АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
ИМЕНИ Г.ИБРАГИМОВА

# Сочинения

Академическое издание
В шести томах

## Том 2

Поэтические произведения
(1909 –1913)

Казань
Татарское книжное издательство
2011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# Әсәрләр

Академик басма
Алты томда

## 2 том

Шигъри әсәрләр
(1909 –1913)

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Т72

Редколлегия :

*К.М.Миңнуллин (җитәкче), Т.Н.Галиуллин, Д.Ф.Заһидуллина,
Х.Й.Миңнегулов, Р.Ф.Рахмани, З.З.Рәмиев, Р.Г.Фәйзуллин,
Н.Ш.Хисамов, Д.С.Шакиров*

Төзүчеләр, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны
әзерләүчеләр :

*З.Р.Шәйхелисламов, Г.А.Хөснетдинова, Э.М.Галимҗанова, З.З.Рәмиев*

Фәнни мөхәррире

*Зөфәр Рәмиев*

**Тукай, Г.М.**

Әсәрләр : 6 томда / Габдулла Тукай. – Академик басма. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.
ISBN 978-5-298-02041-1
2 т. : шигъри әсәрләр (1909–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р.Шәйхелисламов, Г.А.Хөснетдинова, Э.М.Галимҗанова, З.З.Рәмиев. – 2011. – 384 б.
ISBN 978-5-298-02043-5

Әлеге томда татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайның 1909–1913 елларда иҗат ителгән шигырьләре, балладалары, поэмалары, балалар шигырьләре хронологик тәртиптә туплап бирелде. Шулай ук Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр дә урын алды.

Китап Г.Тукай иҗаты белән кызыксынган киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
ISBN 978-5-298-02043-5 (2 т.)
ISBN 978-5-298-02041-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011

**1909**

КҮҢЕЛ

Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!
Күп сөекледер бөтеннән – Тәңрегә сынган күңел.

Һәр минут миннән тели дөнья күңел җимешләрен,
Нәрсә пешсен, булса ялкынсыз күңел, сүнгән күңел?

Алга сәүкъ ит сахибеңне, бул чыдауда таш кеби,
И фәләкнең төрле-төрле золменә күнгән күңел!

Ялтыра, яктыр – килешсен калебе саф шагыйрә,
И моңарча төрле тап-тутларга өртелгән күңел!

Шундый гали матлабың – мең җан бирергә урны бар,
И югарылык белән типкән вә селкенгән күңел!

Игътиля итсәң, канатың ач, – вакыт җитте бугай, –
И тумыштан гарше әгъляларга җилкенгән күңел!

Син йоларсың һәр һәлакәттән – ышаныч бар сиңа,
Яр читендә торганымда ярдәмең булган күңел!

Яхшы аңла: юк сафа, инсанлыгыңны җуймыйча,
И шуны җуймау юлында күп газапланган күңел!

ВАСЫЯТЕМ

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә;
Бирдең арканңны моңарча, инде бир бит әмренә.

Дустларым, кардәшләрем, сез муллаларга әйтеңез:
Бу ике юлны, мине күмгәч, укырлар кабремә.

Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:
Күр, нә рәсма тулган иман берлә Коръән садремә!

ТӘРӘДДӨД ВӘ ШӨБҺӘ

Бер шытырдауны ишетсәм, аузыма җаным килә;
Уйлыймын: «Шелтә кыйлырга әллә вөҗданым килә?»

Аптырыйм: юк изге эш ятканда да, торганда да;
Эш кушарга каршыма һәр дәмдә шәйтаным килә.

Нәрсә күрдем бу җиһанда, ни бетердем? Уйласам:
Алдыма чын эз вә юлдан читкә тайганым килә.

Җырлыймын, ләкин җырымнан файда бармы халкыма?
Бер мәләктән яки шәйтаннанмы илһамым килә?

Раст, бу шагыйрьлек белән мин чынлап ук аурыйм бугай:
Бер-бер атлы рәтләнеп, мәйданга диваным килә.

Мин сизәм: дөнья йөзе – дүзәх, җәһәннәмдер миңа;
Бер шигырь язсам гына, җәннәт вә ризваным килә.

Һәр каралткан кәгаземдә санки багъ, бостан була;
Һәр хәрефтән каршыма вилдан вә гыйльманым килә.

Шигъреми яздым, басылды; мин тагын зур кайгыда:
Фикремә юк-бар белән исмемне игъланым килә.

Һич риза булмыйм үземнән язганымнан соңра мин:
Һәр заман күз алдыма кимлек вә ноксаным килә.

Кайвакытлар һәр сәгадәттән өмидемне өзәм, –
Әллә кайдан шунда икъбаль атлы чулпаным килә.

Ялтырый ул күкләремдә, күп өмидләр арттыра:
Күз яшем сөртергә гүя назлы җананым килә.

## ХАТЫННАР ХӨРРИЯТЕ

*(«Сатирикон»нан)*

– Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатыннарга;
Бөтен фикрем, уем шулдыр, карамый көн вә төннәргә.

Бу уйдан кайтасым юктыр, әгәр канлы сугыш булса;
Хатыннар ирке угърында үләрмен мин, үлеш булса.

Хатыннар! Атлаңыз алга! Бу юлда шаула, матбугат!
Хатыннарны кысучыларга каршы ач сугыш, ук ат!

Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга!
Яшә, и галәме өнса! Вакыт хакларны аңларга!

Таралырга вакыт инде чапан атлы болытларга;
Чапаны да, Бохары да ашарга калсын этләргә!

Алар да, ир кеби, шаһлык, хәкимлек намнәрен таксын!
Хатыннан көч тәрәкъкый бәхренә күл-күл булып аксын!

Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкаддәс яртыбыз безнең!
Кеше булмак өчен иң-иң беренче шартыбыз безнең!

– Эшем бар бит, хатын, тиз булсана, бирсәңче чалбарны!
Бу тапланган икән; бир, яхшысы һәм тапсызы бармы?

Кара, монсы да тапланган! Дидем бит: таплары бетсен!
Шуны чистартмагансың: җә, хатынмы син? Сыер бит син!

## АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ

*(Өченче көлтә)*

Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена;
Унөч яшьлек кызга тисәң, хаҗның әҗре җуела.

Япуннар туп атмыйдыр, төтене җиргә ятмыйдыр;
Ялган сүздер, ышанмагыз: «Сабах» сабын сатмыйдыр.

Эш эшләтсәң, заказ эшләт, файда юктыр пәдрәтдин;
Дин гыйльменә бигрәк чумган Апанаев Бәдретдин.

Ак Иделнең аръягында атлар йөри чабында;
«Чүкеч» сабын кимреп җылый, «Яшен» суккан чагында.

Сары җаулык уртасында сары майның туртасы;
Безнең «Яшен» яшьнәр инде – үтте кышның уртасы.

Бер ишан хәзрәт симерттем, күркә, тавык ашатып;
Сагынсам, корсагын карыйм чүмәләгә охшатып.

Сак берлән Сок кыяміттә берсен берсе очрата;
Биш талчокчы, өч фахишә театрны пычрата.

Чикләвек ярган була да кәнфит ашаган була;
Театрны буяу җитми, концерт ясаган була.

Мөэмин булсаң, чын мөэмин бул – намазыңны калдырма;
Бәйрәмдә кибет япмыйм, дип, частан казак алдырма.

Алтын балдак бармакта, әйләнәдер салмакка;
Ончы хаҗи хәлен сөйлим, әйдә барыйк аулакка.

Тирәк-тирәк ситса булса, матур була чаршауга;
Бөтен Казан абыстае агент хәзер Варшауга.

«Ай туган»да тусаңчы, айдай нурлы булсаңчы;
Яшьләр йөзен кызартканчы, «каралганчы» үлсәңче!

Арыслан берлән юлбарыс яратылган бер каннан;
Безнең Муса һич тик тормас: яңлыш тапкан Коръәннән.

## СӘФИЛГӘ КАРШЫ ЯЗАРГА ТЕЛӘГӘН КАЛӘМГӘ

Юк, маташма, и каләм! – калсынчы – шундай юк белән;
Борча атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән.

Ни эшең бар? Юкмыни, язсаң, югары нәрсәләр?
Угърашып торма җиһанда иң түбән мәхлук белән!

Та әзәлдән ул сәфилләр үз-үзеннән бетмәдә:
Кауме Нухи – су белән йә кауме Лути – ут белән.

Сипмә конфетти аның төсле сәфилләр өстенә:
Ул хәзерләнгән атарга йөзгә каршы чүп белән.

## ПӘЙГАМБӘР

*(Лермонтовтан үзгәртелгән)*

Качан кем сайлады Тәңре мине бу хак пәйгамбәр дип,

Мине фазленә лаек күрде, фәрманым төгәлләр дип, –
Шул ук сәгать үземнән, башкалардан баш-күз алдым да
Сөйләргә башладым хакны кешеләрнең күз алдында.

Кирәк баймы, фәкыйрьме, падишаһмы – күрсәтәм гайбен;
Укыйм ялкынлы аятьләр – карау юк һичберәү кәйфен.
Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә,
Ашамый-эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә.

Җәмигы әкърибам – дустлар, карендәшләр, замандашлар –
Миңа каршы котырдылар, рәхимсез аттылар ташлар.
Сөйләнде өстемә күп ифтира, бөһтан, усал телләр;
Сибелде зур хәкарәт берлә хәтта башыма көлләр.

Ходайга кыйлмадым үпкә золымнардан, каһәрләрдән;
Теләнче рәүше берлән мин качып чыктым шәһәрләрдән.
Менә хәзер япа-ялгыз торам бер читтә, сахрада,
Итәм тагать, күзем, күңлем тәмамән гарше әгъляда.

Күз алдымда күрәм мең-мең кадәр яшьрен җиһаннарны,
Күрәм булган, буласы барча яхшы һәм яманнарны.
Күрәм гъаден, сәмуден, бар булып үткән халыкларны,
Күрәм диңгез төбен, уйнап-йөзеп йөргән балыкларны.

Миңа кол анда бар җанвар: арыслан, хәтта капланнар
Нәбиләргә тимәслекнең мөкаддәс гаһден алганнар.
Догамны тыңлый йолдызлар – кечесе, зурлары бергә, –
Мине тәгъзыймлиләр шатлыклә, уйнап нурлары берлә.

Әгәр кайчакта шау-шулы шәһәрдән аркылы үтсәм,
Янып рухани ут берлә, ашыккан хәлдә юл тотсам, –
Миңа шул хәлдә картлар, бер хәкарәт күзләрен йөртеп,
Үгетлиләр сабыйларны, миңа бармак белән төртеп:

«Караңыз, и сабыйлар! бу кешене, сезгә гыйбрәт бу;
Арамызда иде күптән түгел моннан элегрәк бу;
Тәкәббер ул: торасы килмәде безнең арамызда.
Сабыйлар! Алыңыз гыйбрәт, бу мескингә караңыз да.

Күрәмсез, нинди беткән һәм арыкланган, фәкыйрьләнгән,
Зәгыйфьләнгән, таланган, өсте-башы нинди керләнгән!
Ышандырмакчы булды ул, җүләр! безне, имеш, Тәңре,
Аның аузы белән сөйли, аңар килгән, имеш, әмре!

Имеш тә, безне өндәргә аңар Тәңре үзе кушкан,
Күрәмсез: нинди хур ул, һәм җиһан халкы аңар дошман!»

## ИСЕМДӘ

*(Русчадан)*

Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар,
Гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар;

Исемдә һәм эчемнән көткәнем якты бәхетләрне,
Теләп яшьрен генә рәхәт, сәгадәтле вакытларны;

Исемдә, иң элекке саф мәхәббәт дәрте кузгалгач,

Илаһи бер тәләззездән беренче кәррә тамган яшь;

Яратканым, канымның көйгәне, хәсрәтлә янганым;
«Сөям!» дип әйткәнем, шунда кызарганым, оялганым.

Заман кичте, сулар акты, хәзер юк инде ул ялкын;
Кызу сүнде йөрәктә, мәңгелеккә инде ул салкын.

Тыныч калды йөрәк, шау-шу вә гаугадан тәмам тынды;
Моңаеп тибрәнә тик бер тәхаттырдан гына инде.

## НУМИРГА ТӨШКӘН ИСКЕЛӘР

Күрерсең син боларның йөргәнен һәрдәм коридорда:
Йөриләр карт кәҗәдәй – үзләрен анлар саный зурга.

Озын күлмәк лыпырдый, чалбары юк һәм изү чишкән...
Сәгатьтән һәм дә ыштаннан да чылбыр салынып төшкән.

## ДӘҮРЕ ГАЛӘМ

Йосыб китте сәяхәткә, Рәшит икенчеләп китте,
Рәшитнең сурәтендә бер дегет тулган чиләк китте.

## ИШАН

Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган;
Кибән чалма кибәк башта: ишан булган, имеш, хайван!

## ХӘЗЕРГЕ ӨЙЛӘНҮЧЕЛӘР

Күңелләр саф чагында шәп, матур кыз сайлыйлар анлар:
«Булыр безнең хатын булса йөзе айдай», – диләр анлар.

Әгәр дә басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса,
Убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

## БУЛМЫЙ

Кара карга вә «бөлгән бай» юып асла бәяз булмый,
Вә һәр бер көлтәбаш чын таңчы һәм асла Гаяз булмый.

## МИНҺАҖ

Таш ташыйлар. Анда Минһаҗ «Галия» нигзен сала.
Туй ясыйлар. Монда Минһаҗ гаилә нигзен сала.

Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр соңгысы;
Шикләнәм мин әллә ник: булмас кеби әүвәлгесе.

## ГЛАСНЫЙ

Качан ләкте миңа бу язгы сайлауда гласныйлык,
Югары мәртәбә килде – олугълык һәм дә важныйлык.

Керештем әһле ислам файдасын саклар вә якларга,
Яңа көч берлә башладым гырылдарга вә йокларга.

* * *

Хайлыйм, хайлыйм хайларга, без керештек байларга.
Сторожлыкка ялландык Чәйдәш абзыкайларга.

Яшенче дип әрлибез, доносчы дип хурлыйбыз;
Проститутка Мәрьям белән парлап торып җырлыйбыз.

* * *

Бунларның берсе – үз анасы,
Ләкин үзенә булыр микән баласы?

## КҮРСӘТӘ

Ай кеше! Тыштан үзендә изге хаслət күрсәтә,
Яхшыга – рәгъбәт, яман эшләргә нәфрәт күрсәтә.

Тик Ходай хәзер урынны сайлый ул азмак өчен, –
Әһле дөньяга тышыннан истикамәт күрсәтә.

Әмре Хак корсак белән каршыга каршы килмәсә,
Ул хәзер дингә вә Коръәнгә итагать күрсәтә.

Булса килмәслек үзенә тугъры әйткәннән зарар, –
Ул да чынлыкны сөя, сүздә сәдакать күрсәтә.

Алганы булса берәүдән, ахирәт истән чыга;
Биргәне булса: янарсың, ди, кыямәт күрсәтә.

Бик горурлы ул, сиңа һич ихтыяҗы булмаса;
Бер эше төшсә әгәр, балдай фәсахәт күрсәтә.

Ут кабызмый ул, төтен эчкәндә, иптәштән элек;
Әүвәле аңгар суза – икрам вә хөрмәт күрсәтә.

Дусты өстеннән эчүдә булса сакый ул әгәр,
Тип-тигез салган була, – гүя гадәләт күрсәтә.

Мин арыслан! ди, синең малны тәләф иткәндә ул,
Син аңар калсаң: фәкыйрьмен, ди, җәбанәт күрсәтә.

Чәнчә дә ул күңленә явыз лисане хәнҗәрен:
Нигә кәйфең китте, дустым? ди, мәхәббәт күрсәтә.

Тыңласаң тыштан, синең гайбәт аның аузындадыр;
Син килеп керсәң, ачык, мәгъсум кыяфәт күрсәтә.

## ГАБДЕЛХӘМИД

*(Мин хәфәрә биэрән литәбгатиһи вәкага фиһи)*

Утыз ел хөр фикерлеләрне үлтерт,
Төрекләрдә азатлык тамрын корыт,

Ватан яктыртучы шәмнәрне сүндерт,
Мөселманнан бөтен читләрне көлдерт, –

Утыз ел казыган баз бик тирән шул:
Менә инде Хәмидең шунда
ГӨМБЕРРРТ!

## МУЛЛАЛАР

Йөриләр бу кешеләр сөйрәлеп һәрдәм бәлешләргә;
Теләнми нишләсеннәр: кабилият беткән эшләргә.

Күңелдә утлары сүнгән, вә вөждан майга капланган:
«Әгузе» дип кенә төшмәс, муенга шәйтан атланган.

Менә шул чаклы ялкау, шундый хәйваннар да рухани!
Түбәнлек бу, кабул итмәс үзенә изге рух аный!

## ВӨҖДАН ЗАРАРЫ

*(«Будильник»тән)*

Җиңел йөзмәк бу тормыш диңгезендә,
Хәвеф юк җиллесендә, җилсезендә.

Вәләкин йөкләмә арканда вөждан,
Авыр ул бу йөзүдә кургашындан.

Батарсың син, сине ул төпкә тартыр;
Бу чын сүз: тыңладисаң, фәһмең артыр.

## ИКЕ ЮЛ

Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр – бәхет эстәү;
Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак – мәгърифәт эстәү.

Синең кулда: теләрсәң – мәгърифәтле бул, бәхетсез бул;
Вә яки бик бәхетле бул, ишәк бул, мәгърифәтсез бул.

* * *

Ничек тормак тиеш, дустым? дисеңме, –
Шулай тор: бик кысып тот син кесәңне.

Һаман сак бул, кара ул як, бу якны;
Хосусан сак тоту лязем колакны.

## ГАИЛӘ ТЫНЫЧЛЫГЫ

Әгәр булсын дисәң бер өй эче шау-шу вә җәнҗалсыз:
Ире булса сукыр, ул җитми, – булсын һәм хатын телсез.

## КИҢӘШ

Ялангач калдыйсаң син һәр җәһәттән фазлы Тәңридән,
Мыраулый башла бик ямьсез, алып үрнәк Бәширидән.

## ИКЕ КОЯШ

Күр: ничек, иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула, –
Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.

Бу икәүгә Тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:
Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.

## ЭШТӘН ЧЫГАРЫЛГАН ТАТАР КЫЗЫНА

*(«Зиләйлүк» көенә)*

Сөялгәнсең чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең;
Кызганмыйча күңлем чыдый алмый:
Бигрәк моңлы карый күзләрең.

Атылган кош, адаштырган эттәй,
Үткәннәргә мәэюс карыйсың;
Күрәм, ике ирнең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

Аз шул бездә байлар – кайсысы кем
Фәрештәдән канат каермас;
Алсын гына шәйтан иманыңны,
Җәһәннәмлек бу дип кайгырмас!

Күрдем әле синең залимеңне:
Һаман кәеф сөрә, типтерә;
Рәхәтләнә, кяфер! Сине шулай
Баганага сөяп киптерә.

Сизмисең бит син дә – синең яннан
Нечкә күңел шагыйрь узганын,
Синең болай мескинләнгән хәлең
Аның күңлен ничек өзгәнен!

## БӘГЪЗЕ ЗЫЯЛЫЛАРЫМЫЗ

Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар,
Сирәк ләкин, дөрест әйтсәм, кешелекле хәялылар.

Әгәр күрсәң кызарган йөз аларда, бер дә алданма:
«Оялгандыр» димә яңлыш, «җибәргәндер» дисәң – әүля!

## ГОМЕР ХАКЫНДА

Бик күңелсез бер начар журнал – гомер,
Анда, әлбәт, баш мәкалә мал ирер.

## АЧЫ ХӘКЫЙКАТЬ

*(«Бакырган»нан)*

Татар бае – бөлгүче,
Төрмәләргә кергүче;
Гомер буе ни кыйлган –
Шунда мәгълүм булгучы.

Бай чагында көлгүче,
Гайбен-нисен күргүче;
Табылмыйдыр мескинне
Тугъры юлга сөргүче.

Бай ул ялгышмый, диләр,
Һәр фигъле яхшы, диләр;
Аның һәр дүрт ягына
Монафикълар тулгучы.

Малы, мөлке беттисә,
Дәүләт, бәхет киттисә,
Малның кадрен белми, дип,
Чын дустлары көлгүче.

## ТӨРЕКЧӘДӘН

Сөйгәнеңне мин кочам, дип, дошманым көлгән була;
Белми: җанаш кайгысы һәр кич кочагымда куна.

## ГАШЫЙК

Син күрерсең бу кешене: күп вакыт уйный, көлә, –
Ул шулайтеп халәте рухын яшермәкче була.

Белмичә, «уйный» диләр, эчтән ниләр уйланганын;
Сизмиләр – чыкмый төтен тышка – мәхәббәт янганын!

Ул шаярганда, кисәктән, керсә җанаш каршына,
Гашыйкым җитдиләнә, шундук уеннан тартына;

Кып-кызыл төскә керә ул, үзгәрәдер йөзләре,
Әллә нинди көчтән астка салынадыр күзләре.

Ул түнә, хәлсезләнә шул, очраса үз хурына,
Хәзрәти Муса тәхәммелсез тәҗәлли нурына.

Нишләсен, җанаш хозурында аңар лязем намаз;
Бер азан әйткәч, колак каккач, мөселман уйнамас.

## ВАКЪТЫ ГАҖЕЗЕМ

*(Көнлек дәфтәремнән)*

Тапдисәм мәүзугъ, язарга аптыраймын:
Кай төшеннән мин моны, дим, ләктерим?

Ул йозак төсле миңа, юк ачкычым,
Йә бөек сәд – юк менәргә баскычым.

Йә кимә ул – юк янымда ишкәгем,
Шул рәвеш эчтә кала күп хисләрем.

Яки уйга калдырадыр интикад,
Итмәсәм дә мин аңар күп илтифат.

Уйлыйсың син бер фикерне: раст кеби,
Шик төшә: юк, ул да раст булмас кеби.

Юк әле миндә хәкыйкатькә вөсул,
Әллә нигә айрылалмый уң вә сул.

Йа Ходай! Кайчан чыгармын шөбһәдән?
Кипми ник шөбһә тире бу җәбһәдән?

Йа Ходай! Кайчан бу золмәтләр бетеп,
Юл салырмын күкрәгем берлән этеп?

## ШЕКСПИРДӘН

Күрәм кайчакта: җанкәмнең яңагына чебен кунган, –
Йөри бит шатланып шунда, үзенчә әллә кем булган!

Карыйм да мин, бәхетсез, шул чебеннең бәхтене көнлим:
Ходаем, ни сәбәптән булмадым соң шул чебен мин! дим.

## КИТАП

*(Аз гынасы русчадан)*

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;

Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь, –

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам;

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым;
Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем;

Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка.

## МӨКАДДИМӘ

И көләч йөзле малай, йөргән малай яланаяк!
Бер дә тыштан кермичә уйнап йөрүче шартаяк!

Чәкмәшәңне куй да бер якка, йөгер, кил каршыма!
Шартаяктан да күңеллерәк бер әйбер бар сиңа.

## СӨБХАНАЛЛА, СӨБХАНАЛЛА

Сабый чакта укытканда мине хәлфә,
Рәхмәт аңар, өйрәтте бер яхшы нәрсә:
– «Сөбханалла» диеп әйтү тиеш, – диде, –
Бер мән яңа гына туган айны күрсә.

Шул заманнан бирле айның туганына
Һәм дә алтын көпчәк төсле тулганына
Карап, күңлем кайчан минем хәйран кала,
Диям шунда: сөбханалла, сөбханалла!

Бу әйтүем, хәер, минем гадәт кенә,
Бу бертөрле дини булган әдәп кенә;
Бер вактым бар – чын күңлемнән укыйм моны,
Хәлфәм! Яусын сиңа һаман рәхмәт кенә.

Менә нәрсә: күрәм бәгъзан сөйгәнемне,
Көннәр, төннәр гыйшкы берлән көйгәнемне;
Хәлфә, шунда минем телем тотлыгадыр,
Эшкә кушам тагын шул ук белгәнемне.

Тулган айга охшаш йөзе, башы аның,
Яңа туган айга охшаш кашы аның;
Күңлем аңар карап торып хәйран кала,
Укыйм чынлап: сөбханалла, сөбханалла!

Әгәр күрсә шул матурны Гайнетдиннәр,
Гади генә Котбетдиннәр, Шәмсетдиннәр,
«Сөбханалла» дию кайда аларга соң! –
Укымаган алар, бернәрсә белмиләр.

Әгәр, хәлфә, мин дә шулай надан булсам,
Синнән гыйлем алалмыйча калган булсам,
Әйтер идем, шулар кеби, мин гыйрфансыз:
Әй-яй, бигрәк матур икән, чукынган кыз.

ЭШ

Тынма, эшлә, и сабый! Бел, Тәңредән эшләргә – көн,
Эшләп аргачтын, бирелгәндер тыныч йокларга төн.

Иртә торгач та язарга, дәрсең укырга тотын;
Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың җомга көн.

Күр, ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буенча яктыра.

Соңра, арган төсле, ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата.

Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман!

ӘНӘ-МЕНӘ

Әнә чүлмәк: аңар катык тутырган;
Менә хәлфә: башы мантыйк тутырган.

Әнә карга: мәчет өстенә кунган;
Менә шәкерт: указлы мулла булган.

Әнә чеп-чи бәрәңге кәлҗемәсе;

Менә «Тәхрире мәрьәт» тәрҗемәсе.

## МОГЪҖИЗА

Пәйгамбәрнең вафатыннан соң асла могъҗиза булмас:
Ярылмас ай икегә, һәм кара таштан төя тугъмас,

Диләр безнең гыйлем әһле. – Ышанмаңыз, бу ялгандыр:
Үзем күрдем бүген – безнең заманда могъҗиза бардыр:

Бүген иртүк миңа шактый бурычлы иптәшем килде,
Ялындырмый, талашмый, вәгъдәсендә акчасын бирде.

## ТУГАН АВЫЛ

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

## ЧЫРШЫ

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;
Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сәхра сап-сары.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:
Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

## ЯҢГЫР ИЛӘ КОЯШ

Кояш әйтте: «Һаман мин яктырырмын
Вә бер дә батмамын, янып торырмын».

Диде Яңгыр да: «Һәр көнне явармын,
Кара җирне юешләр, елгалармын».

Кояш каршы диде: «Син бик юешле,
Явасың былчыратып һәммә төшне.

Суыңнан анда баткак, монда баткак,

Синең бар белгәнең – җир былчыратмак.

Юешлектән иген, ашлык черидер,
Мужиклар, яумасайде, дип телидер».

Диде Яңгыр җавапта: «Син кызасың,
Игенне яндырасың һәм кырасың».

Ачуланды Кояш бу сүзгә, кызды,
Ачудан эсселектә хәдтән узды.

Диде: «Мин бит җимешләрне пешергән,
Нурымнан җанлы-җансыз файда күргән».

Диде Яңгыр: «Аларны син пешерсәң,
Ә мин бит үстерәм һәм су эчертәм.

Әгәр мин яумасам, багълар шиңәрләр,
Болынлыклар, яшеллекләр кибәрләр».

Кояш Яңгыр белән күп кычкырышкач,
Бере-берсен яманларга тырышкач, –

Татулашты, килештеләр ахырда
Бу көннән сүз көрәштермәскә бер дә.

Шулай бетте боларда сүз вә тартыш,
Күрергә булдылар нәүбәт белән эш.
Кояш әйтте: «Кызам үз нәүбәтемдә,
Ә син яу рәхмәтеңлә нәүбәтеңдә».

Кояш, Яңгыр әле бу көнгә чаклы
Бозып эш кыйлмыйлар бу иттифакъны.

## МИЛЛИ МОҢНАР

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка киләә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мескин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Ак Идел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,

Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, – диде, – «Әллүки»!».

## ЯРАТЫРГА ЯРЫЙ

Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар,
Киемсез калтырап торган мәсакине, фәкыйре бар.

Яратырга ярый җәйне: матур ул, анда зур ямь бар,
Вәләкин таш бинасы юк фәкыйрьләргә җәһәннәм бар.

Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар;
Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне адәм бар!

## ЯПУН ХИКӘЯСЕ

*(Буренитнән)*

Электә бер Ташчы торган бу дөньяда,
Безнең җирдә түгел – ерак Япунъядә.

Үзе булган таза гына бер яшь кеше,
Ялыкмыйча эшли икән ул таш эше.

Ризыкланган ачы тирләр һәм көч белән,
Көн буена ташлар ватып чүкеч белән.

Булганлыктан һаман да эш, һаман да эш,
Күрәлмаган бу яшь егет рәхәт тормыш.

Беркөн шулай эшләп-эшләп каты аргач,
Күңле кайткан эштән, тәмам хәлдән тайгач,

Тотынган ул үз-үзенә тарланырга,
Мондый начар көн күрмештән зарланырга:

«Ходаем, ник фәкыйрь иттең мине болай?
Рәхмәтең киң, мин бәндәңне кыйлсаң да бай;

Бүтәннәрдәй мин дә рәхәт сөрер идем,
Тынычлык һәм бәхет йөзен күрер идем».

Шуннан гына очып үткән бер Фәрештә
Әллә ничек моның моңын, зарын ищтә.

Һәм әйтә ул: «Ярар, яхшы, шулай бул, – ди,
Ягъни: – Үзең теләгәнеңчә бай бул», – ди.

Безнең Ташчы шул минуттук зур бай булды,
Азаплаган читен тормыш уңай булды.

Инде хәзер авыр эшләр муенда юк,
Рәхәт ята, һичбер нәрсә уенда юк.

Шул вакытта Ташчы күрә: зур урамнан
Үтеп бара гаскәр берлән олугъ бер Хан.
Киемнәре, баш өстендә чатырлары

Ялт-йолт килә көнгә каршы – алтын бары.

Ташчы әйтә: «Зур эшмени бу – бай булу?
Насыйп булса менә шушындый Хан булу, –

Булыр иде шул вакытта бәхтем минем;
Аһ, булсачы вәзирләрем, тәхтем минем!»

Тагы шуннан очып барган шул Фәрештә
Бу Ташчының сөйләгәне сүзен иштә:

«Теләгәнең булсын синең – син Хан бул, – ди,
Үзе китә очып: – Хәзергә сау бул!» – ди.

Ташчы карый: шулук хәлдә ул Хан булган,
Һәр ягына вәзирләр һәм гаскәр тулган.

Уенчылар матур көйләр көйләгәли,
Баш өстендә алтын зонтик күләгәли.

Шулай да бик рәхәт түгел: Кояш эссе,
Гаҗиз калды Хан эсседән, тәмам пеште.

«Кирәк түгел, – ди, – Хан булу һәм баш булу,
Насыйп булса икән миңа Кояш булу!»

Шул Фәрештә тагын шунда җитеп килеп,
Китте очып: «Ярар, булсын синеңчә», – дип.

Шул минутта Ташчы егет Кояш булып
Күктә тора, бу дөньяга нурлар коеп.

Бераздан соң әллә кайдан чыга Болыт,
Җир һәм Кояш арасына пәрдә булып;

Каплап тора әллә нинди гайрәт берлә,
Күренмидер Кояшка җир, Кояш – җиргә.

Егет әйтә: «Кирәк түгел Кояш булу,
Болыттан да кимсеттереп, юаш булу.

Тәңрем, ирек бир син миңа, Болыт булыйм,
Болыт булып, җиһанга баш булып торыйм».

Фәрештә дә шул вакытта җитеп килеп,
Китә күккә: «Ярар, булсын синеңчә», – дип.

Шулук вакыт Ташчы егет Болыт була,
Җир йөзенә яңгырларын коеп тора.

Чиләк-чиләк булып яңгыр яуганыннан
Сулар артып, ташып чыкты ярларыннан.

Сәхра, болын, игенлекләрне су басты,
Һәр нәрсәгә урын булды дулкын асты.

Бу дулкыннар кубарса да шау-шу, гауга,

Һөҗүм итеп килсәләр дә, охшап яуга, –

Шунда үсеп тора торган олугъ Таш-тау
Зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау.

Егет әйтә: «Кирәк түгел Болыт булу,
Артык миңа Болыт булганча юк булу!

Гайрәтемнән күрсәтмичә һичбер какшау,
Минем көчтән көлеп тора шушы Таш-тау!»

Шунда тагын Фәрештәсе килеп җитә:
«Ярар, яхшы, шулай бул син», – диеп китә.

Ташчы егет шулук минут була Таш-тау;
Гомерлеккә торырмын, ди, мин шунда сау.

Һәр яклардан килсәләр дә сулар ташып,
Дулкыннары бәрелсәләр дә шып та шып!

Кибаранә күтәреп баш, безнең Таш-тау
Селкенми дә, кузгалмый да тора сап-сау.

Шул вакытта әллә кайдан чыга Инсан,
Кулларына балта берлән чүкеч тоткан.

Килә дә ул, бу Таш-тауны вата башлый,
Таш артыннан ташны ватып ата башлый.

Егет әйтә: «Мин күп нәрсә булып үттем,
Һәрберсеннән галилек һәм бәхет көттем;

Күрдем хәзер: эшкә һич нәрсә тиң түгел,
Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел.

Кирәк түгел, мин яңадан Ташчы булам,
Әүвәлгечә иҗтиһадлы эшче булам!»

Кодрәт берлә шунда егет Ташчы була,
Әүвәлгечә иҗтиһадлы эшче була.

## КҮҢЕЛ ЙОЛДЫЗЫ

Тәнәфферләр,тәхаттырлар, тәрәххемләрлә дөньядан
Гөзарым, захмедар васле бер һиҗрә мөкәүкәбдер.

*Габдулла Җәүдәт*

Ничаклы изсә дөнья, ирке бар – куркытмыйдыр безне;
Елар җирдә көләм мин, һич чытып тормыйм аңар йөзне.

Минем гомрем караңгы төн – кояшым һәм аем тугъмас;
Шуңар да шөкер итәм мин: бу төнем йолдызлы, йолдызлы.

Озаттылар миңа кул төрле мәлгунь көч, кара көчләр,
Теләп сүндермәгә күңлемдә янган изге йолдызны.

Вәләкин сүнмәде ул: йолдызым якты, һаман нурлы;
Гаҗәпме, юлга салса, ичмасам, бер данә юлсызны?

Күзеннән канлы яшь түксен иде барча шәятыйным,
Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб, гүзәл эзне!

Минем күңлем мөкәүкәбдер өмид, хәсрәт, тәәссерлә;
Зарар юк, барча кодсиятебез дә айлы, йолдызлы!

## КИҢӘШ

*(Позняковтан үзгәртелгән)*

Чикмә гамь шул нәрсәгә: синнән гомернең еллары
Алган аны бер дә бирмәскә – очырган җилләре.

Тормышыңның агымында инде ул киткән агып;
Кайгырудан файда юктыр – булмый инде кайтарып.

Түкмә күз яшь: ярдәмендә һәр заманда Алла бар;
Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!

## СӘРЛӘҮХӘСЕЗ

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Караңгыдыр, күңелсездер гомер юлы,
Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,
Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә
Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тулы.

Мескин адәм! Тыштан уйный, тыштан көлә,
Ямьсез якны уйлап куя эчтән генә.
Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,
Һич кайгысыз кеше булса – адәм түгел!

Бераз вакыт шатлык таба исрек кенә,
Үз-үзенә ачы агу эчреп кенә:
«Әмма дөнья нинди кызык, нинди хозур,
Бу дөньяда кемнәр бар, – дип, – миннән дә зур!»

## ТЕЛӘҮ БЕТТЕ

*(Пушкиннән мокътәбәс)*

Теләү бетте хәзер миндә теләк соңра теләкләрне;
Кире сүттем хәзер күп эшкә сызганган беләкләрне.

Күрәлмим мин азатлык бер дә чиксез ихтыярымнан;
Гаҗәп ләззәтле, тәмле булса да, туйдым хыялымнан.

Фәкыйрь калдым хәзер: тормыш үзенең биргәнен алды;
Күңел буш: анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы.

Бетердем шиңдереп төрле гүзәл чәчкәмне барсын да
Явыз тәкъдир, каты тәкъдир, суык тәкъдирем астында.

Өмидсезмен: фәкать актык дәкыйкамне көтәм инде,
Көтәм: кайчан тавыш-тынсыз гына бер көн бетәм инде?

Мисал бу: көз көненең кышка каршы, соңгы чагында,
Туңып беткән агачның яп-ялангач бер ботагында

Төшәр-төшмәс торадыр соңга калган бер генә яфрак, –
«Төшәм» дип калтырый, җил сызгырып киткән саен чак-чак.

## ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

## АНА ДОГАСЫ

Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр вә сәхралар тора балкып.

Авыл тын. Иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
Халык йоклый – каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.

Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
Авыл кыръенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.

Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

## ТАЯН АЛЛАГА

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;
Ул – рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

БАБАЙ

Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе,
Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе.
Яңак, маңлай җыйрылмаган, тешләр дә сау,
Яшьләрчә саф, ачык чыга аның сүзе.

Җитеп килә инде аның җитмеш яше,
Җем-җем итә җитен сакал, көмеш чәче.
Бабай, мескин, бу дөньяда күпне күргән,
Үлеп беткән инде аның күп яшьтәше.

УЯНМАС ЙОКЫ

Фатыйма күрде үзенең бүлмәсендә бер рәсем:
– Әнкәем, бу кем? – диеп сорды, кочаклап әнкәсен.

Әнкәсе бирде җавап: – Әүвәлге угълым бу минем,
Дөньяда юк ул хәзердә – бер туган абзаң синең.

– Әнкәй, әнкәй! Нишләгән ул, кайда соң ул? Әйтсәнә!
Мин аны күрмәк телимен, зинһар, әнкәй, тапсана!

– Юк, җаным, юк, күз нурым, абзаң хәзердә йоклаган;
Ул каты йоклый, вөҗүден кара туфрак каплаган.

– Ә, алайса, син агамны, бар, уят, торсын, әни;
Бергә уйнарбыз, үзенең сеңлесен күрсен, әни!

– Юк, җаным, син белмисең, юктыр уятырга мәҗал,
Ул уянмас бер йокыдыр, аһ, аның исеме – әҗәл!

АЙҺӘМ КОЯШ

Һималая тау өстендә алтын бишек,
Кояш йоклый һәр кич саен шунда төшеп;
Җил төн буе йоклаганын саклап тора,
Тирбәтә һәм өстен-башын каплап тора.

Йокысыннан Кояш ничек уяндисә,
Җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә;
Исә-исә бөтен дөнья буе китә:
– Торыгыз! – ди, – уяныргa вакыт җитә!

Торып чыккач шул бишектән Кояш агай,
Анда кереп йоклый инде энесе Ай;
Йоклый шунда йолдызлар да өелешеп,
Оядагы йоклап яткан кошчыклардай.

Каты йоклап Ай бишектә мәгърибкәчә,
Торып чыга, көлеп җиргә нурын чәчә;
Кояш һәм Ай – ике туган агай-эне –

Менә шулай дустлык берлән нәүбәтләшә.

## ҖИР ЙОКЫСЫ

Кырга ак кардан
Юрган ябылган;
Җир язга чаклы
Уйкуга талган.

Ул тормас, йоклар,
Кышлар үтмичә, –
Кыйбладан кошлар
Кайтып җитмичә.

Язның айлары,
Апрель, майлары,
Бик матур сызлып
Аткан таңнары;

Урман шаулавы,
Кошлар сайравы,
Күкләр күкрәве,
Яңгыр аннары.

Коену көн саен
Кояш нурында;
Аннан соң тагын
Төшкән чык төндә.

Бу хәлләр җиргә
Барчасы бергә
Калган тик инде
Төштә күрергә.

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш.
Уяныр әле,
Тукта, үтсен кыш!

## КЫШКА БЕР СҮЗ

Кит әле син, аксакал кыш! Күр, әнә таудан туры
Тәгәридер ул матур кыз – язның алтын фәйтуны.

Тиз югал, и Кыш бабай, син ал да тиз кач карт башың,
Барыбер, күрсәң, качарсың, язны – гөлләр патшасын!

Бер дә юк ул патшаның мылтык-кылыч, алмаслары,
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре.

## КОШЛАРГА

Курыкмагыз, кошлар, күреп сез янығызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.

Җырлагыз сез күңлегезгә Тәңре нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк шулай ук ауларым.

Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим, сезгә тимим;
Әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин?!

Курыкмагыз – яхшы беләм, мин һич тә сезне ауламам;
Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.

## САБЫЙГА

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз – аларның булганы юктыр гомер.

Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле – шагыйранә ялган ул.

Һич өрәк, албасты булган сәхралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк.

Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

## КАРЛЫГАЧ

Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын
Оя итте минем сөйгән Карлыгачым.

Ул көн буе аузы берлән балчык ташый,
Балчык берлән матур итеп оя ясый.

Күп эшләде иренмичә; бара-бара
Чыгарды ул матур-матур балалар да.

Ачыксалар Карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.

Карлыгачым ямьсез озын кара төндә
Каты йоклый оясында, алмый тын да.

Бер канатының астына тыга башын,
Уянмый ул, – бөтен кеше тавышлансын.

Күк күкрәсен, ялтыр-йолтыр килсен яшен,
Төн буена нинди каты җил исмәсен, –

Ни булса да, бары да бер аның өчен, –
Уянмый ул, селкетми дә борын очын.

## КЫШКЫ КИЧ

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, тезелешеп, –
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми һич тә.

Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең озынлыгын сизмисез дә
Әнкәгезнең сөйләгәне әкият берлә.

Тышта иссен ачы җилләр, тузсын карлар,
Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар,
Суыклыктан очар кошлар очалмасын, –
Сезнең урын җылы, әйбәт, – ни кайгы бар?

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт:
Һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет;
Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр,
Ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар.

Мондый кышкы кичтә сыгъныр урыннары
Аларның юк, өши бите, борыннары;
Үлми калса яхшы алар салкынлыктан,
Кайберсенең шуннан була үлемнәре.

Очрый калса сезгә шушындый ярлылар,
Яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар, –
Яшь балалар! Аларны сез яратыгыз,
Җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз!

## КОШЧЫК

Кичә мин читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым,
Күңелсез тоткынымны киң яшел урманга кайтардым.

Аңар бирдем азатлык мин, үземдә шул вакыт күрдем:
Тынычлап калды никтер һәм тәмам иркенләде күңлем.

Күзем берлән озаттым: кошчыгым урман таба очты,
Югалды күк йөзендә тиз вакытта, бер дә юк төсле.

Очып киткәндә ул шундый матурлап сайрады моңлы:
Миңа санки азат иткән өчен изге дога кылды.

## БИШЕК ҖЫРУЫ

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

## БӘХЕТЛЕ БАЛА

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олугъ күрсә, белергә кушканын белсә.

Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас – менә бәхте аның шунда.

Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә!

## БАЛА БЕЛӘН КҮБӘЛӘК

Бала:

Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, –
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

## МӘКТӘПТӘ

Менә көз барча кырларны вә урманны ялангачлый,
Менә ак тун киеп инде күңелсез кыш килә башлый.

Игеннәр тулган ындырга, халыкның эшләре беткән,
Вә көньякның вакытча безгә килгән кошлары киткән.

Урамнарда күңелсезлек, авылда сизлә бер кайгы,
Терелекләр вә шау-шулар, кызыклар кайда ул җәйге!

Күңелсез һәм дә ямьсез булса да шул чак табигатьтә,
Кызык ләкин, күңелле бик авыл кырънда мәктәптә!

Укулар кычкырып анда! Бөтен мәктәп килә шау-шу!
Кызык җәй айрылып торган укуга көз көне каушу!

## ЭШ БЕТКӘЧ УЙНАРГА ЯРЫЙ

Бик матур бер җәйге көн: өстәл янында бер Сабый
Ян тәрәзә каршысында иртәге дәрсен карый.

Чын күңел берлән укый ул, кат-кат әйтеп һәр сүзен;
Бик озак шунда утырды, бер дә алмастан күзен.

Шул чагында бу Сабыйны чакыра тышка Кояш:
«И Сабый, – ди, – әйдә тышка, ташла дәрсең, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман;
Чыкчы тышка, нинди якты, нинди шәп уйнар заман!»

Бу Кояшның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Тукта, сабрит, уйнамыйм, – ди, – уйнасам, дәрсем кала.

Көн озын ич, ул уенның мин һаман вактын табам,
Чыкмамын тышка уенга, булмыйча дәрсем тәмам».

Ул, шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас берлән чынлап ябышты дәрсенә.

Өй түрендә шул заман сайрый ботакта Сандугач,
Ул да шул бер сүзне сайрый: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман,
Чыкчы тышка, нинди һәйбәт, нинди шәп уйнар заман!»

Сандугачка каршыга биргән җавабында Бала:
«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәрсем кала.

Туктале, бетсен дәрес, – ди, – әйтмәсәң дә уйнарым,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың тыңларым!»

Ул, шулай дип, һич зарар бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас берлән чынлап кереште дәрсенә.

Шул вакытта өй түрендә бакчада бер Алмагач
Чакыра тышка Сабыйны: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Бик күңелсездер сиңа эштә утырмак һәрвакыт,
Әйдә, чык син бакчага, җитте хәзер уйнар вакыт!»

Алмагачның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Юк, сөекле Алмагачым, уйнасам, дәрсем кала.

Тукта, сабрит аз гына, – ди, – и кадерле Алмагач,
Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач».

Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәрсене,
Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны – барсыны.

Чыкты йөгреп бакчага: «Йә, кем чакырды, – дип, – мине?
Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер мин дәрсеме!»

Шунда аңгар бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңгар кып-кызыл зур алма бирде Алмагач;

Шунда аңгар шатланып сайрап җибәрде Сандугач,
Шунда аңгар баш иделәр бакчада һәрбер агач.

## АРБА, ЧАНА, АТ

Бер заман бер төшкә килгән Ат белән Арба, Чана;
Бу өчәү һәрберсе дә үз тормышыннан зарлана.

Арба әйтә: «Җәй көне мин һич тә рәхәт күрмимен:
Көн-төне эштә йөрим, һичбер җигелми тормыймын».

«Әмма соң бу кыш көне бигрәк уңайсыз!» – ди Чана.
Ат та, сүзгә катышып, үз нәүбәтендә зарлана:

«Юк ла, и Арба, Чана! – ди, – сезгә тормыш бик уңай,
Эшләсәгез алты ай сез, ял итәсез алты ай.

Күпме зарлансам урын бар, мин каты мәзлум менә:
Хәл җыймыйм ел тәүлегендә, ичмасам, бер көн генә!»

## КЯРХАНӘДӘ

Көндез эш, кичен эш,
Бер минут юк тыныч,
Аждаһа-машина! –
Карарга куркыныч.

Җәһәннәмдәй эссе
Кайнаган җиз, бакыр.
Эшлидер, тик эшли
Эшче мескин, факыр.

Аргайгандыр үзе,
Саргайгандыр йөзе,
Бөкрәйгәндер биле,
Нурсызланган күзе.

Ул төтен, ул төтен! –
Алып та булмый тын!
Көпчәкләр дөберди,
Чыгарырлык котың.

Качасиде моннан,
Бу ямьсез тәмугтан!
Әллә кай җирләргә,
Ямь-яшел кырларга;

Шул җирләргә: кайда
Сайрый кошлар, анда
Арыш, богъдай үсә,
Җир җиләкләр пешә.

## КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК ХИКӘЯСЕ

Борын заман бер Ир берлән Хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык, –
Болар булган берсеннән дә берсе арык.

Әйтә бер көн Ире: «Кара монда, Хатын!
Үзең яхшы беләсең бит печән хакын, –
Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,
Ашап ята бушка гына алар азык».

Хатын күнде, диде: «Ирем, ярар, ярар,
Бу икене кумаклыкка булсын карар;
Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән,
Аларны соң асрап торып ни файда бар?»

Нишли инде мескин Кәҗә белән Сарык?
Булмый хуҗа кушканына каршы барып.
Икесенә бер зур гына капчык тегеп,
Китте болар кырга таба сәфәр чыгып.

Китте болар. Бара, һаман бара, бара, –
Күренмидер күзләренә ак һәм кара.
Бара болар. Күпме баргач, Алла белә,
Юл өстендә үлгән Бүре башын таба.

Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак,
Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак, –
Баш янында болар икәү тора куркып,
Әйтешәләр бер-берсенә: «Син тот, мин тот!»

Кәҗә әйтә: «Сарык абзый, син көчлерәк».
Сарык әйтә: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк».
Бүре башын кулга тотып кузгатырга
Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк.

Озак торгач шунда Кәҗә белән Сарык,
Бүре башын тоталмыйча, куллар барып,
Башны икәү тотып ике колагыннан,
Юнәлделәр, капчыклары эченә салып.

Бара болар. Тукталмастан һаман бара.
Күрә болар: ерак түгел бер ут яна.
Утны күргәч, иптәшенә әйтә Сарык:
«Әйдә, Кәҗә, куныйк бүген шунда барып.

Ут янына бүреләр дә килалмаслар,
Безнең анда кунганлыкны белалмаслар».
Сарыкның бу киңәшенә Кәҗә күнде:
«Әйдә, иптәш, ярар, барсак барыйк инде».

Кәҗә, Сарык ут янына якын барса,
Мескиннәрнең күз алдында менә нәрсә:
Өч-дүрт Бүре утырганнар каршы утка,
Тыршып-тыршып пешермәктә алар ботка.

Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны,
Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны.
«Исәнмесез, дустлар, Бүре әфәнделәр!» –
Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле.

Куаналар өч-дүрт Бүре, моны күргәч,
Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч:
«Ашыйбыз, – дип, – бу икәвен тотабыз да,
Менә ничек ит таптык, – дип, – боткабызга!»

Кәҗә әйтә: «Кайгырмагыз, бездә ит күп;
Ул ит берлән һәркайсыбыз булырбыз тук!
Ни карыйсың? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык!
Капчыктагы Бүре башын китер алып!»

Сарык шунда капчыктагы башны ала, –
Барча Бүре куркуыннан шашып кала;
Өч-дүрт Бүре хәйран калып торган чакта,
Кәҗә һаман гайрәт чәчә, ачулана.

Кәҗә әйтә: «Микикики! микикики!
Капчыктагы Бүре башы бит уники!
Ах, уңмаган, җүләр Сарык, надан Сарык,
Моннан зуррак Бүре башын китер табып!»

Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,
Капчыктан ул алып килә шул ук башны.
Өч-дүрт Бүре чынлап инде куркыштылар,
Бер-берсенә күзләрене йөртештеләр.

Түгел хәзер Бүреләргә ашау кайгы,
Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы.
Ничек качыйк? Ничек табыйк качу юлын? –
Һәрбер Бүре шуңар салган бөтен уен.

Торып әйтә шул арада Өлкән Бүре, –
Картайган һәм күп эшләрне үткән Бүре:
«Туктагыз, – ди, – мин тиз генә су китерим,
Суы бик аз, безнең ботка пешәр коры».

Шулай итеп, Өлкән Бүре суга китә.
Кайтмый ләкин, озак кына заман үтә.
Кайтмый Бүре – эзе дә юк, исе дә юк,
Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә.

Бүреләрне тагын каты курку басты,
Чөнки хәзер башлыклары китеп качты.
Тагын берсе суга таба китте торып:
«Туктагыз, мин эзләп кайтыйм», – дигән булып.

Мәгълүм инде, бу Бүре дә кача шулай,
Хәйлә берлән качарга юл ача шулай.
Кайтмый бу да, әллә ничә сәгать үтә,
Мәҗлес халкы көтә һаман, көтә, көтә.

Өч-дүрт Бүре берсе соңра кача берсе,
Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе.
Болар качкач, Кәҗә белән безнең Сарык
Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып.

Утыралар аяк бөкләп каршы утка,
Болар инде тәмләп кенә ашый ботка.
Ашап туеп, рәхәт кенә, тыныч кына
Кәҗә, Сарык бу төннәрен шунда куна.

Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук, –
Кулларында Бүре башы салган капчык, –
Тагын болар урман буйлап сәфәр итте.
Нәрсә языйм?.. Хикәям дә шунда бетте.

**1910**

ТАТАР МӨХӘРРИРЕНӘ

Яз, ни язсаң да, синең бар – язганыңның нашире;
Ашлыгың үстисә – бир, тайярдыр аның гашире.

Тик онытма: бер заман гүргә керер ялгыз башың;
Һичберәү булмас янында: иптәшең һәм кардәшең.

Барча әгъзаң чиркәнеч һәм куркыныч хәлгә керер;
Уйлаган башың, каләм тоткан кулың бергә черер.

Дөньяда булган кеби язганнарыңның нашире,
Монда да кортлар – синең үлгән тәнеңнең «нашир»е.

НӘСЫЙХӘТ

Ихтыяҗын гарз итеп килсә теләнче капкаңа,
Каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама.

Син кеби һәм ул теләнчеләр дә – Алланың колы;
Кул суза, мескин! – бәхетсезлек вә ачлык аркылы.

Күрмәгез бер яклы дип сез бу вафасыз дөньяны;
Ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.

Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә:
Син бүген бай, бәлки, шәйтаннан да ярлы иртәгә!

Булса – бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаслыгын, –
Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын!

МӘҖРУХ УКАЗ

Галәлгомья фикер йөртми бераз да, –
Ук аткан төсле үрдәк яки казга, –
Тисен бу дип Мөхәммәд хәзрәтенә,
«Исабәт»ләп бер ук аттым Хиҗазга.

Исабәт итмәде ләкин бераз да,
Зарар бирмичә хаҗ, руза, намазга,
Бераз әйләнде дә ук буш һавада
Килеп ләкте кулымдагы указга.

*

Тизүк мәҗрух указымны күтәрдем,
Дәваларга Өфе якка юнәлдем.
Тагын терлер микән мескин указым
Дәвасына фидадыр күп һәм азым!

КӘҖӘ ТУГЪРЫСЫНДА

Бер заман йорт кошлары, хайваннары
Хуҗаның каршына килделәр бары:

– И Хуҗа, безгә ризык биргән Хуҗа! –
Дип, сакалын селкетеп сөйли Кәҗә.

– Үзеңә мәгълүм, сиңа мин сөт бирәм;
Күп ашатсаң, аз да бирмим, күп бирәм.

Син, дөрест, ачтан мине үлтермисең,
Ни өчен җимне туярлык бирмисең?

Туймагачтын, мин караклыклар итәм,
Чит кешеләр бакчасын таптыйм, тетәм.

Урлаган чакларда, бик күп мәртәбә
Көчкә ләкми калды сыртым тәртәгә.

Бар кеше дә: «Ул Кәҗә залим, – диләр,–
Ул Кәҗәме? Ул Кәҗә!» – дип тиргиләр.

*

Китмәсен хак сүзгә һич кәйфең синең,
Күргәнең бармы Кәҗә бәйтен синең?

Әмма соң анда каты теткән мине,
Бер дә кызганмастан эт иткән мине.

Ул китапка мин ничек тәкать тотыйм?
Тыңлагыз, Хуҗам, хәзер бәйтен укыйм.

Укый:

«Ул Кәҗәнең ике исме булыр, имеш,
Бере – Кәҗә, бере Каза булыр, имеш,
Ул Кәҗәне ярлы кеше асрар, имеш,
Сыер урнына сөтен савып эчәр имди.

Ул Кәҗәнең айрылыдыр тояклары,
Бакчачендә гизәр аның аяклары;
Калмас аннан кәбестә, суган кыяклары, –
Һәр суганның башын кыркып йөрер имди.

Игътибар юк ул Кәҗәнең сакалына,
Кыйнамыйча килмәс асла гакылына;
Ул Кәҗәне кайда күрсәң, шунда кыйна, –
Язык булмас, бәлки сәвап булыр имди.

ЗУР БӘШАРӘТ!

*(Рәхмәте илаһия гомуми)*

Бәшарәт сезгә, и әһле Петербург!
Шулай ук сезгә дә, әһле Нью-Йорк!

Бәшарәт сезгә дә, и Берлин әһле!
Шулай ук сезгә шатлык, Лондон әһле!

Бәшарәт сезгә дә, карсак япуннар!
Бәшарәт сезгә, чиннәр һәм дә финнәр!

Беләмсез, калмыйсыз сез утта мәңге, –
Алыр сезне йолып Муса әфәнде!

ҖӘЙГЕ ТАҢ ХАТИРӘСЕ

*(Федоровтан мокътәбәс)*

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.

Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә;
Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.

Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм япан;
Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан.

Тын гына яткан, ялыккан, төн буенча көн көтеп,
Ялтырап, җәйлеп ята күлләр, сихерле көзге күк.

Шат үләнлекләр, тәбәссемдә чәчәкләр, ләләләр;
Сандугачлардан ява, яңгыр кеби, мәдхияләр.

Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене
Күктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң;
Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң.

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ

*(Дүртенче көлтә)*

Ала карга, кара козгын әрсезләнә, тук була;
Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит – мәчет Токиода.

Ике туры ат уйныйдыр, муйны кыйгач буйлыдыр;
Әфьюн, каптырма үтмәгәч, «Карга» язып уйныйдыр.

Кәримевләр Шакирҗаны унбиш төрле хат таный;
Бу дөньяда табалмассың аның төсле ганканы.

Кашың кара «хи» кебек, «әлеп»тәге «би» кебек;
Сотрудниклар булса булсын Хөҗҗәт, Нәүрузи кебек.

Җаңгыр җава сибәләп, төймә-төймә төймәләп;
Чыгътай мулла үкреп җылый, «тәүбә, тәүбә, тәүбә!»ләп.

**Озын көйгә дә бер җыру**

– Алма аша, җаный, ай, алма аша,
– Алма ашасам, тешем камаша.
Казан бае, махсус нумер алып,
Наташалар белән маташа.

КҮҢЕЛЛЕ СӘХИФӘЛӘР

Бакчы аучыга,

Кош аулаучыга:
Шактый читен эш –
Арый, талчыга.

Йөгрә дә чаба
Кич-иртә бердәй;
Маңлайдан ага
Тирләр яңгырдай.

Очадыр үрдәк, –
Тизрәк бул, тизрәк:
Китмәсен ерак,
Ат мылтыкны, ат!

Атты, шарт итте,
Каты җил чыкты,
Эшләпә җилгә
Очты да китте.

Үрдәк югалды,
Эшләпә калды;
Мескин эшләпә
Җәрәхәтләнде.

Аттым мин кошка,
Китмәде бушка:
Алып кайтамын
Мәҗрух эшләпә.

Көлсә көләрләр
Кешеләр, күреп;
Тишекләреннән
Җил торыр өреп.

## ИМТИЯЗ АЛГАН БАЛА

Тырышты бу бала, чын ләззәт алды инде тәхсилдән;
Югары булды урны «афәрин»нән һәм дә «тәхсин»нән.

Ни кушсаң да укый алды, ни әйтсәң, шуны язалды;
Балаларның арасында үзенә «имтияз» алды.

Беренче кәррә мөмтаз булса бер инсан туганнан соң,
Фәхерле имтиязларны алыр үскәч тә аннан соң.

## ҺӘР ЯЛТЫРАГАН АЛТЫН ТҮГЕЛ

Төнлә берлән бакчада бер аллы-гөлле Күбәләк,
Очкалап йөргәндә уйнап, анда-монда чүгәләп,

Күрде кырда: бик матур бер әллә нәрсә ялтырый,
Нурлана, җем-җем итә йолдыз шикелле, калтырый.

Күбәләкнең бер дә чик юк һәр матурга гыйшкына:
Тиз генә ул барды да кунды матур зат өстенә.

Ул матур зат юлчылардан сүнми калган ут иде:

Күбәләк булды һәлак шунда кунып – янды, көйде.

## БЕЗНЕҢ ГАИЛӘ

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи –
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

## ГАЛИ БЕЛӘН КӘҖӘ

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.

Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

## ФАТЫЙМА БЕЛӘН САНДУГАЧ

Фатыйма:

Ни өчен син сайрамыйсың, Сандугач?
Шат була күңлем минем, син сайрагач.

Читлегең әйбәт, янында бар ашың.
Ник күңелсез син болай, бөктең башың?

Сандугач:

Аһ, минем сайрар җирем урман иде,
Анда һәртөрле кызык тулган иде.

Мин бу җирдә нигә шатлык күрсәтим?
Анда өч баш кошчыгым калды ятим!

Һәм мине анда тагын дустым көтә,
Сагына ул, саргая ул, ут йота.

Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул,
Булса да алтын, һаман да читлек ул.

Фатыйма:

Йә, алайса, мин ишек ачтым сиңа:
Бар, азат бул, кыйл миңа изге дога.

Бар, җаным, инде яшел урманга оч,
Тиз ятим кошчыкларың берлән кавыш!

## ҺӘРКЕМНЕҢ АШЫЙСЫ КИЛӘ

Урман буйлап Черки очып бара иде,
Бер-бер нәрсә ашарга уйлана иде.
Шул урындук, гөнаһ шомлыкка, бер Чыпчык
Йөри иде азык эзләп, пыр-пыр очып.

Инде Черки бичараның гомре бетте:
Теге Чыпчык сиздермәстән килде тотты.
Чыпчык күптән ашамаган, бик ач иде,

Черкине ул азык итте – капты йотты.

Шул ук җирдә оча иде бер Ябалак,
Азык-фәлән юкмы диеп карангалап.
Төште аның үткен күзенә бу Чыпчык;
Ул Ябалак бу Чыпчыкка төште очып.

Инде хәзер Чыпчыкның да гомре тәмам:
Үзе хәзер Ябалакка булды тәгам.
Ябалагым бер-ике рәт чукып ертты,
Күз әчкәнчә Чыпчык та бетте, вәссәлам!

Булды пәйда әллә кайдан бер зур Бөркет,
Җил-җил иткән канатларын селкеп-селкеп.
Тотты да ул безнең батыр Ябалакны,
Тәгамләде чукып-чукып, йолкып-йолкып.

Әллә кайдан шунда килеп чыкты Аучы, –
Урманнардан ул да бер кош-корт эзләүче, –
Аучы килеп якынлашты Бөркет белән,
Атты Бөркеткә тугърылап мылтык белән.

Җәдрә тиде тугъры төзәп аткан җиргә:
Авып төште Бөркет җәдрә берлән бергә.

## ЯЛКАУ МАЭМАЙ

Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә,
Җитезләнә, уйный һаман йөгрә-өрә;
Карый миңа мәхәббәтле күзе белән,
Гүя «уйныйк» дигән була, гүя көлә.

Кайвакыт ул ята тәмле ашап туеп,
Ал аяклары өстенә башын куеп.
Аны шунда чебен халкы тынычсызлый;
Ялкау маэмай! Ул аларны тормый куып.

Чебеннәрне астан гына карап ята,
Ярты йомык күзен генә ялтырата;
Бервакыт ул колак артын торып кашый,
Чебен халкы шунда тиз-тиз кача башлый.

## ШАЯН ПЕСИ

Күрче, бик чынлап керешкән эшкә безнең Ләмига:
Бар уе – бер бик матур күлмәк тегү Курчагына.

«Күлмәгем кайчан бетәр?» – дип, Курчагы яткан, көтә;
Көтми хәл юк, бер тәти күлмәк кирәк – бәйрәм җитә.

Ә Песи яшьрен генә яткан, кәтүкне күзлидер;
«Тукта селкенмәсме?» – ди ул; бер дә җаны түзмидер.

Ул хәзер сикрер менә, хәзер тотар, хәзер басар;
Ул кәтүкне уйнатыр, уйнар, үзенә шар ясар.

Кайгысы юк ул Песинең, тик һаман уйнау уе;

Бик шаян! Ай-һай, наян! Уйнарга хәзер көн буе!

КЫЗЫКЛЫ ШӘКЕРТ

– Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

– Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

– Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңгайсыз ул!

БИЧАРА КУЯН

– И Куян, куркак Куян, йомшак Куян,
Моңланасың нинди хәсрәт, кайгыдан?

– И җаным, син яшь бала шул, белмисең;
Төште зур хәсрәт, ничек моңланмыйсың.

Без икәү: Әткә куян, Әнкә куян,
Яшь куянчыклар янә бездән туган.

Барчабыз бер гаилә булган идек,
Күп заман шатлык белән торган идек.

Яшь балаларны ашап китте Бүре,
Бик усал ерткычтыр ул, муркыргыры!

Күп тә үтми, куйды дөнья Әнкәсе;
Тулды күңлем, ничек итеп әйтәсе.

Килде дә бер явыз Аучы Эт белән,
Атты үлтерде аны мылтык белән.

Шул вакыттан бирле аш булмый ашым,
Моңланам ялгыз башым, агъзам яшем.

АК БАБАЙ

Бөтен дөнья аппак булып кар яуганда,
Ишек алды, урам, түбә агарганда,
Аппак булып кайтып килә безнең Бабай,
Безгә төрле-төрле уенчык алган да.

Шатланышып без әйтәбез: «Рәхмәт, Бабай,
Сиңа тагын күп ел гомер бирсен Ходай!»
Бабай, мескин, кар-яңгырга карамыйча,
Безне шатландырмак өчен йөри шулай.

КИЧӘ ҺӘМ БҮГЕН

Йа Ходай, көн кичә ямьсез, ә бүген, аһ, нинди көн!
Кичә сынды һәм боекты, ә бүген күңлем бөтен.

Әй кояш нурлы – ачылган бакчаларның гөлләре;
Яктылык! Рәхәт! Бәхет! Сайрый Ходай былбыллары!

## МИГЪРАҖ

Ярты төн булган чагында, китте Мәккә ялтырап:
Нур тоташты җиргә күктән, иңде нурдан бер пырак.

Хәзрәти Җибрил бәшарәт әйләде, дип: «Йа Рәсүл,
Хак Тәгалә хәзрәте тәгъйинләде бу кич вөсул.

Мөнтәзыйрләр , ля мәкяннәр , бар мәляикләр сиңа,
Гарше әгъля килде, атлансаң, аягың астына».

Садрулды шул вакытта Хактан әмер: көн фәякүн!
Шундый изге йөк белән гаршулды күкләргә рәуан!

Дөньяда һәр нәрсә дә үз аслына бер әйләнә:
Ашты кодрәтлә сәмавәткә бу кич Коръән янә.

Бәхре вәхдәт асты өсткә килде шунда, кайнады,
Бетте, мәхү улды зәмин, һәм дә замана калмады.

Калмады сурәт, бары тәбдил ителде мәгънәгә;
Әүрелеп мәгънәгә, дөнья сәҗдә кыйлды Мәүләгә.

Күрде Алланы пәйгамбәр, сәҗдә кыйлды, баш иде;
Ушбу җир булды бөтен мәсҗедләрең дә мәсҗеде.

Булды саф-саф, кыйлдылар сәҗдә мәляикләр бары;
Җәмгулып һәрбер нәби, Муса вә Гайса җаннары.

Булды заһир, белмәделәр җир йөзе мөнкирләре:
Монда габдият, гыйбадәтнең илаһи серләре.

Үтмәде керпек кагып та күз ачып йомган заман,
Мәккәгә иңде, фирашы җып-җылы ирде һаман.

Нә саташмак, нә гөман бу, нә хыял, нә төш иде, –
Бер илаһи вакыйга, могъҗиз вә серле эш иде.

## ИКЕ ИПТӘШ АРАСЫНДА

– Җәле, иптәш, ни ишеттең, бер хәбәр сөйләп җибәр;
Кайда, кемнәр нишләгәннәр? Юкмы яңа бер хәбәр?

– Китсәнә, иптәш, йөдәтмә, эшләрем бит бар минем;
Юк хәбәрләрне сөйләп тормакка вакътым тар минем!

– Сөйлә инде, ни хәбәр бар, иптәшем, назланмачы;
Әллә нидә бер соравымны да җиргә салмачы!

– Кит, димен, иптәш, йөдәтмә! Мин беләм тик: син – җүләр;
Нәрсәсен сөйлим моның мин – инде бу иске хәбәр!

## НИК? НИГӘ?

Ник, «Болакыл хак», сиңа юктыр мәхәббәт һәм мәрак?
Шул сәбәптер ки: Болак гөлдән вә рәйханнан ерак.

Нигә мәнфүр бу татарларның китап наширләре?
Бер тиен китсә, җылыйлар, агълашубән: «Әлфиракъ!»

Нигә курка бу татар, кузгалса дини мәсьәлә?
Барсы кыркылдый тавыктай: «Дин кырак! Дәһри кырак!»

Нәрсәгә каптырмачы, әфьюнчыга «Карга» язу?
Ах, мие чергән чүбек баш, ах, ишәк, ахмак, дурак!

Ник Шакирҗанел Хәмиди нам бәрәңге корсагы
«Мин беләм»лек дәгъвасын кыйлган була, салам сыйрак!

Ник бу Чыгътай «дау» ясый да, нигә соңра тәүбәсе?
Бүреләрдән куркъдисәң, урманга бармау яхшырак.

Нигә тончыкты «Чүкеч» атлы нәҗес вулканы да?
Кем атар инде бу милләтнең йөзенә былчырак?!

Ник Орынбурда урын зур төрле шахшы нәрсәгә?
«Чүкеч»е – «Чүкеч», «Мәгыйшәт» тагы бер кат шахшырак.

## КАТИЛЕ НӘФЕСКӘ

Котылмакчы булып татсыз хәяттан,
Гомергә җан авырттыргыч газаптан,

Гакыл бу дип, үзеңнүзең үтердең,
Тынычлык эзләдең дә гүргә кердең.

Вәләкин, и карендәш, алданасың,
Үзеңне мәңгелек утка саласың.

Синең тик сурәтең китте җиһаннан,
Һаман да калды рухың яки мәгънәң.

Синең бар дөньяда күргән газабың,
Гөман юктыр, бозык булганга җаның.

Әгәр рухыңны ислах итми үлсәң,
Барыбер син газапта, яхшы белсәң!

Кирәк черсен, кирәк торсын – ни ул тән?
Чыдамсыз бер кием ул җанны өрткән!

Әгәр син катле нәфситмичә торсаң,
Җаныңны изгелек берлән тутырсаң,

Ачар ирде Ходай бәхтеңне, шаять,
Ашыктың, эшләдең бик зур җинаять!

Газаб китми кабердә тән черүдән:
Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән!

## ГАЗАПТАН СОҢ

*(Майковтан мокътәбәс)*

Мин бәхетле бәндә, чөнки тормыш алдымда һаман
Барча шау-шу һәм дә барча күрнеше берлән тәмам.

Алдагы михнәтнең урнын әллә истикъбаль ала?
Тормыш инде яктырадыр, кузгала һәм җанлана.

Таң атып, чәчсә кояш нурлар – шулай ук кузгала,
Яктыра, шаулый ерак җирдән күренгән зур кала.

Үземә сөйнеч бирәм инде бәхет, гыйззәт берлән;
Уйлыймын үткән газапларны хәзер ләззәт берлән.

Булмадымы шул газаплар бәхтемең ачкычлары!
Җитмәкемнең изге максудка ләгыль баскычлары!

## АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Сөям кайчакта бер-бер иптәшемне,
Аңар мин күрсәтәм күздә яшемне.

Кыйлам изһар аңар кайгы, моңымны,
Сөйлим бер-бер барымны һәм югымны.

Күренә ул мәхәббәтле күземә,
Куяр төсле бәһа һәрбер сүземә.

Алалмыйча теким күзне күзенә,
Чыгадыр балкыган нурлар йөзенә.

Килә шунда бер аваз әллә кайдан:
«Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!

Аның тик тышкы ягын син күрәсең,
Мәхәббәтле әһәмият бирәсең.

Тышыннан кызгану күрсәтсә дә ул,
Эчендә нәрсәләр ятканы мәҗһүл.

Әгәр күрсәң аның йөзендә нурны,
Бу нурга мәгънә бир син башка төрле:

Аңар син саф күңел берлән ышандың,
Эчеңдә кайгы, хәсрәттән бушандың.

Бушанды, пакь вә саф күңлең ачылды,
Тирә-якка шуның нуры чәчелде.

Йөзендә күргәнең нур иптәшеңнең
Нурыдыр саф күңел һәм күз яшеңнең.

Кара йөз ул, кара эч ул һаман да,
Мәхәббәт һәм кешелек юктыр анда!»

Менә шул чак тәмам мин аптырыйм да,
Аваз килгән тарафка бер карыйм да:

«Аваз! – дим, – иштеләсең, әйтче, кайдан?
Фәрештә кычкырамы яки шәйтан?!»

Җавабында аваз: «Син рәнҗемә, – ди, –
Минем исмем – ачы, карт тәҗрибә», – ди.

ҖӘЙ КӨНЕНДӘ

Каты эссе. Һава бөркү. Кыза дөнья, сабыр җитми,
Җил исми аз гына да, бер генә яфракны селкетми.

Корылык һәр урыннарда. Кибә вак-вак кына күлләр,
Шиңәргә йөз тота кырда үләннәр, чәчкәләр, гөлләр.

Агачлар астына сыгъна балалар барчасы бергә,
Алай да булмаса, барсы төшәләр сикрешеп күлгә.

Алар аппак балыклар күк йөзәләр иртәдән кичкә
Кадәр шунда, туңып бетмичә ярга чыкмыйлар һич тә.

Менә шунда кисәктән йөзгә бернәрсә тиеп китте;
Сабамы, нәрсәдер, салкынчарак бер җил сөеп китте.

Якын урманның артында яшеннәр ялтырый аз-аз,
Ерактан, әллә кайдан, иштелә күк күкрәгән аваз!

МӘҖЛЕС

*(Пушкиннән)*

Мин сөям дустлар белән булган хозур мәҗлесне кич,
Шундый мәҗлес: анда хөррият белән шатлык рәис;

Торса анда иштелеп «эч, эч» дигән сүз таңгача,
Кясәләр булса тулы, без мәст булып аугангача;

Булмаса артык тыгыз эчкән кешеләрнең рәте,
Тып-тыгыз булса бушап калган шешәләрнең рәте.

ЯЗ ХӘБӘРЕ

*(Русчадан)*

Килде Ак диңгезнең артыннан очып бер карлыгач,
Кунды да ул сайрады, сайлап үзенә бер агач:

«Күпме, февраль, каш җыерсаң һәм ачулансаң да син,
Барыбер, – ди, – җитте яз һәм рухына кышның ясин».

Яз җитәдер, файдасы юктыр, күпме гайрәтләнсә март,
Халкыбыз сүзе буенча, гәрчә март итсә дә «шарт!»

Яуса да карлар, табигать эшли инде үз эшен;
Тиздән иснәрбез кызыл, ал, ак чәчәкләрнең исен.

* * *

*(Ике хатын берлә тормыш)*

Биек тауның башыннан күренәдер бер авыл;
Хатын өстенә хатын алсаң, менә шулай була ул.

КАЙЧАКТА

Була кайчак бөтен уйдан күңел буш,
Туза уйлар, мисале гыйһне мәнфүш.

Күңелдә яткучы изге хәзинә
Вакытлыча китә үз мәәхәзенә.

Бушап күңлем, була рухымда тәгътил,
Ителми берни дә тәхкыйк вә тәхлил.

Менә шул чак кешеләр шелтәлиләр:
«Нигә син язмыйсың һичнәрсә?» – диләр.

Җавабымда: «Вакыт юк, – дим аларга, –
Бушамыйм бу арада язгаларга».

Шулай кайчак кесәгезнең төбендә
Беләсез юклыгын ярты тиен дә,

Сораучыга дисез бит: «Миндә вак юк!»
Шулай ук мин дә әйтәм, дип: «Вакыт юк!»

ГОМЕР ЮЛЫНА КЕРҮЧЕЛӘРГӘ

Беләм инде, сабыйлар, сезгә мәктәптә күңелсездер,
Аның тоткынлыгыннан сез бигүк разый түгелсездер.

Сабый чакта күңелсезләнгәнем бар мин дә, һәм шунда
Очып эзли иде фикрем азатлык анда да монда.

Заман үтте. Азат булдым. Теләгем алдыма килде.
Күрәм: мин дәү кеше булдым вә мәктәптә түгел инде.

Ачылды юл, ирек алдым. Эчемнән нәрсәләр уйлыйм:
«Менә шатлык миңа, – дим, –
мин хәзер тормыш белән уйныйм.

Шаярырмын, теләрсәм нишләрем, уйнар, көләрмен, – дим, –
Бөтен мәктәптә тоткынлыкларым бурчын түләрмен», – дим.

Кереп киттем гомер юлына... Әллә мин йөри белмим?
Нидәндер анда мин шатлык, азатлыкларны һич күрмим.

Барып булмый. Ирексез тукталамын юлда кайчакта, –
Каты сызлап, бу юлымда аяклар йөрмидер хәтта!

Йөреп мин, шатлык эзләп бу гомер юлында акрынлап,
«Гомер итмәк» димәкнең мәгънәсене аңладым чынлап:

Гомер итмәк – тырышмактыр ялыкмый, һич тә ял итми,
Гаталәт хурлыгын асла үзеңә ихтыяр итми.

Тиеш, имеш, үтәргә изге юлда бу гомер барсы

Түләү берлән бурычны Тәңремә һәм халкыма каршы.

Бәхетлемен шушы хәлдән, бүтән бер хәл дә көтмимен,
Шушы юлдан ризамын, башка төрле юл да тотмыймын.

Әгәр кайчак гомер сәхраларында мин гизеп арсам,
Гомер юлында бер мәүкыйф ясап алмакны уйлансам,
Итәм дәрхаль тәвәккъыф мин сабыйлык хатиратында,
Очам мәктәп таба нурлы тәхаттырлар канатында.

Күңелдән сагынам «тоткын»лыгымны, мәктәбемне мин,
«Нигә соң үстем инде һәм нигә «дәү» булдым инде, – дим. –

Нигә, – дим, – изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым?
Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым?»

ӨМИДСЕЗЛЕК

Тәндә җаным, чык та Тәңреңә юнәл, бар, кайт кире!
Китте җаннар азыгы, һәм кайтты истибдад кире.

Көлмә син дә бу бозык дөньяга каршы та әбәд,
И кояш! Мәңгегә чыкма, бул кара тап, бат кире.

Яз башы дип, башны калкытмагыз, и гөл-ганҗәләр!
Бел, янарсыз: җир хәзер ялкынлы истибдад җире!

Калмасын дустлык, мәхәббәт, чын сөешмәк дөньяда.
Бу җәһәннәмдер, түгел Ширин илә Фәрһад җире.

Тәрке хезмәт әйләгез, үткен гакыллар, сез дәхи,
Бер дә тугъмаслык булып бат син дә, истигъдад, кире.

Сез дә, и мөһлик мәрыйзләр, урныгызны ташлагыз,
Барчагызны мөштәмилдер кайтты истибдад чире.

Сез дә, мәзлумнәр гөруһы, хак өчен кул сузмагыз,
Тик кыямәт көнгә калды хаклар истирдад кире.

Гыйш-гыйшрәтләр, музыка, тансалар, уйнау-көлү –
Барчасы бетсен хәзер, җир чөнки тик фөрьяд җире.

И каләм, син хакны язма, күз буя, юк-барны яз,
Бумыни соң тугъры әшгарны язып иншад җире?!

ХАЛЕ ХАЗИР

Белми үзсүзле мәрыйз имләт дигән сүз кадрене,
Аңламас беткән сәфил гыйззәт дигән сүз кадрене.
Белми хайваннар да инсият дигән сүз кадрене,
Һәм тупаслар белми шигърият дигән сүз кадрене.
Белми хикмәтсез кеше хикмәт дигән сүз кадрене,
Таш күңелләр аңламас рикъкать дигән сүз кадрене.
Кап-кара кол белми хөррият дигән сүз кадрене,
Һәм түбән рухлар да – кодсият дигән сүз кадрене.

*

Күрсәтә һәрбер җаһил милләткә золм вә җәбрене,
Таптыйлар пычрак аяклар берлә милләт садрыне.
Бер генә милли бәхетнең безгә көлгән вакъты юк,
Искеләр белми һәнүз милләт дигән сүз кадрене.

ҮКЕНЕЧ

Электән белгәнем хәлдә кешенең
Тышы яхшы, бозыклыгын эченең,

Ничек соң мин адаштым изге юлны,
Биреп мәлгунь, ходайсызларга кулны?!

Нигә мин, алданып ялган көлүгә,
Нифакъ иттем үземдәге голүгә?!

Нигә булды зыя сөйгән азат баш
Монафикълар караңгысында хәффаш?!

Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз –
Ничек күктә яна бер данә йолдыз?

Шулай янсам, ни булды, төшми җиргә,
Якынлашмыйча һәр мәгърур сәфилгә!

Янып ялгыз шулай, күп еллар үткәч,
Сүнәр идем, Ходайдан вәгъдә җиткәч.

Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге,
Күңелсез һәр ягым – нурсыз, караңгы!

Монафикълар камап һәр дүрт ягымны,
Күрәлмим мин кояшым һәм аемны.

Кырылды алда изге эшкә вәгъдәм,
Караңгыда күренми чөнки кәгъбәм!

Һава юктыр, алалмый рух сулыш та,
Кабахәт бөркү уң, сул, аста, өстә.

Читен хәл. Гайрәтең җитсә – ерып чык,
Әгәр җитмәс исә – бет, шунда тончык!

ХАСИЯТ

Сөйләшсәк төрле милләтләр хакында,
Ерактамы алар яйсә якында,
Сөйлибез төрле сүзләр хакларында
Вә кайсысында ни хасләт – барын да.

Итеп иснад аларга милек вә малны:
«Фәлән милләт фәләнле һәм фәләнле».
Дибез госманлылар тугърында: «шанлы».
Немец халкы хосусында: «кораллы».

Яһүд халкы хосусында сөйләшсәк,
Дибез: «гаять җитез һәм эшкә җайлы».

Кытайлар тугърысында сүз ачылса:
«Алар, дибез, гүзәл һәм яхшы чәйле».

Әгәр телгә төшә калса фырансуз,
Дибез: «гаять һөнәрмәнд һәм дә җанлы».
Арабызда сөйләнсә ингелизләр,
Дибез: «бик иҗтиһадлы һәм дә маллы».

Ни дирсең, сүз татар тугърында булса?
Табалмый сүз, диерсең: «ул – сакаллы».

ЯШЬЛӘР

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.

Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.

Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,
Көмеш, алтын санәмнәргә табынмас?

Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.

Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңлен дә салмас.

Сатучылык итә бездә мөхәррир,
Әдип исме аңар тагълыр-тагылмас.

Яралганмы бу яшьләр күңле әллә
Мөрәүвәт маддәсе ягълыр-ягылмас?

Ышанабыз халык көчсезлегенә,
Бабайлар шөһрәтен сагъныр-сагынмас.

Тотып милләт ливасын, юлга чыктык:
«Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».

Җыгылдык без икөч чакрым да китми, –
Җегетләр! Бездә көч юк, – ахры, булмас!

ТАНСА

Танса таушы зал эчендә төн ката,
Уйный оркестр: «Трим-там-там-та-та!»
Барча кулларда чуар чүпләр тулы:
Өч хатын почмакта конфетти сата.

Бик хозур эшләр, халык хәйрәт итә,
Мактый һәркем: «Әттә-тәттә-тәттә-тә!»
Мактаган саен, идәндә сикрәләр –
«Тып та тып!» – пар яшь кәҗә берлән тәкә!

ИССЕЗ ЧӘЧӘК

*(Русчадан)*

Болынлыкта үсәр гади генә, иссез чәчәк, яңлыш
Гүзәл исле чәчәкләр бәйләменә бергә бәйләнмеш.

Ярар, бәйләнгән ул анда, соңыннан нәрсә булган соң? –
Булып киткән үзе хуш исле бик аз бер заманнан соң.

*

Шуның күк, безне тәүфикъле дуст-ишләр һәм белешләр дә
Өйрәтерләр гүзәл гадәткә һәм дә изге эшләргә.

## СИБГАТУЛЛИН

Бер җегет, шәмдәй, буен катрып йөри,
Алга, дип, милләт, сине чакрып йөри;
Белмисең, милләт, синең хаккың өчен
Нинди җырлар ул җегет шапрып йөри.

Ул синеңчөн, милләтем, атлып йөри,
Армый-талмый, көн вә төн ватлып йөри;
Җаны һәм вөҗданы шул юлда фида:
Кайда бай күрсә, шуңар сатлып йөри.

Кайда барса, шунда «милләт» дип йөри,
«Мин – мөхәррир һәм дә бик шәп!» дип йөри,
Инде дә, милләт, тәрәкъкый итмәсәң,
Ресторannарга кереп акрып йөри!

## КҮГӘРЧЕН

*(Русчадан)*

Бер урманда агач астында, яшьрен,
Качып утыра иде мескин Күгәрчен.

Якыннан шул вакытта узды Лачын,
Җәеп, селкеп канат атлы колачын.

Эченнән сөйләде шунда Күгәрчен:
«Бу Лачын нинди көчле кош, күрәмсең?

Көче күп, тырнагы үткен, явыз ул,
Зәгыйфьләрне ашар, канлы авыз ул.

Вәләкин мин ризамын язмышымнан,
Ходай кыйлган мине көчсез кошыннан:

Зәгыйфь, корбан булу артык, Ходаем,
Булудан андан көчле һәм дә залим!»

## БАСКЫЧ

Сөялгән, өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч,
Кырыклап басмасы бар – бик авыр һәм дә озын баскыч.

Кирәклектә бәрабәр булсалар да басмалар бергә,
Югаргы басма тиңләшми түбәнге басмалар берлә.

Югаргы басма мәгърур: «Мин югары, сез түбәнсез, – ди, –
Ничек гали минем урным, түбәнгеләр, күрәмсез?» – ди.

Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны:
Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.

БЕР МӘН

Итәм кайчак бөтен инсанга нәфрәт,
Бу нәфрәттән туа күңлемдә хәсрәт.

Тула күкрәк ачы, яшьрен зәһәргә,
Ачу зәһре ага җан берлә тәнгә.

Сөеп тә алданып бер мәнне җандай,
Чәчә зәһрен күңел мәҗрух җыландай.

Бөтен инсан вә җир, күккә, нөҗүмгә
Күңел башлый, котырган күк, һөҗүмгә.

Өмидсезлек, усаллык, вәсвәсәләр
Зәгыйфь җанны теләләр һәм кисәләр.

Өзеп барлык хәятымнан өмидне,
Димен: «Аһ! бар да бетте, бар да бетте!»

Димен: «Җирдә мәхәббәткә урын юк
Вә булмас, булмагандыр ул борындук!»

Менә шул чак керешеп эшкә, гакълым
Кушадыр тикшерергә хәлнең аслын:

– Кара, – ди, – әйлә син дөньяга дикъкать,
Бөтенләй сүнмәгән анда мәхәббәт.

Кара эзләп, табарсың син җиһаннан,
Бөтенләй китмәгән кодсият аннан.

Җәмигы әнбиянең мәһде – дөнья,
Вә барча әүлиянең ләхде – дөнья!»

Фәкать бу сүзгә күңлем һич ышанмый
Вә нәфрәт вәхшәтен һич ташлый алмый.

Менә шул чакта, һич ис итмәгәндә,
Явызланган күңел хис итмәгәндә,

Ничектер табыла дөньяда бер мән,
Тулы күңле мәхәббәт хисе берлән.

Мөҗәссәм бер кешелек ул җылы җан,
Аны тәкрим вә тәкъдисне тели җан.

Аның берлән, итеп сохбәт, сөйләшсәм,
Яшермәстән бөтен күңлемне ачсам,

Бетәдер ярасы рухның вә хиснең,

Тигәндәй куллары гүя мәсихнең.

Сөйләшкән сүзләре гөлдәй тамадыр,
Сулаган сулышы баде сабадыр.

Тисә киеме генә яңлыш тәнемгә,
Туадыр бихисап шатлык җанымда.

Була җанга хозур буултырышта,
Сөйгән төсле канат берлән фәрештә.

Менә шунда ачы яшьләр түгәм мин,
Дәсисә, вәсвәсәләрдән чыгам мин.

Тибәр күңлем моңарчы бер ләгыйньчә
Тибәдер «рәхмәтән лил-галәмин»чә.

## МӨБАРӘК ТӘСБИХ ӨЗЕЛДЕ

Ушбуны яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве,
Мәсьәлә бик зур – сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве.

Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин Русия кояшы, бүтән еллардагыча, нурын киметми, дөнья йөзенә чыраен сытып, салкынлык бирергә ашыкмый.

Бу ел ноябрь ае керде. Русиянең агар сулары бозланмый, һаман ага да ага.

Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин Русия көз көненә махсус ачы вә үзәк өзгеч җилләр исми.

Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин кыйбла якның кошлары китми.

Бу ел бөтен табигатькә ят бер хәл вакыйгъ булган. Бер олугъ һәлакәт булачагын алдан сизгән җанварлар кеби, галәме табигать тирән бер хәвеф вә дәһшәт эчендә.

Тавыш та, тын да юк!

Бу тугърыда халык уйлый, аптырый. Ләкин бу хәлнең сәбәбен белә алмый.

Бөтен җанварларның җаны вә бөтен инсаннар вөҗданы кадерле вә бәһале Толстой җәнабләре түшәктә!

Үләрме бу мөхтәрәм шәех? Әллә терелерме?

Тагы берничә генә ел артык дөнья халкы күңеленә кодсият нуры чәчүендә дәвам итәрме?

Менә галәме табигать хәвеф вә изтираб тулган бер сөкүнәт эчендә шушы ике сөальгә җәнабе Хода тарафыннан ничек дип җавап киләчәген көтә.

Бөтен табигать, мөхтәрәм шәех гафиәт тапса, дип, нәзерләр әйтә;

Кояш, Толстой терелсә, дөньяга кыш буласы айларда да көлеп, шатланып кына карармын, салкыннар ясамам, ди.

Агар сулар һаман, көзгә карамыйча, агарга, ачы җилләр дә исмәскә сүз биргәннәр.

Кошлар да агач башларын чуарлап кунышканнар, гадәттәгечә шаулашмыйлар, алар да тын гына фаҗигъ бер вакыйга көтәләр. Толстой хәзрәтләре терелсә, һаман Русиядә калып, кыйбла якларына канат селекмәскә гаһед итешкәннәр.

Куркынычлы, үзәк өзгеч хәбәр фаш булды.

Толстой вафат!

Кояш йөзен чытты. Агълады. Инде көлми. Агар сулар дәфгатән бозландылар.

Ачы җилләр исеп, котырып китеп, агач башындагы кошларны кыйблага сөрделәр.

Караңгы. Күңелсез. Салкын.

*

Андреев, Максим Горький, Потапенко, Куприн, Сологуб, Мережковский, Григорий Петров, Скиталец вә гайре, вә гайре бөтен Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбарәк тәсбихнең очындагы бисмилласы, Мәрьям анасы яки имамы өзелде.

Италиядә һушы китеп егылган Максим Горький шул мөбарәк тәсбихтән өзелеп төшкән бер төймә иде.

## АКТЫК ТАМЧЫ ЯШЬ

Бик юашлатты мине яшьрен сөюдән җан көю,
Бар иде булган чагым хәтта арысланнан кыю!

Һәр теләккә килде тәкъдирем белән бәхтем кире,
Мондый хәлгә сабриталмас, булса да адәм дию.

Инде күңлем кясәсеннән яшьне түкмәккә җитә
Уйлаган вакътымда аңсыздан килеп тә «һай!» дию.

Үлде рух яшьрен мәхәббәттән, – хафа юк үлсә дә, –
Нишлим, иркәм кәйфенә килгәч шулай бер җан кыю!

## ГРАММОФОНДА ТАТАР ҖЫРЛАРЫ

Тынычлыкны боза аның әче таушы,
Килә аннан, бер тыңласаң, мәче таушы;
Бер тыңласаң, чинау килә; бер тыңласаң, –
Майламаган арба тәгәрмәче таушы!

## ИТ БАЗАРЫНДА ТӘРӘКЪКЫЙ

Җиһанда «сез» сүзе бар «без»гә каршы,
Шикәр, бал бар керән һәм тозга каршы.

Мокабил барча әшья бер-беренә:
«Бәянелхак» чыга «Йолдыз»га каршы.

Әгәр тезсәм, тезәргә күп мисаллар:
Караңгы төн туа көндезгә каршы.

Вә «Ялт-йолт» та һәр унбиш көн саен бер
Чыга тәмсез «Чүкеч» һәм «Без»гә каршы,

Мөселман казлыгы чыккан базарга –
Шәригатьтә хәрам дуңгызга каршы.

* * *

Сәгатьләр келт-келт итәдер, төн уртасы җитәдер;
Йокласа да курка, мескин, – исрек ирен көтәдер.

## ЕЛНЫҢ ДҮРТ ФАСЫЛЫ

*(Русчадан)*

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде;
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт? –
Йә, әйтеп кара.

*(Яз көне)*

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.

Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура, –
Бу кайчак була?

*(Җәй көне)*

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, –
Бу кайчак була?

*(Көз көне)*

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран, –
Бу кайчак, туган?

*(Кыш көне)*

## ТӨШ

*(Гетедән)*

Мин төш күрдем. Гүя мин бер зур шаһ, имеш,
Таҗыма тезгән энҗе, мәрҗән, ахак, имеш;
Сине сөеп, шигырь сөйләп, шагыйрь булып
Йөрүләрем бөтенләй үк нахак, имеш.

Таҗлы башым хозурыңда иям, имеш,
«Җанашым, мин сине сөям», – диям, имеш;
Нәрсә генә әйтер инде сөйгәнем дип,
Эчемнән бик янам, имеш, көям, имеш.

Әтрафымны чолгап алган гаскәрләр дә
Гөл йөзеңә күзләрене теккән бар да;
Минем өчен синнән шәфкать булырмы дип,
Бөтен гаскәр тын да алмый интизарда...

Төш шул төшкә җиткәч, шагыйрь уянды да,
«Явыз язмыш!» – диеп азрак уйланды да,
Уйларга да өлгермәде, мескин гашыйк,
Кайнар яшькә ике күзе чыланды да!

Бераздан соң килде аңар шатлык янә:
Егъласам мин, егъладым, ди, шашып кына;
Мәхәббәтем һаман иске мәхәббәт ич,
Югалтсам мин, югалттым, ди, шаһлык кына.

## ӨЗЕЛГӘН ӨМИД

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе;

Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урынында анда тулган айның яктысы.

Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.

И мөкаддәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барсы корган – бер генә юк җанлысы, яфраклысы.

Булмадың, алтын ярым – салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә, егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

## КАЙДА? КЕМ?

Кем, дисез, бу фетнәле эшләр башы?
Кайда бу хаксызга тәфтишләр башы?

Кем җигә безгә тәдәнни арбасы?
Кемгә ләгънәт әйтәсе һәм каргасы?

Бәдбәхет, мәлгунь кеше кем, дустларым? –
Бер авылның чалмалы карт марҗасы!

## ТӘЛӘҺҺЕФ

Мәлганәт, пычрак вә ялган берлә тулган безнең эч;
Бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбарәт безнең эш.

Шаккатабыз тышкы зиннәтләр, киемнәргә карап;
Җан сатабыз әллә нинди вак «тиен»нәргә карап.

Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк;
Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?!

## ӨЙЛӘНҮ – ТҮГЕЛ СӨЙЛӘНҮ

(*Иванов-Классиктан*)

– Кара, иптәш, сиңа килдем киңәшкә:
Күз аттым мин бүген бер шәп кәләшкә.

Ни дирсең син, әгәр дә мин өйләнсәм,
Кеше төсле урынлашсам, көйләнсәм?

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Матур, якты гомер бирсен Ходаем.

– Шулай димсең? Шулаен ул шулай да,
Ярый ла эш барып торса уңайга.

Хатын алмак читен бит һәм мәшәкъкать,
Бер алгач, булмый бит, шәйтанны, ташлап.

Бөтенләй бәйләнә анда аяк-кул,
Җүләрлек ул – өйләнмәк, гайре мәгъкуль.

– Алайса, көчләми һичкем, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә!

– Шулай димсең? Шулаен ул шулай ла,
Әгәр дә охшаса ул тулган айга!

Фәрештә күк көлеп алдыңда торса,
Вә, туптай, киң кочакка ул атылса!

Шулай булгач, ничек алмый түзәрмен, –
Алам мин, бәлки, рәхәттә йөзәрмен.

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Сәгадәтле гомер бирсен Ходаем.

– Шулай димсең? Шулаен ул шулай да,
Ярый ла эш барып чыкса уңайга.

Хатыннарны сөюче бер матур яшь
Минем ярны сөюдә булса көндәш;

Сөеп китсә хатын һәм ул җегетне,
Читен тормыш: бер айда бар да бетте!

– Алайса, көчләмәс һичкем, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә.

– Өйләнмим, – дим, «өйләнмим» ул матур сүз,
Читен шул дөньяда тормак хатынсыз.

Ятасың боз кебек салкын түшәктә,
Гүя син бу җиһанга килмешәк лә!

Бүленми эш тә бер мәгълүм вакытка,
Бу хәлләр бик ерак, иптәш, бәхеткә!

Кәләшкә мин бүгеннән яучы салсам,
Озак үтми аның куйнына барсам,

Җылы куллар белән ул тәнне сарса! –
Бәхет шул, эзләмим мин башка нәрсә.

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Җылы, якты гомер бирсен Ходаем.

– Шулай ла, ул әгәр дә иркә булса?
Тәкәббер бер кабарган күркә булса?

Риза булмый минем тапкан табышка,
Сәбәп булса һаман юк-бар тавышка?

Риза булмый минем алган киемгә,
Төшерсә ул кесә якны кыенга?

Ире кем? Баймы, юкмы, белми хәлен,
«Китер!» – дип дауласа зәңгәр вә алын?!

– Шулай, иптәш, алай куркъсаң, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә.

– Шулай да бит ата булмак күңелле,
Бөтенләй шат итә ул хәл күңелне.

Балаң йөгреп менә алга «әти!» дип,
«Китер, әткәй, миңа мәммәм! тәти!» – дип.

Бу хәл, иптәш, җуатмасмы күңелне,
Бөтен рәхәт, хозур шунда түгелме?

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Әти булмак насыйп итсен Ходаем.

– Шулай да, соң балаң булса биш-алты,
Өең тулса шулардан һәм каралты?

Шуларны туйдырамын, дип тирең түк,
Иел җиргә, дуга төсле, билең бөк.

– Алай булса, хатынсыз тор, өйләнмә,
«Киңәш бир дә фәлән бир», – дип сөйләнмә.

– Шулай да, ул балалар үссә бар да,
Әгәр дә җир җиләктәй пешсә бар да?

Таянып яшь гакылга һәм дә көчкә,
Керешсә һәрбере бер яхшы эшкә;

Баеп китсә алар шул эш юлында? –
Итәрләр тәрбия картлык көнемдә.

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Тыныч картлык насыйп итсен Ходаем.

– Шулай, ләкин кирегә ишсә язмыш?
Үлеп китсә хатын, күп тормый, яңлыш?

Биш-алты яшь бала калса кулыңда, –
Менә инде чокыр тормыш юлында!

Тынычлык юк аларның борчуыннан,
Колагың тык аларның чыр-чуыннан!

Менә, иптәш, бу эшкә аптырыйм мин,
Бу уйны уйлагач та калтырыйм мин!

– Алай булгач, куша чорт, һич өйләнмә,
«Киңәш бир», – дип йөдәтмә һәм сөйләнмә!

Диим бер сүз, бүтән бер сүз дә катмам:
«Хатын алсаң, кирәк ит көн дә батман!»

...ГА

Бул кеше: байбәтчәләрнең калдыгы хәмрен көтеп,
Алты еллык образованьеңне йөрмә селкетеп!

* * *

Кушмый ишан хилкасендә
Бик мактыйлар шуларны:
Прахут Мәхүб, Чаршау Биби,
Гыйлаҗ абзаң Сәрвәри.

**1911**

БОРЫН

*(Русчадан)*

Электә бер кешедә бар иде киң бит, зур ындырдай,
Аның нәкъ уртасында бер борын һәм зур чөгендердәй.

Тәкәббер бу борын, китми исе һич башка мәхлукка;
Олугълыкны сөя торган, чөя торган үзен күккә.

Борын тәхкыйрь итә торган иде бигрәк аякларны,
Диеп: «Сез бик түбән җирдә, ерасыз былчыракларны».

Борынның сахибе бер көн чыга яңгырлы көн юлга,
Каядыр ул бара, һич тә борылмый уңга һәм сулга.

Егылды ул кисәктән, чөнки баткактан аяк тайды, –
Тәкәббер зур борын бик шәп кенә баткакка капланды!

КУШМЫЙ ИШӘК ҖЫРЛЫЙ

Кашың кара – кәкере, буең зифа – бөкере;
Кайдан чыгып бәла булды җәдид каһәр төшкере?

Алмагачта алма сирәк, җыеп ашарга кирәк;
Җәдидләрнең башлыкларын җыеп асарга кирәк.

Бакча эчемдә пар каен, яра яфрак ел саен;
Кочак-кочак доносларны яудырамын көн саен.

Йөгреп кердем бакчага, бастым бакыр акчага;
Әптрәхмәнем бар чагында аптырамам акчага.

Кабан күле өстендә байлар аты юргалый;
Ишан булып йөргән чакта, шундый хәлләр булгалый.

Хай михайлыйм хайларга, без керештек байларга;
Мөселманнарны сатамыз чәчле абзыйкайларга!

* * *

Төркия янгын эчендә: монда ут һәм анда ут;
Анда дерзиләр кабынган, монда сүнсә – арнаут.

...ГА

Шома тормыш юлында гизгәнеңдә яңлышып тайсаң,
Йөзеңнең дәфтәренә син хатаән кер вә тап салсаң,

«Кабахәт», «бәдбәхет», «җүнсез» кеби күп ямьсез ат алсаң,
Сине ташлап бөтен дөнья, үзең ялгыз фәкать калсаң, –

Белеп тор: мин чыгармын таш күңелләләр арасыннан,
Көлеп тормам, карап читтән, синең бәхтең карасыннан.

Бүләрмен, бергәләрмен барча кайгы, моң вә аһыңны,
Сиңа дошманлык итмәм мин, алып күзгә «гөнаһ»ыңны.

Халык ләкин сиңа иткән үзенең хөкмене бозмас,
Егылганнарга кул бирмәс, батып барганга җеп сузмас.

Җәза бирми халык һич тә гөнаһ эш, яшьрен эшләргә,
Куша анчак кеше сизмәс рәвештә яшьрен эшләргә!

Җәзалау камчысын биргән гөнаһлы ул халыкка кем?
Түгел, юк! Бирмәгән һичкем; Ходай – гадил,
 Ходай – хаким!

Икәү без, бер дә тилмермә халыкка, сөймәсен барсын,
Аның күк тиз сүнә торган сөюдә ни хәер бар соң!

Оныт барсын – бөтен хәсрәт вә моң-зарыңны тын эчтән,
Хозур да эзләмә инсаф вә вөҗдан кушмаган эштән.

Моны яздым, киңәш бирдем, юаттым һәм тыйдым, куштым;
Шулай булмыйча хәл юк, инде калган мин генә дустың!

МИЯУБИКӘ

**Йокы**

Ал аякларга башын куйган да йоклый, төш күрә;
Төштә дә тычкан, күсе халкы белән ул эш күрә.

Бер күсе йөгрә, имеш тә, бу куган төсле була
Һәм куып җиткән дә муйныннан буган төсле була.

Читтәрәк өч-дүрт песи чыпчыклар аулыйлар, имеш;
Өй түбәсендә җыелганнар, мыраулыйлар, имеш.

Һич бозучы юк кәефне, эт тә куркытмый өреп.
Бик тынычлык. Тик ята ул, төрле тәмле төш күреп.

**Уяну**

Торды, исни инде ул, бик зур итеп аузын ачып,
Арт аяк һәм ал тәпиләрне идәнгә нык басып.

Тырпаеп киткән мыеклар һәм югарырак башы;
Нәкъ дуга күк бөкрәеп киткән песинең аркасы.

Күз йомык, тынлык бөтен як, бер дә ул-бу юк әле;
Башта да яхшы-яманнан һич тә бер уй юк әле.

Бу – йокы ялкаулыгыннан киерелеп иснәү генә,
Бар песиләр һәм кешеләрчә бер эш эшләү генә.

**Акыллыбашланып уйлану һәм әсәрләнү**

Ул утырган бик матурлап һәм акыллыбашланып;
Уйга чумган, җиргә күз теккән, җиһаннан баш алып.

Һич белер хәл юк ниләрне уйлаганын гакълының, –
Әллә уйлыймы тәрәкъкыйсен песиләр халкының?

Үз-үзеннән нигә ләкми кулга тычканнар, диме?
Тәмле кошларга канатлар нигә чыкканнар, диме?

Әллә инде ник тиялмим йортта үрдәк, казга, ди?
Сөт эчәргә кайсы чакта төшкәлим ич базга, ди?

Әллә инде кич ашаган тәмле ашын уйлыймы?
Әллә бу көнге үзенең карны ачын уйлыймы?

Тукта, чү, шунда якында әллә нәрсә селкенә, –
Бетте уй, инде песинең ауга күңеле җилкенә.

Әллә тычканмы мич астында чыелдап кычкыра?
Бер күсе мәллә идәннең тактасын кимреп кыра?

Үрмәкүч сузганмы әллә шунда бер төшкә җебен?
Тибрәнә, чыр-чыр итәме шунда ләккән бер чебен?

Белмимен ни булганын, белсен песиләр үзләре,
Мин күрәм тик: ялтырый инде песинең күзләре.

**Нечкәләп карау**

Нинди күзләрне зурайткан, ачкан инде шар кеби,
Шул тирәдә бик кирәкле бер кызык хәл бар кеби.

Бер кирәкле эш песигә шунда бар, чынлап та бар;
Ни була инде хәзер: шатлык вә йә кайгы аңар?

Ут алынган өй эчендә, яктылык алган залын;
Бай хатыны көзге алдында төзәтә калфагын.

Кайдадыр, кемнәрдә бардыр бу кичә парлы кунак;
Ул күренмәкче буладыр шул кунакта яхшырак.

Йә оныткан ул хатын, яки песине күрмәгән, –
Ни сәбәптәндер песигә кичке ашын бирмәгән!

Кайгысы безнең песинең тик бары шул нәрсәчөн,
Күзләре булган тишәрлек һәр караган нәрсәсен.

**Шатлыклы уй, хәсрәт һәм кайгы**

Нинди елмайган авызлар! Күрсәнә, ул нинди шат!
Килсен асты өсткә дөнья, һич тә итмәс илтифат.

Тел очында бар бугай бер бик кызык, үткен сүзе;
Ни сәбәптәндер яшергән, әйтәсе килми үзе.

Нәрсә булган соң песигә? Үзгәрә шундук рәсем:
Аз вакытта кайгыру алган чыраен, чәһрәсен.

Ул берәүне, кемнедер, алдарга булгандыр көлеп,
Шул көлүгә каршы бер калҗа бирерләр, дип белеп.

Бушка киткән көлгәне дә, бирмәгәннәр калҗаны;
Шул сәбәптән кайгыра ул, рәнҗи шунлыктан җаны!

**Зарлану һәм гаҗәпләнү, намәгълүм бернәрсәдән әсәрләнү**

Карны бик ачкан песинең, бирмәгән һичкем дә аш,
Кызганыч, моңлы мияулый, егълый, мескин, күздә яшь!

Карны ачлык хәсрәте, инде хәзер үзгәрде төс;
Төскә хәсрәт билгесе чыккан хәзер нинди дөрес.

Нәрсәдер читтә, ерак, шунда шытырдый башлады,
Инде онтылды песинең егълавы һәм яшьләре.

Шул шытырдау нәрсә? дип тыңлый, утырган яхшылап,
Күзләре читкә акайган, һәм дә бик торган колак.

Ни икән соң ул шытырдаучы вә нинди җан икән?
Ул әле яшьрен: песигә дуст микән, дошман микән?

**Юри генә исе китмәгәнгә салышу**

Куйдылар инде шикәр каткан җылы сөтне аңар;
Күрсәтә шундый кыяфәт: ул исе китми аңар.

Бик ашыйсы килсә дә һәм барса да ачтан үлеп,
Сузла ул ашка ашыкмый, бик суфиланган булып.

Ул күренмәкче була инде тамагы тук кеби;
Күп ашау, ачкүзлелек бер дә үзендә юк кеби.

Чөнки ул ачкүзлелектән күп кыен алган иде,
Шул кыен күңлендә онтылмас булып калган иде.

**Һөҗүмгә хәзерләнү, туклык ялкаулыгы**

Артка салган ул колагын, җиргә яткан ау өчен –
Ни генә селкенсә дә, сикреп барып аулау өчен.

Әллә тычканның оядан күрдеме койрык очын,
Мондый тайярлык вә саклык нәрсәгә һәм ни өчен?

Өстериләрме шаяннар җепкә таккан бер кәгазь?
Нәрсәдер бар, ул һөҗүмен бер дә юкка эшләмәс!

Күрсәгез күз алдыгызда бер песи рәсме шул ук,
Ул ята ялкауланып, аштан соң инде карны тук.

Хәл җыя рәхәт кенә, ирнеп кенә һәм тын гына,
Күзләре йомлып бара инде аның әкрен генә!

Йокласын ул, и шаяннар! Сез аңар сүз катмагыз;
Торгач уйнарсыз, йокысын бүлдереп уйнатмагыз!

**Аналык шәфкате!**

Нинди шәфкать! Өстенә баксаң, күңелләр нечкәрә,
Мондый хәл күргәч, күңелләрдә мәхәббәт көчләнә.

Үз баласын ул юа, пакьли, теле берлән ялый,
«Бәбкәем! – дип, – күз нурым!» – дип, яшь баласын
иркәли.

Ул, җитез, йөгрек песилектән чыгып, инде ана,
Һәр ике җанны күңел инде сөя һәм кызгана.

**Рәхәт кенә калыгу, гаҗәпләнү**

Дикъкать иткән, күзне теккән әллә нинди нәрсәгә,
Ни гаҗәп булган песигә? Башта нинди мәсьәлә?

Башта тулган төрле уйлар, зиһне эшли бик каты,
Күзләрен күргән кешегә билгеледер дикъкате.

Ул гаҗәпле мәсьәләне уйлый-уйлый баш арып,
Калды ул инде тынычлыкка вә рәхәткә талып.

**Ачу аралаш курку, чын курку**

Бу ике баш өстенә әллә күтәрелгән таяк?
Кайсы чакта ул таяк тормый «песиләр» дип аяп!

Бик кәеф киткән песиләрнең, икәүләп куркалар;
Тик бераз бу куркуларның бер-береннән фәркы бар:

Бер песи дошманга азрак каршылашмакчы була,
Берсе һич тә каршы тормый, читкә качмакчы була.

**Ләззәтләнү һәм хозурлану, куркыныч һәм каһәрләнү**

Аркадан, баштан сыйпыйлар, и күңелле! и хозур!
Инде ләззәт, иркәлекләр, күр, песидә нинди зур!

Зур бәхетлелек вә шатлык аңлата көлгән төсе,
Бик хозурлыктан ачылган аузының да яртысы.

Кәйфенең бик шәплегеннән кәкрәеп киткән башы,
Күзгә дә килгән олугъ шатлык вә рәхәттән яше.

И кызык соң бу җиһанда! Шәп торамын, ди, бугай;
Ни кирәк булса, шуңарга аптырамыйм, ди, бугай.

Ул шулай инде, вәләкин бер көе тормый җиһан:
Ул җиһан шатлык белән хәсрәтне бер җиргә җыйган.

Басты аңсыздан, килеп, койрыкка шунда әллә кем,
Орды камчы аркага һич юкка гына әллә кем.

Инде һәртөрле зәһәрләр һәм каһәрләрдән эче
Туп-тулы булды песинең, кайраладыр һәр теше.

Һәм үрә торды, кабарды бар тәненең һәр төге,
Үч алу дәртендә гүя һәр төгенең бөртеге!

**Барсы да бетте!**

Фани дөнья! Нинди эшләр эшлисең син – шак та кат!
Шундый шат уйнап, көлеп йөргән песи инде вафат!

Бу хәбәр тизлек белән читкә җәелгәндер хәзер,
Һәм идән астында шатлыклар вә бәйрәмдер хәзер.

Ул йөриләрдер күселәр шатланып, җырлап, биеп!
«Бәдбәхет, залим песи, син тар кабердә ят!» – диеп.

**Мәрсия**

Күчтең инде дөньябыздан ахирәткә, хуш, песи!
Байлыгы берлән иманның, изгелектә күч, песи!

Сау чагында күп золым кыйлсаң да тычканнарга син,
Бик тыныч бул, ярлыкар Алла гафур һәм гафве киң.

Дөньяда иттең зарарлы нәрсәләргә сакчылык,
Шул сәбәпле дәфтәреңдә, бәлки, күптер яхшылык.

Шунда да бик кызгана, мәрхүм, сине инде күңел,
Инде синнән куркъмыйлар кортлар да – тычканнар түгел!

Кайвакыт ялгыз чагымда зур юаныч син идең,
Һәм шаярып көлдерә торган куаныч син идең.

Мич башында йоклаган чакта бабай гыр-гыр килеп,
Син дә йоклыйдыр идең бер читтәрәк мыр-мыр килеп.

Көн буе уйный идек без; һич тә тик тормый идең,
Кулларымны, һич авырттырмый, юри тырный идең.

Кайвакыт урлап ашасаң син бәлешләр, сумсалар,
Һәм сине: «ник урладың?» – дип, орсалар йә суксалар, –

Шәфкатемнән мин җылап йөгрә идем тиз әнкәмә,
Ялварып: «Әнкәй, песигә сукма һәм, зинһар, тимә!»

Һай, гомерләр үтте китте, кайда китте ул заман?
Бу җиһанның дустны дустан айруы бигрәк яман.

Булсын инде якты кабрең, бирсен Алла яхшы хәл,
Һәм кыяматтә мине күрсәң, мыраулап каршы ал!

## АНА ИЛӘ БАЛА

– Җавап бирсәң икән, әнкәй, минем әйткән сөальләргә,
Гаҗәпләндем бу дөньяга вә анда барча хәлләргә:
Ничек булган, ничек үскән хисапсыз дәү бу урманнар?
Бу һәйбәт ямь-яшел кырлар каян килгән вә булганнар?
Вә һәртөрле үсемлекләр бизәнгән чәчәкләр берлә,
Вә төрле күбәләкләр дә күңел ачкан алар берлә,
Агар су, татлы, салкын, саф гаҗәиб чишмәләр, күлләр,
Куаклыкларда сайрар сандугачлар һәм дә былбыллар,
Суда йөзгән балыклар һәм үсеп торган бу зур таулар,
Чебен, черки вә ерткычлар, кәҗә, ат, барча җанварлар?

– Яраткан, әйләгән мәүҗүд боларның барчасын Тәңрең,
Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән, бәгърем.

## КАРГА

Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шигъре бар.
Карга, мескин, җырлый белми, кычкыра тик: «кар» да «кар»!

## «САКМАР СУЫ» КӨЕНӘ

Язасылай сүземне язалмыйм,
Ни булдикән минем каләмгә?
Язам, диеп кенә утырсам да,
Вакътым гына китә әрәмгә!

## ҖИЛ

(*Пушкиннән*)

Исәр җил! Көчлесең, син бик батырсың,
Ачулансаң, җиһанны кузгатырсың.

Бик иркенләп исәсең җир йөзендә,
Котыртып болгатасың диңгезен дә.

Көтү төсле болытларны куасың,
Теләрсәң кайсы якларга борасың.

Ireклесең: исәсең дә исәсең,
Тузан, кар туздырып юллар кисәсең.

Ирекле син, исәр җил, әйдә ис, ис!
Сиңа баш юк Ходайдан башка һич, һич!

## ЭШКӘ ӨНДӘҮ

*(Плещеевтән)*

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
Аһ! Оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.

Булса калдырмак берәү ушбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад.

Һәр олугълар эшләгәнлектән олугълыклар таба,
«Уйнады» дип бирмиләр ушбу җиһанда мәртәбә.

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкаддәс нәрсә – эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.

## ИРТӘ

Иртә. Дөнья җанлана,
Мәшрикъ ягы аллана,
Кояш чыгып, нурлары

Төшеп җиргә ялгана.

Яктыра кала. Урамнар,
Кырлар, якын урманнар,
Таулар, багълар, бакчалар
Нурга гарык булганнар.

Торды халык, уянды:
Шау-шу һәрбер төшләрдә;
Көтү-көтү менмәктә
Күккә җитез кошлар да.

Шушы вакыт балалар
Мәктәп таба баралар;
Букчалары артында,
Алар гыйлем дәртендә.

* * *

И төрек, иң әүвәл үк әйтим сиңа: борның кылыч;
Гыйльмилә хикмәт базарында синең урның кылыч.

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ НӘСЕР

«Ямьле кичтә күл буенда утырам.
Балкыйдыр ай, ялтырап тын күл ята».
– Бай абый! Бирче хәер! Бик ач торам, –
Йөз чытып, бай бер тишек акча ата.

«Күк йөзендә нурлы ак йолдызлары
Ялтырыйлар: шау-шусыз, тып-тын кичә».
Җиңгәчинең төн буе бар кызлары
Хаҗи байны сый итәләр төрлечә.

«Якты кичтән айрылалмый җан минем;
Сандугач сайрый турымда, моңлана».
– Бәдбәхетләр! Сез талап, дөньям минем
Гүр кебек, – дип, бай малайдан шомлана.

«Сайрый кош иркен гомер, хөр дөньяны;
Мин аның җыр, моң-зарын нәкъ аңлыймын».
Иске корсактан килә өн: мин яңы!
«Әссәлам!» берлән тотам ислам динен!

«Мәңге шул төн булсачы! Ямьле ничек!
Җанкәем дә килсә – бит оҗмах була!»
Акчага мөмкин сыйрат күпрен кичеп,
Акчага Гыймуш та хур кочмак була.

«Күлнең артында берәү моңлап көйли:
Җыр белән су каушалар – китте үбеш!»
Бер тәрәкъкыйче имам фикрен сөйли:
– Ишмиләр юкка түнәр, булса сугыш!

«Төн буе мин Аллага әйтәм хәмед, –
Тын галәмне бар кыйлучы Тәңремә».
Мактана Ишми: «Кидердем бит камыт!
Күп җәдидне мин җибәрдем кабренә».

«Күп тә тормый, атты әкрен якты таң,
Нурлы йолдызлар берәмләп сүнделәр».
Бер «кара көч» әйтте: «Аклыкны ватам!»
Бәндәләр «төнгә» ахырда күнделәр.

«Каршылады таңны сайрап сандугач;
Башка кошлар да кушылды, сайрыйлар».
Хаҗитарханда Камил булган агач;
Сәйяр «артистлар» да корсак кайрыйлар.

«Күктә шаулап кошлар үтте бер көтү,
Тиз булыр күл һәм кояшның каушуы».
Бетмәде шул «Мөхбире» дә, «кых, тефү!»
Һәм Рәмиевнең шигырьдә шау-шуы.

* * *

Приемныйның ишекләре тар ләхеттән тар икән;
Әстерханда ике этәч – «Борһан», «Идел» бар икән.

«ШУРА» ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН

Килеп мәктәпкә укыдык бу көн;
Укып, күңелгә тукыдык бу көн.
Укып, күңлемез ачылды бу көн;
Кальбемезгә нур чачылды бу көн.
Укып без сабак китапка карап,
Япь-яшь күңлемез ачылды бу көн.
Кыйлып иҗтиһад туктаусыз һәрчак,
Хәлфәдән «рәхмәт!» без алдык бу көн.
Укып, балалар алга баралар;
Ата-аналар разыйдыр бу көн.

**«Ялт-йолт»:**

Бу шигырьләрне яздым мин, бүкән;
Язалмас моны бүкәннән бүтән.

ИҺТИДА

**1**

Әгәр булса «сөю» ләфзы кочаклау куллар арганчы,
Үбү булса әгәр чут-чут, ирен һәм бит кабарганчы, –

Гомер дә сөйгәнем юк һәм «сөям» дип әйтмәмен һич тә;
Сөюнең мәгънәсе, минчә, бигүк гали, бигүк нечкә.

Кешеләрчә сөюне белмәдем, хис итмәдем асла;
Сөю идеалдыр ул, ягъни, гарәпчә: максады әкъса.

Табындым, сәҗдә кыйлдым мин сөйгән җанашның алдында,
Өмид иттем вә куркътым да, кызардым һәм оялдым да.

Миңа ул бер вә бар, көчле вә һәйбәтле санәм булды;
Аңар хәмдем, салатымны ирештергән каләм булды.

Мәхәббәттән эреп шәмдәй үзем, күңлемдәге гөлләр
Янып җиргә сыгылдылар, һавага очтылар көлләр.

**2**

Гарәп халкы кабул итмәстән әүвәл дине исламны,
Илаһ урнында тотканнар агач, таш, төрле әснамны.

Бераздан соң килеп хак дин, тәмам батыйль булып ялган,
Гарәпләрнең күзеннән дине ислам пәрдәне алган.

Алар бар үткән эшләргә пәйгамбәрдән оялганнар:
«Ничек соң без табындык потка?» – дип хәйранга калганнар.

**3**

Килеп чыкты хәзер фикрем кояшы золмәт артыннан,
Түгел инде вакытлы, мәгънәсе юк хискә мин корбан.

Шөкер булсын, хәзер алдымда бер нурлы хәят инде,
Теге мәзкүр пот алдында табынганнан оят инде.

Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мең ләгънәт!
Яшә, тугъры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!

* * *

Уңга да мин әйләнәм, сулга да мин әйләнәм;
Бай алдында җәдид күрсәм, «Син кяфер» дип бәйләнәм.

ЯШЕН ЯШЬНӘГӘНДӘ

Куркытма син, Алла! Яшен белән,
Барыбер мин куркъмыйм, яши беләм!
Куркытсаң да куркъмыйм, аязымны
Сатып алдым аһым, яшем белән!

* * *

Һәзад-дөнья әкалле мин калили,
Кара сыра эчеп исерә Хәлили.

ЧИТЕН ХӘЛ

Ни була тугъмак сыйратын кичмәсәм,
Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!

Әйләнә бит, үтми, бетми гомре дә! –
Җәй килә утлар чәчеп, син кышласаң.

Ардым инде, кайда актык мәүкыйфем?
Җилкенәмен – бер басарга өч басам.

Каршыма чыкма, кояш, син – канлы тап!
Ак кәфендәй син җәелмә өсткә, таң!

Катле нәфситсәм, Ходайдан куркамын,
Ләкми чир, аурып та булмый, ичмасам!

ГӨНАҺ

(*Бальмонтътан үзгәртелде*)

Кем яраткан? Кем чыгарган? И «гөнаһ» ләфзы, сине;
Мәгънәсезсең, сеңдералмый саф гакыл һәзмы сине!

Син кирәксез бер ләфызсың, син кабахәт, син оят;
Безгә артык бер йөгәнсең, бел: сиңа дошман хәят!

Аз гына инсан торырга уйласа хөр, шат булып,
Әллә кайдан син төшәсең, шатлыгына тап булып.

Алдыйсың; алмаштырасың; син тыгызлыйсың тыеп;
Син изәсең дә итәсең хөр җиһан күңлен боек.

Син, түшәкле бүлмәбездә яшьренеп, мескин карак! –
Тик торасың күз челәйтеп, гыйше-гыйшрәтне карап.

Аз гына артса чигеннән уйнашып үбшү, кочу,
Сызгырасың син җыландай: «Тукта, тукта, җитте, чү!»

Син пышылдыйсың гомергә: «Бу ярамый, ул ярый»,
«Ул, теге, һичбер ярамый, монсы бик мәгъкуль, ярый».

Без яраткачтан ярар, дим, кем аны синнән сорар?
Хөр кеше алдында җирләр һәм дә күкләр калтырар!

АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ

*(Бишенче көлтә)*

Мәкәрҗәгә баралар тәтәйләрнең ирләре;
Шушы вакыт тәтәйләрнең җөреп калган көннәре.

Таптамагыз, и тәтәйләр, Бакыр бабай бакчасын;
«Уйнаш»тагы яман күздән Ходай үзе сакласын.

Жаңа бистә кызлары чигү чигә акчага;
Бу вахытта шулар җөри Ботански бакчада.

Кушмый ишан капкасы, нарат икән тактасы;
Нарат булмый нәрсә булсын, бар да донос акчасы.

Безнең урам – таш урам, ташу ага басудан;
Сакалына хөрмәт беткәч, милләт сата ачудан.

Бәдәлчеләр-мәккәчеләр җөри Казан шаулатып;
Бер сөяккә унлап эт бар, чәйнәшәләр даулашып.

Ике туры ат җиктердем, берсен – сыңгар тәртәгә;
Баш хәерче Морадлары чыкмый ята Мәккәдә.

Шауладык без – «шу-уу!» иттек, кузгалдык без –
«ду-уу!» иттек;
Эшсезлектән, эч пошканнан эшсез картка туй иттек.

Камил мәхдүм җырлап җөри борнын түбәнгә асып;
Ала карга кунып сайрый тел очларына басып.

## ГАКЫЛЛЫЛАР ФӘЛСӘФӘСЕ

Күңелсез сүз сөйли бәгъзе гакыллылар хатын-кызга:
Фәкать бер ел күңелле, дип, календарь һәм хатын безгә.

## КАДЕР КИЧ

*(Сурәи кадердән)*

Бу кадер кич елда бер кич – барча кичләр изгесе;
Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе.

Сафланыр ул, пакьләнер, – бик зур Ходайның дәүләте;
Һәм төшәр ул көзгеләргә күк капугы шәүләсе.

Шул капугъдан күндерермез Тәңремезгә без теләк, –
Бер кадер кич Тәңре каршында мең айдан изгерәк.

Җон, мамыктай әйләнер җирдә бу кич әрвах вә рух;
Һәм фәрештә сафлары җирдә йөрер меңнәр гөруһ.

Ул мәлаикләр җыярлар тол, ятимнәр яшьләрен,
Барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын.

Күз яшеннән, төрле рәнҗештән ясап зур энҗеләр,
Ул мәлаик гарше-көрсине бизәр һәм энҗеләр.

Таң сызылганча йөрерләр, әйтмичә һичбер кәлям;
Тик диерләр: «Барча мөэмингә, мөселманга сәлям!»

## РАМАЗАН ГАЕТЕНДӘ ИБЛИСНЕҢ ШӘЙТАННАРЫНА ХИТАБЫ

Инде динне ташлыйлар,
Уразада ашыйлар;
Оялмыйча Алладан,
Ничек гает ясыйлар?..

Барсы качып ашады,
«Көндез сәхәр» ясады;
Тәкъва, суфи байларның
Чиктән узды фәсады.

Без, шәйтаннар, богауда
Гомер иттек бу айда.
Кодрәт бавын өзәргә
Без шәйтанда көч кайда?!

Без тик тордык богауда.
Ник аздылар бу айда?
Гөнаһ эшне юк файда
Инде безгә сылтауда.

«Шәйтан аздырган», имеш!
«Юлдан яздырган», имеш!

Кире татар, иң элек
Вөжданың берлән килеш!

## САЙФИЯ

*(Иделдә сәяхәтем хатирәсе)*

Килсә байның ач халыкны күзгә-күз мыскылласы,
Яллый ул, әлбәт, пароход, ансы – байлар юргасы.

Ярда торган ач халыкка йөз дә бормый, туп-туры
Юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сайфиясе.

Бу тупаслыктан көлеп торса кояш, күктән карап,
Нурны каплый «эссе!» дип бай – кулда бар шәмсиясе!

Бай киенгән франт-шикларча халык тирсе белән,
Батсачы шунда үзе һәм аләте нәкълиясе.

Ул хәзер туктар сиңа, и ач авыл, мохтаҗ авыл!
Җимрек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе.

Җаннарым, күз нурларым, сез, бу мәһабәтне күреп,
Җан ачып: «*во какъ!*» дисез, мәзлум мужиклар семьясе.

## ПОЕЗД БАРГАН КӨЙГӘ

«Дөмберр» карчык йортына
Тәрәзәсенә кыйна,
Нишләп иртә йоклаган,
Торсын әле Фатыйма!

Кичә эчтек партебин,
Берләп түгел, алтыдин;
Нинди йоклау ул әле
Пирбуенчы яртыдин!

Зәйни берлән Шәйхетдин
Килеп керде ишекдин;
Кыска буйлы Фатыйма
Торды гүя бишекдин.

– Исәнмесез, кунаклар!
– Сез дә саумы, аппаклар!
Әйдә, дустлар, эчәбез,
Әле безнең яшь чаклар.

Эчә дустлар чәкәшеп,
Күзне-күзгә текәшеп;
Эчкән була карчык та, –
Үзе беткән бетәшеп.

Фатыйманың кыз чагы –
Һавадагы кош чагы –
Хәрап булган бу өйдә,
Суына төшкән кочагы.

Шулай да ул типтерә,

Бетәсен сизеп тора;
Җылыйсы күз яшьләрен
Күз эчендә киптерә.

«Дөмберр» күрә – җыласа,
Ачулана ул нәрсә:
– Ашарыңа бар ич, – ди, –
Тагын җитми ни-нәрсә?

Мескин безнең Фатыйма
Кече яшьтән ятимә;
Шуңар күрә төшкән ул
Сатлык кызлар рәтинә.

Һәр төн шул эш бу йортта,
Исрек татар фарситта;
Ниләр, ниләр булганын
Саный алмый бер чорт та.

Сез әйтәсез: «Дөмберр» ни?
Аңлый алмыйбыз берни, –
Шундый карчык ул, аңар
Себерең ни, Сембер ни!

Яшь бер кызны ала ул,
Булган була ана ул;
Үсеп буйга җиткергәч,
Башын утка сала ул.

– Ник исме «Дөмберр»? – дисез, –
Бик ят исемдер, – дисез;
Язган абзаң белә шул,
Сез бернәрсә белмисез.

Гомре үткән дөмбердәп,
Аккан су күк гөлдердәп;
Ах, дүдәк-дүдәк-дүдәк,
Басма өстендә балүрдәк;
Господа! Станция Дюдякъ!

## ТӘМСИЛ

*(Италия-Төркия сугышы мөнәсәбәтилә)*

Дуст кушылдылар Арыслан берлә бер көн Юлбарыс,
Бер киңәштә эшләнергә булды эшләнгән бар эш.

Шул әззаманны әллә кайдан килде чыкты бер Мәче,
Каршылыйлар: «Әйдә безгә иттифакъка кер, Мәче!»

Булса да сүзләр береккән, бу өчәү айрым яши,
Һәрбере үз тапканын айрым ятып, айрым ашый.

Юлбарыс, күрсә ишәк-куйны, тизүк ертып ала;
Мөттәфикъ безнең Мәче тик күзләрен йөртеп кала.

Ат-сыер күрсә, Арыслан иткә тиз әйләндерә:
Бәдбәхет безнең Мәче тик күзләрен майландыра.

Аулый алмый бу Мәче һич, ач үләр хәлләр килә...
– Иттифакъ туклыклымы? – дип, дустлары аннан көлә.

Зар җылый безнең Мәче: «Сез туйдыгыз, – ди, – мин ач ич!
Нигә тик мин ач калырга, мин – великий держав ич!»

## ТОЛСТОЙ ФИКЕРЕ

Әле мөмкин икән иркеңне тоткынлыкка сатмаска,
Җаның көчсезлеген һич тә бу дөньяга сынатмаска, –

Өйләнмә, баш имә һич, телгә дә алма «хатын-кыз» дип;
Олугъ җан бул, куан-шатлан, шөкер, мин бит хатынсыз, дип.

Өйләнмәк бер-берәүнең җәбре-хаһре өсткә менмичә –
Егылмак берлә бердер, һичбер әйбергә абынмыйча.

**Үземнән гыйлавә**

Ышандык без Ходайга, бер вә бардыр, дип, вә ялгыз, дип;
Сөйли тел: «Кайнигәч, кайне, кәләш, – дип, –
һәм дә балдыз», – дип.

## ТӘҮБӘ ВӘ ИСТИГЪФАР

(*Пушкиннән үзгәртелде*)

Йа Илаһым! Падишаһым! Бер дә чик юк иркеңә,
Әмритәсең син кызыкмаска кешенең милкенә.

Мин кызыкмыйм һич кешенең малы, милке, бәхтенә;
Кайда ул, хәтта кызыкмыйм падишаһлар тәхтенә.

Көнче күз салмыйм кешенең йорт-җиренә, нигзенә,
Бер дә янмый күзләрем атлар, сыер һәм үгзенә.

Һич кызыктырмый мине шәп фәйтуны һәм арбасы,
«Әйдә тик сөрсен сафа!» дим, иткәч ихсан Алласы!

Йа Ходай! Нишлим, әгәр күрсәм кешенең зәүҗәсен?
Торса ул яд иттереп җәннәт сарае раузасын?

Ул Зөләйхаләр вә Ләйләләр кеби булса матур?
Көнләшәм... (әстәгъфирулла!) йа шәкүр вә йа гафур!

Дөньядук нишләп ача ул сигез оҗмах капкасын?!
Ник тәнавелли гүзәл, тәмле, матур оҗмах ашын?

Ярлыка, Мәүлам, мине, мин – инде көнче күбәләк,
Ибне адәмме түзәр, җирдә әгәр күрсә мәләк?!

## КӨЗГЕ ҖИЛЛӘР

Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен;
Ядыма Тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен.

*Русчадан*

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

– Иң сөекле эшче әүладым быел ач калды, – дип,
Изге, шәфкатьле анабыз – мәрхәмәтле җир җылый.

Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,
Бер телем икмәк, дип анда назлы нечкә бил җылый!

Бер сынык юктан гына үлгән таза ирләр күреп,
Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый.

Тилмереп торса бу ачлар, безгә бәйрәмнән ни ямь?!
Мәркадендә чөнки Ибраһим вә Исмәгыйль җылый.

Көлсә монда тук вә ихлассыз халык тәкбирләре,
Һәр ишеткән җан җыларлык – андагы тәкбир җылый.

Көзге төн, ямьсез, караңгы... Өй түрендә җил җылый,
Җил – хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый!

## ЗОЛЫМ

Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа иман таккан?
Тәзкирәңә «мөслим» диеп игълан таккан?
Кемнәр сине, намаз, диеп, сәҗдә, диеп,
Юкка тузанлы мәсҗедләрдә аунаткан?

Тагып сиңа иярченлек сәфаләтен,
Корал итеп йөретәләр җәһаләтең.
Гуаһлыклар бирәсең син, «әшһаде» дип,
Син ни белдең? Кемгә мәкъбуль шәһадәтең?

Мескин фәкыйрь, иркен сулыш та алмыйсың,
Аһ-ваһыңнан һичбер вакыт бушанмыйсың;
Көчләү сине сарих золым иман белән,
Иртәгә ач үлмәм дип тә ышанмыйсың!

## КЕЧКЕНӘ МУЗЫКАНТ

Уйга баткан, утырмакта шагыйрь язып,
Язадыр ул бар дөньяны онта язып;
Каләм белән кайчак чәчен актаргалый,
Чыгаргандай төрле уйлар баштан казып.

Яза шагыйрь, каләмене кулдан куймый,
Бер юл язып ташлый, тагын берне уйлый.
Шулай тыныч утырганда безнең шагыйрь,
Өй турында кемдер исә быргы уйный.

Тынычлыкны боза аның әче таушы,
Килә аннан, бер тыңласаң, мәче таушы,
Бер тыңласаң – чинау, бер тыңласаң –
Майламаган арба тәгәрмәче таушы.

Китә кәйфе, шагыйрь тәмам хәйран кала:
Кайдан чыкты бер дә уйланмаган бәла?

Кычкыра ул ачу белән тәрәзәдән:
– Тиз кит, малай, өй турымда тавышлама!

Йөгреп качып китте тизүк шаян малай,
Беразга туктаган булды юрамалай.
Шагыйрь тагын ихлас белән эшен эшли,
Тавышлардан котылдым, дип, йа Ходай!

Җыеп торган чакта гына шагыйрь хәлен,
Ходай орган! Быргы уйный башлый тагын.
Нишләргә дә белми шагыйрь, ачуыннан
Идәнгә ыргытып ташлый язганнарын.

Уйный быргы, һичбер вакыт туктап тормый,
Мескин шагыйрьнең күкрәгең, җанын тырмый.
Шагыйрь, инде нишләргә дә гаҗиз калгач,
«Булмас, ахры» диде, бер-бер хәйлә кормый.

Кычкырды ул: «Килче монда, чибәр бала!
Йөгреп кил дә, менә минем кулга кара:
Бирәмен мин быргың өчен унбиш тиен,
Акыллы син, шул быргыңны сатчы миңа».

ТӨРЕКЧӘДӘН

Эзләдем, филлаһ, сөямен, биллаһ;
Эзләдем дә таптым... бу бәлане!

**1912**

САБИТНЕҢ УКЫРГА ӨЙРӘНҮЕ

Сабит алты яшендә, инде гакълы башында;
Ялгыз, иркә бала ул әткәләре кашында.

Шуңа күрә шаян ул, бик күп уйный, наян ул;
Күңеллелек, көлкеләр таба әллә каян ул.

Фәһме үткен, ул зирәк, андый балалар сирәк;
Һәрбер әйберне сорый ул: «Бу ни нәрсә? Ник кирәк?»

Сабит сорый җентекләп, һәр нәрсәне бөртекләп,
Әти белән әнисе җавап бирә бик ипләп.

Беркөн Сабит әткәсен күреп әйтә әйтәсен:
«Әти, миңа әлепби кайчан алып кайтасың?

Мине укырга өйрәт, миңа укырга кирәк;
Үзем укыйм мин китап, үзем сөйлим һәм көйләп».

Атасы хәйран булды, китапчыга йөгерде,
«Бүләк» атлы әлифба алып кайтты ул берне.

«Бер адым, – дип, – гыйлемгә», өйрәтә ул Сабиткә;
Салган Сабит ихласын, кош бәбкәседәй, җимгә.

Монсы – «әлиф», монсы – «ба», бу хәреф –
«җим», монсы – «та»,
Бусы «дал» хәрфе була, бу хәреф – «зат», монсы – «та».

Салган Сабит муенны, оныткан ул уенны;
Тыршып укый «Бүләк»не, белми көнне һәм төнне.

Әткәй алган китапны тапты Сабит бик татлы;
Тиздән белде бик яхшы: нинди хәреф ни атлы.

Беркөн чәй эчкән вакыт, укый Сабит шартлатып;
Әти белән әнисе торышалар шаккатып.

Укуы өзек аның, – балачарак баланың:
«Бу ә-лиф-ба – бүләге Харитонов бабаның».

Хәйран булды әнкәсе, гыйлем булгач бәбкәсе;
Чәй катында елмая куанычлы әткәсе.

Күрсәң иде әнкәсен: кочып алган бәбкәсен,
Үбә-үбә бихисап битен, күзен һәм кашын.

ГЫЙБРӘТ ВӘ НӘСЫЙХӘТ

Нумерың матур булса – күсе булгай,
Һәр матурда начар якның берсе булгай;
Ансы булып җитмәсә дә – монсы булгай, –
Андин җыртык, мондин җыртык туннарым бар.

Бер адәмнең чын дошманы күсе булгай,
Икенчесен йөдәтүче кеше булгай;
Һәркемнең үзенчә бер эше булгай, –
Андин сүтек, мондин җыртык туннарым бар.

## АВЫЛ МӘДРӘСӘСЕ

Мәдрәсә дип нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе,
Нәкъ эче азган мөрид, мәҗнүн ишаннар хилкасе.

Чәйниләр монда җирәнгеч әллә нинди мөһмәлят,
Яшь гомерләр мөһмәлят чәйнәп була монда һәлак.

Кайсысы «кәптеркү» ди, һәм кайсысы «каптырку» ди;
Чорт ява знат, нәрсә ди, «сентерсү» ди, «саттырсу» ди!

Кыш көне шул мөһмәлятне ач төя төсле күшәп,
Яз көне туктый күшәүдән һәр күсәк угълы күсәк.

Алларында шунда да «Коръән» була һәм «Әфтияк»,
Буш түгел букча – китергәннәр аны көчләп төяп.

Кул керенә былчыраткач «Һәфтияк»нең һәр битен,
Уртасыннан капкалап, тәмләп кимергәннәр читен.

Астына мендәр өйгән – күрдем түрендә хәлфәсен,
Ул кырын салган начар, очлы вә кыршылган фәсен.

Килбәте булгач кабахәт, уйладым: иблистер ул;
Бу сасы ис, кем белә, шуннан чәчелгән истер ул.

## БӘЕТ

Бу сәнә ачлык җыланы чын халык бәгърен ашый!
Кит, китап! Сабрит дип әйтмә, ул халык көчен ашый!

* * *

Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра,
Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора.

Бу ике дуст, берсенә чөнки аларның берсе тиң,
Бертигез тәгълимнәре дә: берсе – дөнья, берсе – дин.

Ва әсәф! Ачлык вә коллыктан бүтән һич бездә юк.
Шул гаҗәп: ник бу егерменче гасырда – (йөз дә) юк!

* * *

Җырласаң да, җегет, ачы җырла,
Уяу җаткан кызлар җокласын;
Тәрәзәләр ачтым, гөлләр сачтым,
Асыл кошлар килеп чүпләсен.

* * *

Теләрсәң кемне сүк син яки макта,
Берәү берлән дә булма иттифакъта.

## ЯЗ ГАЛӘМӘТЛӘРЕ

Шактый ук язга галәмәт ушбу үткән мартта бар,
Анда салкыннан бүтән юк, марттан азрак артка бар.

«Яз якын»ның шатлыгыннан йөзгә чыккан елмаю
Инде яшьләрдә түгел, хәстә вә хәлсез картта бар.

«Яз җитә, бозлар китә!» – дип бирде инде март хәбәр;
Инде яз булганга билге һәр урам, һәр чатта бар.

Җитмәгәндер яз диеп тотсаң әгәр күңлеңдә шик,
Мин дә бер пальтомны илтәм, әйдә, дуст, ломбардка бар!

## ХӨРМӘТЛЕ ХӨСӘЕН ЯДКЯРЕ

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше йолдыз кеби.

Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма,
Күрмәмен дип уйлыймын бер якты йөз ул йөз кеби.

Көчле, көчсез, ярлы, бай булды һаман да бер аңар;
Һәр караштa ул иде чын «керпегеннән гөл тамар».

Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөҗдан белән;
Аз гына кер кунганын да кай җиреннән кем табар?

Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп,
Үткен акълы шул көрәшкә пакь көмештән юл булып.

Ул көрәште, язда елмайган кояш төсле бәләнд:
Карны-бозны ул ничек эртә көлеп һәм нур коеп.

Күрмәде гами, табигый, буш куыклар атмагач,
Һәм кәмиттә бер батыр да җирдә егълып ятмагач.

Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мескин үлеп аңлатмагач?!

## ЯНӘ БЕР ХАТИРӘМ

Мин – кунакчыл бер җыручы, миндә – бар ярлы-гидай,
Ханәмә яшьләр килә, һәм сәүдәгәр, бай угълы бай.

Ул бәләнд мәрхүм дә килсә, мин сизә торган идем:
Күктән иңгән, ханәмә килгән шикелле тулган ай.

## ШЫЕР

Фәхрелислам Агиевнең шыерын, малай, Кулаткада да севеп укыганнар. Вата, шыннан күреп, Кулаткада бер шаир безнең журналга да нәстәдер бер бәет посылать иткән. Вата:

**Бәет**

Их, малай, вафасыз да бу: міръ!
Бак вана: Хусаен дә помер!
Әмән безнең күк алаша кебек
Ашый, кәбәм, һич туймый бу йир.
Нишләсен вет, Азраил килсә, бар кеше үләр,
Тимай бай булсаң да – азанчы күмәр.
Вет праруклар да, малай, вафат булды,
Сахабалар: Али, Усман, Үмәр.

##ҺӘЗИҺИ КАСЫЙДӘТЕН ФИ МӘДХИ МОСТАФА

Төркиядә бер теләнче сухтә булган Мостафа;
Монда кайтып ил казасы, фетнә булган Мостафа.

Юп-юаш, муйнын бөгеп йөргән сарыклы бер сарык, –
Монда кайткачтын симергән, чучка булган Мостафа.

Шат кына, берлек белән торган шәһәрнең халкыны
Төрле дошманлык чәчеп, өч-дүрткә бүлгән Мостафа.

Әллә кем, чирмеш теле берлән гәзит язган булып,
Барча пакь инсанга биш ел этчә өргән Мостафа.

Торса да ул бер заманнар баш булып ялган белән,
Мисле корчаңгы көчек, читкә сөрелгән Мостафа.

Ут белән күктән сөрелгән бер усал шәйтан кеби,
Сөрдисәң мәҗлестән, ул дингә сыенган Мостафа.

Ач бозаудай тиз генә Коръән ялап та ант итеп,
Күп вакыт йозрык, таяклардан котылган Мостафа.

Дин дә файда бирмәгәч һәм деньгасы да калмагач,
Бай калошына табан һәм үкчә булган Мостафа.

Булганы хәлдә надан, тик бер кызылбашлы ишәк,
Тәртәбезгә ат булып, алдап җигелгән Мостафа.

Эзләп-эзләп тәртәбездән үз-үзенә мәртәбә,
Чын тиешле абзарына инде кергән Мостафа.

Хәйләләп монда китергән саф бер Истамбул кызын
Шәһвәте угърында хурлыкка төшергән Мостафа.

Килсә монда кыз балаларны укытмакка сусап,
Ул килер-килмәстә, гыйрзына тукынган Мостафа.

Ул шулай хайванлыгының, шәһвәтенең пәрдәсен
Бар укыр кызлар юлына каршы корган Мостафа.

Ник саныйм гайбен аның соң? Мин түгел бухгалтеры!
Ул кабахәтлектә мильярдир танылган Мостафа!

## БАЛКАНДА

Курыкмыймын, селкенми хәтта фәс чугым;
Мә, кирәксә, дүртеңә дүрт йозрыгым!

## КАЗАН МУЛЛАСЫ ҺӘМ БУЛАЧАК ДЕПУТАТ

– Райта, райта, райта, райта, райтарам!
Шул көйгә бассаң, указың кайтарам.

– Яхшы, рәхмәт, мин басам, сүзсез басам;
Яхшы хәтта шатлыгымнан очмасам.

– Тимта, тимта, тимта, тимта, тимтатам!
Очсана, мин җөббә чабуыңнан тотам.

Әйдә, хәзрәт, ач канатың, юлда бул;
Мин вәкилмен, син указлы мулла бул.

Син яңа булсаң да, хәзрәт, искесең,
Син җәдид, ләкин ишансың, изгесең.

Ни гаҗәп, бирсә сиңа Тәңре канат,
Ярлыга биргән кеби ул җиккән ат.

Бу икәү очты Петербурга таба,
Каргалар күктә сәламли: «Мәрхабә!..»

Очтылар хәзрәт, вәкил – күп очтылар,
Тик, тәәссеф, җиргә егълып төштеләр.

## ВАЛЛАҺИ

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!

Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
Җир яшел; кошлар да сайрый, валлаһи!

Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!

Аз гына бер җил исү берлән, үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

## ТӘМСИЛ

**I**

Әһле Балкан кечкенә бер эт иде,
Төркия күктә очар бөркет иде.
Һәр заман торды бу көнче эт өреп,
Күктә очкан солтанәт кошны күреп.
Өрде, өрде, кошны иткән күк харап,
Торды пычрак аузы күкләргә карап.

Хөр вә шат, якты фәзада кош оча,
Койрыгын болгап җылый эт: эч поша.
Эт улый мәшъүм вә тырный үз битен,
Бәдбәхет, чәйнәргә хәзер үз итен.

Ошбу күренеш башкаланмый күп заман,
Төркия хәле гүзәл, этнең яман.
Очты бөркет киң һавада хөр вә шат,
Кәгъбә шат, милләт вә шат, солтан рәшад...

**II**

Әллә кем аткан тирән бер ярдан,
Билгеле бер саеде мәльгунәдан,
Кош төшә җиргә (бу мәгълүм язмый ук),
Кәрлә этнең, көнче этнең аузынук.
Шунда да курка һөҗүмгә эт сәфил
Читтән әйткәнне көтә: «Өсс!» яки «пиль!»
Чөнки шанлы кош чокып алса күзен,
Һич берәү әйтмәс, ди, ул «яклау» сүзен.

**III**

«Пиль» диде кемдер – җибәрде өстереп,
Сугъша маэмай койрыгын селкеп, өреп...
Ошбуны «изге, кирәк бер кан» диләр,
Сугыша Инҗил белән Коръән диләр,
Алдый алмаслар халыкны юк белән,
Монда хәзрәтләр сугышмый поп белән!

АҢ

Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъват итте безне кемдер изге нам белән.

Эшкә ябшыр чак җитеп, ямьсез озын төн үткәнен
Күз ачып белдек без, үлчәп күктәге Чулпан белән.

Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел.

Шул сәбәпле дустны, дошманны дөрест фәркъ итмичә,
Күп сataштырдык рәзил шәйтанны чын инсан белән.

Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек – булсын кабул;
Җәбраил ачкай ул эшләргә сигез кат күккә юл.

Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул;
Инде эшлик саф, ачык күзләр белән – чын «Аң» белән.

ТОЛУГЫШШӘМСИ МИН МӘГЪРИБИҺА

Чыкса мәгърибтән кояш – шунда заманның ахыры,
Бу – китапларда язылган күп галәмәтнең бере.

Гыйльмилә хикмәт кояшы тугъды мәгърибтән хазир,
Көнчыгыш халкы, белалмыйм, инде нәрсә монтазир?

ҮТЕНЕЧ

Яшь вакытта яшьнәдем, көчле вакытта күкрәдем;

Яшьнәмим дә, кукрәмим дә – утсыз инде кукрәгем!

Килде тоткынлык, түбәнләнде уемның куллары;
Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.

Ак күгәрченне кулымнан алдылар, козгын биреп;
Ак кирәк дип, пакь кирәк дип, күпме күз яшь түкмәдем!..

Ул – түгел күңлем эшеннән, тик ялан кулның эше,
Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем.

ДОШМАННАР

Күп «җыланнар» сызгырып читтән карыйлар бәхтемә,
Борла-сырла, бәдбәхетләр, үрмәлиләр тәхтемә.

Аз кеби баскан бу золмәт тормышым йортын минем,
Түзмиләр бит бер генә яктан ачылган яктыма!

Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән;
Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.

Дөньядан туйдым, өмидем юк, алар күпсенсә дә;
Тик мин үлгәчтән, карагыз, типмәсеннәр нәгъшемә!

*

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна;
Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля.

Якты йөз берлән алам каршы авырлык, ауруын;
Чүпкә дә саймыйм йөрәккә кап-кара кан саулуын.

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

КИЧКЕ ТЕЛӘК

Мин язам, шунда күрәм: лампам эчендә май кими;
Алда кәгазьгә ташыйлар – күңлемә уйлар сыймый.

Якты беткәнчә языйм дип, сызгалыйм тиз-тиз генә,
Кәгазь өстендә кала тик кәкре-бөкре эз генә.

Нокталар да төртмимен, керсә ярар, дип, киртәгә –
Мин үзем сызганны бик яхшы таныйм, дип, иртәгә.

Күп тә үтмәстән, утым ялт-йолт итә һәм селкенә,
«Гөлт!» итеп актык нурын бер күрсәтә, аннан сүнә.

Нишлисең? Һәр якта золмәт. Ихтыярсыздан ятам;
Мин, ятып, яткан җиремдә төрле уйларга батам.

Мин, караңгылык эчендә уйланып яткан көйгә,
Нечкәреп күңлем, җылыйм да бер сүз әйтәм лампага:

«Ни бәхет! – дим, – иртәгә кич син тагын да янмасаң,

Бу ятыштан мин дә мәхшәр җитмичә кузгалмасам!»

## ҖЕГЕТЛӘР

Бар җегетләр: бик тәкәбберләрчә тоткан *поза*сын,
Чөнки дөнья бакчасының күргән ул тик *роза*сын;

Күрмәгән ул дөньяның каһрен, усал *угроза*сын,
Күрсә дә, калган «угы», күргән фәкать ул *роза*сын;

Күрмәгән язмышның ул зур тукмагын йә *розга*сын,
«Г» калып, күргән фәкать ул розганың да *роза*сын.

## ВАКСЫНМЫЙМ

Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа,
Әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа:

– Бу заман шундый заман, – дип, – бу вакыт мондый вакыт,
Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.

Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вакътына,
Башны бөксәм – зур җинаятьтер олугъ җан хакъкына.

Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга, мәңгегә,
Мәңгелеккә – мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!

Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;
Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.

Вакътыны йөртер кешеләр ул заман миннән күреп,
Файдалансын шунда миннән сәгатен һәркем борып.

## БАЛА ОҖМАХТА

Мин хәзер оҗмах түрендә – бер матур хур иркәли;
Мин җуанмыймын, җылыймын, син түгелсең, дим, әни!

Ай төсендә нурлы гыйльманнар миңа ташлый тәти,
Егълыймын, алмыйм аларны, сез түгелсез, дим, әти!

## САГЫНЫР ВАКЫТЛАР

Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, –
Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын.

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!

Юк гамең бернәрсәдән дә, барча эшләр ал да гөл;
Күк тә күк төсле зөбәрҗәт һәм дә баскан җир – ләгыль.

Очрамый юлда җиһанның кайгы-хәсрәт, аһына,
Тик бирәсең ул вакыт бәйгать табигать шаһына.

Һәр чәчәк – сеңлең, апаң; абзаң – үсеп торган агач;
Син сабыйдай нечкә аваз берлә сайрый сандугач.

Чәчмәгән җир күк – күңелнең һәр гүзәлгә бушлыгы,
Тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы!

Бар күңел хәдсез, хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы,
Санки күңлең – җиргә күктән ингүче рәхмәт юлы.

Бер теләнче керсә йортка, син бирәлсәң бер телем, –
Әй була җанга хозур! Шатлыктан әйләнми телең.

Кич белән кайчак укыйлар, тыңлыйсың төрле китап,
Кайсысы көйсез була һәм кайсысы көйле китап.

Бер кызык көйле китапның моңлы таушы тирбәтеп,
Күз йомылгач, ихтыярсыз йоклыйсың шундук ятып.

Йоклыйсың рәхәт кенә; төнлә уянсаң бер заман,
Як-ягың тып-тын – әле юк яктылык, таң атмаган.

Шул вакыт яшьләр күзеңдә: җан ачып, җан сызланып
Егълыйсың, Җан-Зөһрә берлән Җан-Таһирне кызганып.

КАРТЛАР

Шаулый-шаулый уйныйбыз без кайчагында картаны,
Без отабыз, оттырабыз – «тем»мы шунда, «банка»мы.

Кем көлә, кем кычкыра, һичбер өзексез шау да шау;
Бу хозурдан онтыла кайчак эчү берлән ашау.

Акчалар уйнарга дәртне кузгатадыр шалтырап,
Күзне кыздыргыч көмеш, алтын ятадыр ялтырап.

Уйнасын шул бәндә – кемнең акчасы бар, вакъты бар;
Әйдә оттырсын бәхетсез, отсын әйдә – бәхте бар.

Тик нигә китми уеннан акчасы беткән кеше?
Акчасы юк, бәс, бу мәҗлестә аның беткән эше.

Китмәве җитми әле – ул уйнаганнарны тыя:
«Иттем инде тәҗрибә, уйнау начар эш!» – дип куя.

*

Нәкъ шулайдыр карт кеше дә, бетсә хәле, әлсерәп,
Аркасы чыкса вә торса ак сакалы сәлперәп;

Ах да ух! дип, көчкә-көчкә өстерәлсә бөкрәеп,
Күзләренең дә нуры бетсә вә калса чекрәеп, –

Баш бөгәргә өнди башлый инде ул яшьләрне дә,
Һәм сөюдән мәнгъ итә башлый кара кашларны да.

Бозмасын мәҗлес хозурын акчасы беткән кеше,
Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше!

АВЫЛДА АВЫРЫП ЯТУ

Мин әле аурыйм авылда, монда кайттым кыш көне;
Ял итә монда агайлар, җәйдә калган эш көне.

Сызганып мин дә агайлар берлә ялкаулык итәм;
Туйдым инде хәстәлектән, яз көтәм, саулык көтәм.

Язганым – кышның буранлы һәм караңгы уйлары,
Һәм дә хуш исле ипи, майлы бәрәңге уйлары.

И бәрәңге! Син, бәрәңге! Кил, бәрәңге – җан ашым;
Син генә тәмләртәсең бар ярлылар, байлар ашын.

Күп җәфа күрдең бу җиргә син килеп Амрикадан,
Нишлисең, тәкъдир шулайдыр, халкыбыз шул бик надан.

## БӘРӘҢГЕ ВӘ ГЫЙЛЕМ

И бәрәңге! Безгә килдең син ерак Амрикадан;
Мәгърифәт! Син безгә килдең мондарак – Яурупадан.

И бәрәңге! Син күрендең әүвәле күрнешкә чит;
Шаулады, күргәч сине, барлык мужик: ул дип «җәдид!»

Ул бәрәңгене китергән дип бу җиргә дәһриләр
Һәм эчендә ул бәрәңгенең, имеш, дип зәһре бар.

И бәрәңге, күп әзаларга синең сабрың беләм,
Ташлады йолкып мужик халкы төбең-тамрың белән.

Ул бәрәңгене ашаучыны ора дип Алласы,
Син аталдың ул заман: «кяфер вә шәйтан алмасы!»

И бәрәңге! Инде шатлан, кичте баштан ул чагың;
Син, җиңеп, иттең мәкян инде мужикның корсагын.

Син кикертсәң, ул хәзер: «Әлхәмделилла!» – дип куя;
«Күп шөкер, – ди, – бу җимешне бирде Мәүла!» – дип куя.

Син, алып үрнәк сабырлы бу бәрәңгедән, гыйлем!
Аз гына нурландыра башла мужикларның миен!

## «ЙОЛДЫЗ»ДАН ДА КУРКА

Кайдадыр йөгрә иде кырлар буенча бер куян –
Дүрт аяклы һәм канатлы дошманыннан куркудан.

Шактый җир киткәч, бераздан тугъры килде бер суга;
Калтырый бәбкәм минем – һәр әгъзасы бер куркуда.

– Инде нишлим? – дип, куян торганда гакълыннан шашып,
Төштеләр ярдан суга барлык бакалар: «шып та шып!»

Мескинем күргәч бу хәлне, аз гына артты көче:
– Мин куяннан да җиһанда бар икән, дип, куркучы!

*

Аулыма кайтышта мин бер чит авылга туктадым;
Төн иде, кердем дә шунда бер агайда йокладым.

Күз йомалмый төн буе төрле исәп, уйлар белән,
Иртә торганга агаем, мин дә тордым таң белән.

Тиз генә чәйне эчеп, бакмый җиленә, даулына,
Юлга чыкмакчы буламын, тиз җитим, дип, аулыма.

Мин кичә кич монда чәчкән барча әйберне җыеп,
Инде китмәкче булам, тышкы киемнәрне киеп.

Шул вакыт күрдем: агай, сумкамны рөхсәтсез ачып,
Нәрсәдер шунда сала тиз-тиз генә, миннән качып.

– Нишлисең, абзый? – дидем. Шунда агаем аптырый;
Куркынып киткән төсе, куллар да дер-дер калтырый.

– Мин, – ди, – салдым сумкаңа, йортымда калган, –
 ди, – «гәҗит»,
Мин түгел, – ди, – абзарауный һәм түгелмен, – ди, – җәдид.

Алмадым мин ул гәзитне, калганын да бик беләм,
Бу бака, хәтта ки, «Йолдыз»дан да курка дип көләм!

## БУРАН

Тик кенә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себрелә, кар котрына һәм кар ява.

Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап;
Һәр кара нәрсә – бүре һәм һәр маяк булды карак.

Карны җиңгән күк, төшә җиргә тонык ай яктысы;
Ай да куркынган шикелле: бер сары, бер ак төсе.

Көн буе яткан иде, үлгән җылан күк, юл тыныч;
Чыкты соң кайдан адаштыргыч буран – бу куркыныч?

Әллә ычкынганмы баудан Каф тау арты җеннәре?
Йә тишелгәнме Ходайның бихисап зур мендәре?

Кар булып җирдә очамы ушбу мендәр җоннары?
Йөгрешеп җон аулый мәллә Каф тау арты җеннәре?

Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә,
Мин фәкыйрь михнәттә – гүя чарлагыннан бай көлә!

## КӨТМӘГӘНДӘ

Кар-томаннан көтмәгәндә килде чыкты Шүрәлем.
Дәшмимен. Тып-тын торам. Нишләр икән, дим, күрәлем.

Иң элек төртте озын бармакларны ул бүркемә;
Бармагы үтми аның, күрде, башымның күркенә.

Сузды шуннан соң кулын, биттән минем эзләп кытык;

Кайда ул көлмәк, кытыкланмак миңа – йөзләр чытык.

Муйныма сузды, кытыклармын дип, ул тырнакларын;
Мин шарыф берлән аны куйган идем чорнап калын.

Белде капшап соңра инде арканың да ул хәлен;
Җәйге күк күлмәк түгел шул: үтми бармак – тун калын.

Бик кирәкле эш кеби күкрәкләремне капшады:
Ул кытык эзләп маташты; булмагачтын – ташлады.

Мин бөтенләй бер кәбестә: бар кием ун кат минем,
Бу киемнәр йөклеген икърар итәрлек ат минем.

Ул, алып кулларны күкрәктән, минем билдән тота;
Һич тә бер шәйтан чишалмаслык минем билдә пута.

Ул, табан астын кытыклыйм дип, аякка кул ата;
Бармагын сизми аның, әлбәттә, җансыз ул ката.

– Әмма бәйләнчек тә син урманда, кырда, Шүрәле!
Йөрмә монда булмаганга, бар, эшеңне күр әле!

Син түгел, тәнгә тиялми китте инде күп суык,
Төлке эчле тун җибәрде күп суыкларны куып.

Кертмәгәч тәнгә, суык абзаң миңа дошман әле,
Миннән үч алмак өчен эшкә буран кушкан әле.

Шул сүземнән соң томанга батты, гаиб булды ул,
«Чи-и-и!» итеп бер әллә кайда, бик еракта көлде ул.

Ул көлә, һәм көлке эзләүдә үтә кич, иртәсе;
Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул – табигать иркәсе!

## КӨЛКЕ ТҮГЕЛ

Көлке булса кайвакыт шигъриятемнең кыйссасы,
Анда бар бер җанлы хәсрәт, канлы ләгънәт хыйссасы.

Уйлый торгач, мин үземнең җан ачымнан да көләм,
Чөнки инде кайгыралмыйм, кайгырып арган булам.

Хәсрәтем – әллә минем нурлы кабыклы бер җылан?
Куркынырда җылмаялар, ни бәхетледер җылан!

Юк, түгел, һәр хәлдә дә хәсрәт язу рәүшем шулай,
– Нәрсәгә шиблит киясең? – Мин димен: кәүшем шулай!

## ӘХЛАКСЫЗЛЫК

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

Тик хәзер, йөз сумны урлап килгүче угъры кеби,
Күз салабыз чын сүз әйтердән элек як-якка без.

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

## МОНАФИКЪКА

*(Сюжет русчадан)*

Җиһанның эссесен, салкын, бозын күрдем, карын күрдем;
Ниләр күрсә бөтен үксез – барын күрдем, барын күрдем.

Хәзер шатлык, уен-көлке телим инде җитәрлек күп;
Сабый чакта гариб башым җәфа чикте, җитәр, бик күп.

Сөрәм, котрып, тәмам тилреп, фани дөнья сафасын мин;
Кире алсын явыз тәкъдир үзе салган хафасын, дим.

Теләп шөһрәт вә хөрмәт, күккә бер чаклар очу күрдем,
Һава юктан көчем беткәч, тагын җиргә төшү күрдем.

Аяклымын, канатлымын – чабыш күрдем, менү күрдем,
Сөбатлымын, хәятлымын: үземдә бер голү күрдем.

Шаярма, дошманым, пешкән, җитешкән пәһлеван берлән;
Монафикъ! Яхшы саклан! Аударым бер көн ояң берлән!

## САБЫЙЛАР ҖЫРУЫ

Каз канатлары ак булыр,
Ир канатлары ат булыр.
Сабыйларның канатланыр вакъты
Мәктәпләрдә укыр чак булыр.

## НИ КИРӘК ТАГЫ?

*(Экспромтъ)*

Алкаларың якты брилиант ич, –
Җанкисәгем, ни кирәк тагы?
Һәрнәрсәдән миңа син кыйбат ич! –
Җанкисәгем, ни кирәк тагы?
Син теләк ич миңа, син салат ич, –
Җанкисәгем, ни кирәк тагы?
Син хәят ич миңа, син мәмат ич, –
Җаным, бәгърем, ни кирәк тагы?

## ПУШКИН ВӘ МИН

Хәзрәти Пушкин авылда язды үз «Евгение»н,
Мин исә җырлыйм фәкать монда бәрәңгенең көен.

Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннән түбән;
Тугъры күз салсаң эшенә – ул үзе миннән түбән:

Бервакыт онтыр җиһан Пушкинне һәм «Евгениен»,
Яүме мәхшәрсез онытмаслар бәрәңгемне минем.

Язганың булса бәкалы, ул бәкага тартала;
Мин дә булдым һич тә онтылмас кеше шул аркада.

## МӨНТӘКЫЙД

*(Кыйтга)*

Күп сөйләндем. Яхшы инде, мөнәкъкыйдләр сүкмәсә,
Берсе барлык язганымны читкә себреп түкмәсә.

Ул кавемнән булмыйдыр тәхрирчедән һичкем тыныч,
Берсе бар, дустым минем, һәрбер сүзе үткен кылыч:

Җил тегерменен күрә дә: «Аһ, суы юк!» – дип куя.
Су тегерменен күрә дә: «Пар, буы юк!» – дип куя.

Ул тота ат койрыгын да: «Бу – озын сач!» – дип куя.
«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ!» – дип куя.

Ул сукачыны күрә дә: «Җир боза бит!» – дип куя,
«Шундый зур эшкә каләм әһле түзә бит!» – дип куя.

Ул күрә куй койрыгын да: «Нинди шешкән!» – дип куя,
«Рус табибкә бу татарлар нинди дошман!» – дип куя.

## ИНТИКАДКА МӨТӘГАЛЛИКЪ

Булса ялган, тик кәгазьләрдән ясалган бер чәчәк, –
Билгеле, үз өстенә яңгыр явардан куркачак.

Чөнки яңгырда җебеп беткәч вә киткәч төсләре,
Һичберәүнең чәчәккә инде китмәс исләре.

Куркъмый яңгырдан, әгәр булса табигый, чын чәчәк,
Чөнки ул яхшы белә: яңгыр аны яхшыртачак.

Ушбуның күк, куркыталмый чын талантны интикад:
Ник үзенә игътимады һәм сүзенә – игътикад.

Тик китә кайчакта кәйфең, хакимең булса ишәк,
Бер татарга ят, мәхәббәтсез күсәк һәм килмешәк!

## МӘХӘББӘТ ШӘРХЕ

Мин: «Мәхәббәтсез», – дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә:
Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә.

Тугъры килгән урны чүплеккә, тиреслеккә аның:
Каплап алган төрле шакшы, төрле пислек һәр ягын.

Шунда кыткылдый әтәч, мыркылдый шунда дуңгызы;
Шундый хурлыкта, хәкарәттә мәхәббәт йолдызы.

Йоклый йолдыз шул түбәнлектә, озын төшләр күреп,
Һәр төшенә бакчалар, гөлләр, гүзәл исләр кереп.

## КАЗАН ВӘ КАБАН АРТЫ

Кай заманда, кайсы телдә булса да мәзкүр Казан,
Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл – Кабан.

Бу шәһәрне һәм бу күлне җырлыйдыр милләт теле
Бик яратып, әллә инде иске шөһрәт аркылы.

Ул шәһәр – гади шәһәр, алтын-көмеш, гәүһәр түгел;
Күл дә тик бер күл генә, әлбәттә, ул кәүсәр түгел.

Нечкәләп баксаң, бу күлнең бар бугай шигърияте,
Бар кеби милләт хыялында аның сиррияте.

Бервакытлар мин, сузып анда Кисекбашның җебен,
Бер төшеп мендем – бөтенләй тикшереп бактым төбен.

Чыкканым юк тик әле никтер бу күлнең артына, –
Әллә мин ялкауланаммы? Әллә күңлем тартына?

Тик сөйли күргән кеше анда гараибләр күбен,
Тәңре кылган, ди, гаҗәп бу күлнең артын һәм төбен.

**2**

Бар, имеш, ди, ул күл артында убырның карчыгы,
Йортлы-җирле, ди, үзе; акча тулы, ди, янчыгы.

Ул күл артында адашса кичкә калган кыз бала,
Ихтыярсыз, ди, әбинең йортына ул күз сала.

Ул әбинең балкыган тышка уты бик якты, ди;
Һәм ул ут чиксез матур: күкле, кызыллы, аклы, ди.

Кич белән карчыкка шундый күп адашкан кыз кереп,
Чыкмыйлар, ди, юк булалар, ди, тәмам боз күк эреп.
Бер-ике кичне тарыйлар, ди, алар карчык сачын
Һәм кашыйлар, ди, уалар, ди, аягын, аркасын.

Чәч тарарга бер печәнлектән алынган тырма, ди,
Аркасын массаж өчен бер ат җигелгән арба, ди.

Ул ята, ди; шунда гармун уйный, ди, гармунчылар;
Ул кырын салган кәпәчләр уйный, ди, бик моң, чибәр.

Гайфи абзый! Кайда күрдең? Син аларны мактадың:
Күрмисең тиз уйнаса хәтта, дидең, бармакларын!

**3**

Баш таралгач, башлый, ди, ул инде, мәлгунь касдына:
Хәбситә, ди, барча кызларны идәннең астына.

Ул ябып мәзлумаләрне мисле былбыл һәм тавык,
Ташлый, ди, кызлар симерсеннәр дип, анда чикләвек.

Шунда ул, кызлар симергәч, ул яга, ди, бер кичен
Бар тәмугдан, бар җәһәннәмнән дә киң һәм зур мичен.

Шул вакыт бер кыз ала, ди, ул чәченнән өстерәп,
Бер кулында, ди, аның дөнья кадәрле зур көрәк.

Әйтә, ди, ул: «Бу көрәккә син утыр, куштан кызым!»
Ташлый, ди, мичкә, утыргач, бер дә чытмастан йөзен.

Ул өй алдында хисапсыз, ди, имеш, кыз түшкәсе,
Мөслимә, ди, барчасы, юк бер генә Катюшкәсе.

Бер чөйдә торса Рабига, Гайшә, Мәрьям түшкәсе,
Шунда, ди, бергүк эленгән дуңгызы һәм чучкасы.

Шунда кыткылдый әтәч, мыркылдый шунда дуңгызы
Шундый хурлыкта, хәкарәттә мәхәббәт йолдызы.

## КАЗАН ВӘ КАЗАН АРТЫ

И Казан шәһре, торасың тауда зур шәмдәл кеби,
Мәсҗедең, чиркәүләрең, һәр часларың шәмнәр кеби.

Син, үзеңне чорнаган һәрбер өязгә нур чәчеп,
Бик мәһабәтле торасың, барчага юл күрсәтеп.

Нур ала синнән бөтен як: Чистапул, Спас, Тәтеш
Һәм Чабаксарга, Мамадышларга Чар, Малмыж катыш.

Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:
Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.

«Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампының һичбер нуры», –
Шул мәкаль монда дөрест шул, ах, аны җен оргыры!

## ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый, мәгърифәт, хикмәт белән

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.
Мондый күрнеш сөйнеченнән инде мин алдан беләм:

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гауваслары.
Өсттә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары.
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек, –
Без аның бик зур фәхерле, чын брилиант кашлары!

## ДИН ВӘ ГАВАМ

Дин хәзер – иске, аварга торгучы чергән дивар,
Аз гына, уйнап кына бармак белән төртсәң – авар.

Билгеле, һәрбер агачлар да корырга башлыйлар,

Былбыл урнына оя тоткач башында каргалар!

*

Ник агай мәсҗед эчендә юкка ирнен селкетә? –
«Пыш-пыш»ыннан күршесе белсә укый дип, шул җитә.

«Кем ятар да, кем торыр?» – дип йөртә ул тонган күзен, –
Бер тыныш та белми бит күңленнән ул Коръән сүзен!

Син киләсең бит, агай, тик монда килгәнгә атаң?
Ул да син килгәнгә килгән – тышта калдырган катаң!

*

Әйтче, зинһар, нишлисең мәсҗедтә соң син, сәүдәгәр?
Сау торамсың, бу арада бик кызумы сәүдәләр?

Соң ничек үтте базарлар, һәм тире күп кердеме?
Бу намазыңны әле соң хаҗи абзаң күрдеме?

Күрсә, ул мактар сине, «Һәйбәт кеше Әхмәт», – диер;
«Тәүфигыңдә, истикамәттә, менә рәхмәт!» – диер.

*

Пурки! пурки! нәрсәгә мәсҗетдә син тыңкышланып
Сайрыйсың, Коръән ватасың, тук сыер күк мышнанып?

Җомгадан соң кемдә аш барны сизә ак тешләрең?
Соң теге көнге хәмелдән күп «хосул»мы эшләдең?

## ЯҢГЫР

*(Русчадан)*

Былчыракта яңгыр артыннан балалар йөгрешә,
Кычкыралар: «Җиргә, – дип, – алтын төшә! алтын төшә!»

– Шауламагыз, и балалар! Без җыярбыз барчасын,
Тиз ул алтыннарны амбарга төярбез барчасын.

Тик җыярбыз юл буе шыгрым тулы йөкләр көе,
Бар келәтләр туп-тулы хуш исле орлыклар көе!

## ҖИЛ ТАВЫШЫ

Җилбер-җилбер йөрмәс идем,
Җил тавышын сизмәсәм;
Өзлеп такмак әйтмәс идем,
Үз халкымны сөймәсәм.

Кәйфе бик киткән урыс әйтсә әгәр: «Ыжжжид!» – дисә,
Кәйфе бик киткән үрәтник: «Ах, ты, пес мужжжжжик!» – дисә,

Кәйфе киткән ихтилалчы: «Ах, ты, чорт, шшшшпик!» – дисә,
Һәм авыр штыклы солдат: «Их, тяжел шшштык!» – дисә,

Һәм дә бер исрек кеше: «Без бик кичә эччччччтек!» – дисә,
Һәм табадагы коймаклар: «Инде без пешшшштек! » – дисә, –

Ушбу сызгыргыч тавышларны берәү аулап җыйса, –
Барчасыннан көчлерәк бер җил нидер даулап исә.

*

Җил – табигатьнең теледер; кайвакыт ул, тотлыгып,
Өч хәрефне яхшы әйтми, – бәс, буран китте чччыгып!

АВЫЛ ХАЛКЫНА НИ ҖИТМИ

Казенный булса да, зур урманы, чыршы, нараты бар;
Казенный булса да гәрчә, эчим дисә – аракы бар.

Җитәр төсле түгелдер, ничек хәмдитсә Алланы:
Хисапсыз әйләгән ихсан иманны һәм иманаы.

ӨЧ ХӘКЫЙКАТЬ

*(Майковтан)*

Бар иде әүвәл заман бер Бай кеше,
Күп ашап тулган, биек таудай, эче.

Бер заман аулак урамнан барса Бай,
Әллә ни чыр-чыррр килә, – Чыпчык бугай.

Чыпчык ул, Чыпчык! Менә очты хәзер,
Ул очып Бай өстенүк төште хәзер.

Ул чырылдап кунды Байның бүркенә,
Чын-чын илтердән генә баш күркенә.

Кошчыгым чиксез кыю, чыррр-чыррр килә,
«Нинди куркъмас кош!» – ди, абзый селкенә.

Абзыйның һәрбер көрәктән зур кулы,
Тотты Чыпчыкны, сузып кулы, берьюлы.

Шул вакыт Чыпчык сөйләргә башлады,
Сүз сөйли, чыр-чыррр итүне ташлады.

Инде Чыпчыкта хәзер Адәм теле,
Хам белән Яфәс, тагын да Сам теле.

Абзыйга ул ушбу сүзләрне сөйли
(Кош, ирексез, дикъкатен Байның били):

«Мин сиңа, абзый, булырмын файдалы,
Сәүдәгәргә андый файда кайдәле?!

Тик мине, абзый, син ит әүвәл азат,
Шуннары байрак булырсың һәм дә шат.

Син азат иткәч башымны, чөнки мин
Файдасы күп өч дөрест сүзне сөйлим.

Өч дөрест сүз ул сиңа бик файдалы,
Сәүдәгәргә андый файда кайдәле?!»

«Яхшы, яхшы, тиз булырсың син азат,
Эш алай булгачтын, итмәм мин азап».

Чыпчык әйтә: «Өч дөрест сүз шул була:
Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, җыла.

Һичвакыт алма көчең җитмәслек эш,
Хәл җитәрлек, булдырырдайга тырыш.

Бик ышанма һәр сөйләнгән сүзгә дә,
Күп таянмас бул үзеңнән үзгәгә».

Тыңлагач, Бай әйтә: «Моннан файда юк,
Андый буш сүз кемдә юк һәм кайда юк.

Сүзләрең тормый синең тыңлауга да,
Йөрми торган акча нәрсә сәүдәдә!»

Ушбу сүздән кош бераз хәсрәтләнә,
Бай учыннан башлый ул сүзгә янә:

«Үткән эш кайтмый, дигән сүзнең, җылап»,
Мәгънәсен әйтим, колак сал яхшылап:

Бер кабып куйсаң биш, ун, йөз мең белән,
Син җылап чыкма җә эчмә төн белән.

«Алма көч җитмәслек эш»тән шул морад:
Кермә Мәскәүгә, «бирә» дип, син ерак.

Хирсы берлән тәңкә артыннан куып,
Азмы калганнар тиен кулдан шуып.

«Төрле сүзләргә ышанмаска» кушам,
Чөнки һәркем үз уенча зур ишан.

Дәгъвасы: мин күп беләм, алдан беләм;
Эчләре тулган хата, ялган белән.

Кемдер әиткән: «Күктәге торна өчен,
Күп очырганнар кулында бар кошын».

«Сүзләрең иске. Шулай да бул азат,
Бар, югал күздән, сине итмим газап!»

Тукталыштан абзый шул чакта туеп,
Китте юлдан, кулларын артка куеп.

Тиз-тиз атлый күпкә Бай өстендә эш,
Тик оча, калмый аның өстендә кош.

Абзыйның ул җә колагыннан үтә,
Ул ягыннан җә бу ягыннан үтә.

Абзыйның бәрлеп китә дә борнына,
Шунда булган бер якын йортка куна.

Абзый әйтә: «Мин азат иттем сине;
Нәрсә бу? Мыскыл итәмсең син мине?»

«Синдиләрне, ап-ачык, шәрран яра,
Һич зарар юк күпме кылсаң мәсхәрә.

Эзләмим читтән мисал мин, син менә,
Бәрфараз, булса бик аз фәһмең генә,

Булмага мөмкин идең бит бай кеше,
Сәүдәгәрләрнең күгендә ай кеше.

Әмма вакътың үтте тыңлап әкиятем,
Тыңлаганга, билгеле, күп «рәхмәтем».

Син мине тоттың. Беләмсең, шул чагын
Тиз генә ярсаң иде син корсагым,

Күрер идең зур асыл таш ятканын,
Мәңге байтырга кәфил шул тапканың.

Бер дә ялгансыз, күкәйдән зур таш ул,
Дөньяда юк, булса да тик бер таш ул!

Син үләр чакта бу байлыкка батып,
Тик гакыл юктан карап калдың катып».

Мондый сүздән абзыйның үзгәрде төс,
Ул песи күк булды әйтелгән «прес!»

Алга, артка атлый алмый ул кыеп,
Һәм баса никтер аяклар да кыек.

Аптырый, ботка суга, «ах» дип куя,
«Ах, җүләр мин, ах, мин ахмак!» дип куя.

Шунда да уйлап таба бер хәйләне, –
Хәйләле дөнья, диләр, бит файдалы.

«Ләктереп» булмас микән дип бер тагын,
Бай чәчәргә башлый юк сүз борчагын.

Ул килә кошка таба җылшып кына,
Алдалап тотмаммы дип, тыршып кына.

Йөртә, урнында тоталмый күзләрен
Һәм үзенчә башлый хәйлә сүзләрен:

«И кошым, син мескнем, син Чыпчыгым,
Мин сөйлим, тыңла сүземнең чып-чынын.

Мин карыйм һәм дә күрәм: кош халкы сез,
Валлаһи, дим, мин сиңайтим, жалкы сез...

Йорт-нигезсез, анда оч һәм монда оч,
Шәпмени, җә, бу чегәннәрчә тормыш?

Җәй көнендә – анда яхшы, ичмасам;
Куркыныч бит кышны сезчә кышласаң.

Ул кара көзнең кыраулы кырлары!
Чиркәнеч һәм вак, суык яңгырлары!

Кыш тагын да: кар, яман салкын буран!
Очмыйлар кошлар өшүдән куркудан.

Әмма йортларда минем соң улмыни?!
Анда бар: ни нәрсәне күңлең тели.

Мич ягабыз, булса салкын, эсситеп,
Җәй көнеме дип торырсың, ис китеп.

Һич исәп юк, бездә бик мул аш та су,
Һәр заман күрнеп тора артып ташу.

Син очып йөргәнче, кошчык, пррр да пррр!
Ташла иске тормышыңны – бездә тор».

Билгеле, кош алдавын Байның белә,
Абзыйдан ул кяһкаһә берлән көлә:

«Абзый! Абзый! Булмаган син, пешмәгән,
Корсагың үскән, ә гакълың үсмәгән.

Дәгъвалыйсың, сүзгә шәп тә телгә шәп;
Эш гакылга килсә, нәкъ син бер ишәк.

«Үткән эш кайтмый» дигәнне аңладың,
Син мине тоттың да саклый алмадың.

Син җылыйсың, һәм дә күңлең кайгыра,
«Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, җыла!»

Һәрвакыт чиксез пошар инде эчең,
Хәсрәтеңнән, бәлки, ташларсың эшең.

Һәм хәзер «алма көчең җитмәслек эш»:
Мин тотылмыйм – хәйләлә син һәм җылыш.

Сездиләргә сезчә: «Чыпчык баш», – диләр,
Әмма бездә сездән артык баш, миләр.

Мин: «Ышанма төрле юк-барга», – дидем,
Син минем юк әкиятемгә баш идең.

Син, түгел адәм, ышандың кошка да,
Инде ләкмәм җәйгә дә һәм кышка да...

Аңладыңмы? Өч хәкыйкать шул иде,
Һәр өче мәкъбуль иде, мәгъкуль иде.

Соң, җүләр, азрак кына уйлап кара:
Ул минем эчтә асыл ташлар кая!

Җитмәсә, ул таш күкәйдән зур тагын,
Ул сыярлыкмы минем соң корсагым?

Син үзең учлап тотып тордың мине,
Иң-буемны үлчәдең, күрдең мине:

Бер күкәй хәтле бөтен гәүдәм дә юк,
Бәс, синең хәтле җүләр адәм дә юк!»

Сүкте Чыпчыкны, төкерде җиргә Бай,
Көлкегә калганга хурланды бугай.

Бай бу эшне әйтмәде һичкемгә дә,
Ачмады серне хатынга, иргә дә.

Булган эшне чәчми йөрде ул һаман,
Торды яшьреп нәкъ егерме ел тәмам.

Тик фәкать бер көнне «башка ис тигәч»,
Азрак эчкәч, башка киткәчтән «пирәш», –

Кемгәдер ул иске серне итте фаш,
Бәлки, шагыйрь шуннан иткән икътибас.

БАЛКАН КӨЙЛӘРЕ

**I**

Төркия бетә
Дип һәркем көтә, –
Балканнар эше
Гел алга китә.
Тик шул Әдернә
Алынмый менә.
Яния, Шкудра
Тиде теңкәмә.
Чыталҗа яман,
Аузы тулган кан,
Туплар дисеңме,
Зурлар дөньядан.
Ай-һай, Чыталҗа,
Син майлы калҗа;
Сине йотмыйча,
Истамбул кайда?

**II**

Сүзләр куештык,
Дүртәү сугыштык;
Зур кошлар төсле,
Лондонга очтык.
Монда төрекләр –
Ямьсез терекләр –

Авызларыннан
Чәчәләр утлар!
«Сез кемсез, – диләр, –
Без төркез», – диләр;
Җиңелдек дип һич
Өмет өзмиләр;
Диләр: «Госманлы
Өч истихкямны
Кулда тотканда,
Туктатмас канны.
Артык шаулыйсыз,
Бик күп даулыйсыз.
Нигә тарихтан
Гыйбрәт алмыйсыз?
Руслар да җиңде,
Якынгук килде;
Аңар нәмсәләр
Күпме җир бирде?
Курыкма, нәмсәләр –
Безнең кемсәләр,
Вильһелем лаек,
Калиф дисәләр.
Безгә бар да бер,
Итсәгез сабыр,
Чыталҗада да
Сезгә бар кабер!»

**1913**

ШИҺАБ ХӘЗРӘТ

Һәрбер имам бездә койрык булган чакта,
Койрык сүзе безгә бойрык булган чакта,
– Фәлән сәләф фәлән әйткән, фәлән бул, – дип,
Җаһил мулла әмер бойрып торган чакта, –

Чыкты, ахры, бездән дә бер бөтен кеше,
Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше;
Татарда да гыйрфан уты кабынганны
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.

Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.

Ул итсә дә хәдис, аятьне күп нәкыль,
Булып бетми аның гакълы нәкыльгә кол;
Инсан дигән шәрәфле бер мәхлукта ул
Бар дип белә хаким гакыл вә хөр гакыл.

Дәлил итә «Тәзәккәрү!» аятьләрен,
Раушан итә шул аятьнең һәр якларын;
«Тәфәккәрү!» аятьләрен таяк итә
Тик белгүче муллаларга тамакларын.

Аңлангачтын Коръәндәге бик күп серләр,
Үз-үзендән агаралар дини керләр;
Бу эшләргә Шиһаб хәзрәт сәбәп диеп,
Даһи кулын үбә башлый күп мөнкирләр.

– Кемнән алдык дин фикрендә истикъляльне?
Кем ташытты ушбу бәхет, бу икъбальне?
Ничек өздек «уйлауда да» коллык җебен? –
«Хәзрәт»тән ул безгә мирас булып калды.

Чыкты, әлбәт, бу даһигә сәфил дошман;
Чыккан дошман мәгълүб булып чыкты эштән.
Олугълыкта, өстенлектә Шиһаб хәзрәт
Этләр буе җиталмаслык җиргә кичкән.

Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм,
Шәрәфәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм;
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне
Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм!

ЙОКЫ АЛДЫННАН

*(Русчадан мокътәбәс)*

Гафу әйлә, кичер мине, Ходам җаным,
Бик еш була кәҗәләнеп җылауларым;
Кайсы чакта артык шаян булып китеп,
Берчак юктан гына ямансылауларым.

Кичрелсәче, Тәңрем, бәгърем эти, әни,
Дәү әнием, апайларым, бабай, әби;
Хозурыңда гәүһәр яшем түгеп телим,
Кабул әйлә, Тәңрем, әле мин бик «нәни».

Йокымда да күрсәтмәгел яман төшләр
(Аннан куркып уянгалыйм һаман кичләр);
Иртә белән мин торганда, матур булып,
Гөрләп торсын шытыр-шытыр янган мичләр.

Һәм бер эшне әнкәемнең иснә төшер,
Дисен аңар бер фәрештәң: «Коймак пешер!»
Иртә белән коймак ашап чәй эчкәчтән,
Тәңрем, сиңа кыйлырмын мин меңләп шөкер.

Иртәгә көн матур булсын һәм бик аяз,
Бакчабызда төрле кошлар бирсен аваз;
Шаян энем курчакларга тимәсен лә! –
Бигрәк монсын изге ләүхелмәхфузга яз!

СУЫК

**1**

Рус мәүлүде үтеп китте, көннәр суык,
Колакларда, борыннарда өрлә куык;
Җылы мичсез кибетләрдә сатучылар
Малын сата, бии-бии кулын уып.
Байлар кигән тиен толып, төлке толып,
Үз фикренчә, Печән базар күрке булып;
Куллар сузу, ялангачлык, ертык җилән
Күрнә аңар кызык булып, көлке булып.
Хулиганнар груһлана казенкага,
Суык чөнки – сызлый арка һәм җилкә дә;
Ушбу халык, кабак ничек ачылгач та,
Бик нык суга гөнаһы юк бутылкага, –
Диеп аңар: «Эчеңдәге суың чыгар,
Аның белән безне җылыт, безне сугар;
Эчтән безгә бишмәт киерт, чикмән киерт,
Көчле хәмер! Синең кулда зур ихтыяр».
Шәкерт белән школьниклар тиз-тиз атлый,
Йөгрә алар, колакларын саклый-саклый;
Дошман шәкерт, школьниклар арасында
Бу хәл – суык мәҗбүр иткән иттифак, ди.

**2**

Юлга чыксаң – җилләр каршы, туры була,
Буран чыкса – адаштыргыч юлы була;
Кинәт кенә җиккән атың туктап кала,
Җаның курка: карак очрый, бүре була.
– Монда кара, явыз, усал, мәлгунь бүре!
Тамагыңа күсәк белән лом кергере;
Мужикларның тырма теше кеби тешең
«Мәгыйшәтче» мие мислендә чергере!
Нигә соң син мескин мәҗбүр мужикларны

Талавыңда беләлмисең хәд-чикләрне?
Мужик әллә сиңа азык булып туып,
Җирән атын сиңа булсын дип җиккәнме?!

**3**

Суык инде; Кабан күле чынлап катты:
Юргаларга башлар инде байлар аты;
Көн юргала, төн юргала, тик юргала, –
Узалмассың «акыллы баш» Ишморатны.
Әүкатлене тешли алмый салкын, суык,
Черек күлдә, берсен-берсе куып-куып,
Җегет белән кызлар йөри шаркылдашып,
Боз өстендә тимераяк берлән шуып.

**4**

Никтер кичә озак йөрдем урамда мин,
Гаҗиз булдым эчем-тышым туңганга мин;
Җылныр өчен берәү белән сугъшыйм, димен,
Юлда торып, кеше сайлыйм сугарга мин.
Күрдем шунда: берәү бара таза гына,
Өсте-башы чибәр генә, яңа гына;
Читкә генә карап барган чагы иде,
Мин «чалт!» итеп менеп төштем яңагына.
Сиздем шунда: тәнем җылнып китте, кызып,
Дөп! дөп! итә мине сыйлап төшкән йозрык;
Явыз тагын артык җылтып куймасын дип,
Без бәндәңез бик тиз генә торып «сыздык».
Читкә киткәч, гайрәтләнәм мин абзыйга:
«Тукта әле, бирермен, дим, мин аузыңа!»
Тагы килеп абзам берне бирмәсен дип,
Атлыйм үзем артка һаман аз-аз гына.

**5**

Рус кардәшләр бигрәк каты кыйлды бәйрәм,
Бик күп семья башы эчеп улды әрәм;
Былтыр, хәер, безнең кайсы бәйрәмдәдер,
Татарлар да үлде эчеп берән-сәрән.
Эчә халык суык дип тә, бәйрәм дип тә,
Эчә халык хәләл дип тә, хәрам дип тә;
«Кытайский әфлисуннар яшьнектә», – дип,
«Эчми үткән яшьлек гомре әрәм», – дип тә.

**Халык җыруы:**

Кытайский әфлисун
Килә, диләр, яшьнектә;
Картайгачдин үкенерсең,
Типтереп кал яшьлектә!

ХӘСТӘ ХӘЛЕ

Көн туа. Һәр көнне хикмәт, мәгънәдән буш эш күрәм;
Күз йомалмыйм төн буе, йомсам – коточкыч төш күрәм.

Юк янымда чын кеше, булганда да – мин чит күрәм;
Белмәдем капшап, фәкать һәр йөздә кәгазь бит күрәм.

Бетте иман, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәткә тәмам;
Бәйле корбанлык кеби, алда кызыл кан, ит күрәм.

Бар хәятым салкыныннан туңды җан, катты күңел;
Һәр ягында бар җиһанның зәмһәрирдән чик күрәм.

Кышта очкан күбәләк төсле гүзәл кызлар миңа;
«Ник йөриләр?» – дим, кирәксез бер чуарлык дип күрәм.

Җиргә нык басмыйм – аяк астымда йомшаклык күрәм;
И үлем! Мин синдә бер хәсрәт вә бер шатлык күрәм.

Акмый тышка мәгънәләр – кипкән күңелнең чишмәсе;
Калган урнында һәлакәт чокры, баткаклык күрәм.

Юк нәҗат, фикрем чөерсәм дә үземнән үзгәгә;
Козгын – ислам гәүдәсендә, кәгъбәсендә пот күрәм.

Тик болай бер аурумынмы? Әллә Обломовтамы?
Көн саен йөз сулса сулсын, җанда ник кытлык күрәм?!

Ауру җанның бишмәте-тәнне дәваның төрлесе
Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм.

Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,
Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм!

## ӘНВӘР БӘК

*(Кечкенә ядкяр)*

Әллә кем Әнвәр?!
Әллә җен Әнвәр?
Әллә фәрештә?
Әллә пәйгамбәр?

Әллә мең җаны,
Таумы – вөҗданы?
Дөньядан гали
Фикре – изганы.

Күңлемдә булган
Аңар хөсне зан
Инде, һичшиксез,
Чикләрдән узган.

Тагы бер Гайса
Дарга асылса,
Рәфгъ итәр төсле,
Әнвәр бәк булса.

Табынмый потка,
Ибраһим утка
Атылган, минчә,
Әнвәр бәк юкка.

Өхед дошманы
Рәсүлулланы
Таш берлән орды –
Акты теш каны.

Шунда пәйгамбәр
Янында Әнвәр
Булса, шатланмас
Иде мөнкәрләр.
Шиксез, Бәдердә
Шатлык хәрбендә
Әнвәр бәк рухы
Булгандыр бергә.

Әнвәр шундый нам –
Ул җанлы Ислам,
Госманлы түгел,
Ул үзе Госман.

ДАҺИГӘ

Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн;
Киттең эзләп син, аны яктыртмага, идеал утын.

Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син,
Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син.

Мин әле хәйран һаман да, белмәдем ни булганын;
Нәрсәгә артка карыйсың, утка калгач бер адым?

Ялтырау күрдеңме артта? Ут түгел ул – алтын ул;
Юк мөкаддәс нур да анда, юк җылылык – салкын ул.

Изге юлны һәрвакыт алдап шулай кыскарта ул,
Син сатылмассыңмы дип, фикрең үзенә тарта ул.

Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса – Алла ул!

ТОЛСТОЙ СҮЗЕ

Зур бәхет инсанга – һәр көн, һәр сәгатьтә яхшыру;
Яхшыру юк, булса анда «Яхшы мин!» дип лаф ору.

ОЛУГЪ ЮБИЛЕЙ МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ
ХАЛЫК ӨМИДЛӘРЕ

**1**

Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «Мөнафис» нам канат.
Җыйла халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.

**2**

Һәр күренгәндә шимальдән ак болыт,

Без көтеп тордык өмидләр, шат булып, –
Дип аны: ул падишаһ һәм тәхтедер,
Дип: шушында без татарның бәхтедер,
Дип: гариб башларга энҗүләр төшәр,
Мәңге михнәт, мәңге рәнҗүләр кичәр.

**3**

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,
Без шаярыштык, вакытлар алмашып.

**4**

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –
Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук!

**5**

Падишаһ, бу көнге парлак бәйрәмең
Котлыйдыр йөзләрчә мильон адәмең.
Җыйла халкың ак канатың астына,
Ихтирамән затыңа, зур нәслеңә, –
Төшсен әзрәк, дип, күләнкә безгә дә,
Бәлки, кипмәсме бу яшь, дип, күздә дә.
Һәрвакыт: «Юкмы мөнафис?» сүзләре,
Тилмерә эзләп җиңеллек күзләре.
Бер сүзең – мең канлы коллар гафведер,
Бер ишарәң – мең җинаять мәхведер.
Зур «Мөнафис» берлә җанлансын халык,
Бар моңын, барлык зарын өстән салып.

*

Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «Мөнафис» нам канат.
Җыйла халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.

## КЫЙТГА

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

## ШӨҺРӘТ

Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт шөһрәткә син;
Бик төренмә, иртәгүк артык булыр чүпрәккә син.

Тапмасам шөһрәт, сизәлмәсләр димә күңлемдәген,
Зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син.

## ТОЛСТОЙ СҮЗЕ

Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга,
Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.

## ТӘФСИРМЕ? ТӘРҖЕМӘМЕ?

Һәр заман кем насры берлән фәтхе килсә Алланың,
Һич тә бер көч туктаталмый, манигы булмый аның.

Син күрерсең тугъры юл тапканны күп төркем халык,
Хәмд-ү-тәсбих өннәре берлән гөрелдәр урталык.

Мәккәдә ачты бүген якты иманга баб Ходай,
Ярлыкау эстә, шөкер ит, тәүбә кыйл, тәүваб Ходай!

## МӨХӘРРИРГӘ

*(Кыйтга)*

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!

Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!

Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.

Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.

Алты ел торды чупансыз, айрылышты яшь көтү;
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

«Ул Гомәрдән курка шәйтаннар» дигән төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя...

## ТОЛСТОЙ СҮЗЛӘРЕ

Һичвакыт булмый пәшиман садә тордым дип кеше;
Кан җылый күп чакта фәүкыльгадә тордым дип кеше.

Җан тынычланды димә, булганга малда артыгың,
Артык ул – алганга нәмәгълүм гарибләр актыгын.

Эстәмимсең буй бөгәргә? Ирнәсең эшләргә эш?
Йә телән син, йә фәкыйрь кардәшне көчләргә кереш!

Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары,

Күп вакыт борчы, тозы – мескин гидайлар яшьләре.

## КЫЙТГА

Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән бу баш.

*

Булмый Пушкин шигърене һич хаинанә үз итеп,
Булса да «Әлхәм» уку ул өр-яңа бер сүз итеп.

*

Аузын эт япмас, фәкать уйнар гариб сазым минем,
Мокътәбислектә Жуковский – зур остазым минем.

## БУШ ВАКЫТ

Безгә ят-чит телдәге изге фикерне тәрҗемә
Биш вакытта биш намаз күк керде инде фарзыма.

Бу «Толстой сүзләре»н дә хасладым буш вакътыма,
Күп вакыт моңлы күңелнең саф, аяз, хуш вакътына.

Әйтмәгез: «Ул – иске сүз, «Гайнел-гыйлем»дә күп иде»,
Әйтсәгез, сездән сорыйм мин: бездә нәрсә юк иде?!

## МӘКТӘП

Мәкаль бардыр: «Урыс байса – сала аулында дәү чиркәү;
Татар байса – хатын асрый, була хатыны өчәү-дүртәү».

Гүзәл тәфсир кыйлынса, бу мәкальдән ушбудыр матлаб:
«Урыс байса – сала чиркәү, вәләкин әүвәле – мәктәп».

## КАЗАН

Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан.

**ТУКАЙНЫКЫ БУЛУЫ ИХТИМАЛ ШИГЫРЬЛӘР**

## ЯҢА ЧЫКТЫ

Укымаган мәхдүмнәрне мулла кую яңа чыкты, –
Мәскәү малын ябып калу яңа чыкты.

Әүвәлдәге хаҗилар суфи иде, –
Хаҗи булып кеше алдалау яңа чыкты.

Әүвәлдәге ишаннар да тәкъва иде, –
Ишан булып акча җыю яңа чыкты.

Мөселманнар бер-берсенә кардәш иде, –
Хулиганлык, шпионлык яңа чыкты.

## ҖАБИР ХӘЗРӘТ МАКТАНА...

Утыз биштә мәхәллә башы булдым,
Кырык яшьтә Дума әгъзасы булдым;
Бу хәзрәттә дини хис бар, диделәр,
Думада динне бу саклар, диделәр.

Бу көндә мин ишанлыкның юлында, –
Тройскидән шәһадәт бар кулымда.
Бу көн мин – «Дин-мәгыйшәт»кә язучы
Вә яшьләр юлына чокыр казучы.

Вәгазь әйтәм халыкка җомгаларда,
Котыртам: каршы торсыннар аларга.
Симердем мин – сигез пот булдым инде:
Ашаганым мөселман ашы сеңде.

## ТАБЫШМАКЛАР

Җан сатар, вөҗдан сатар,
Белмим-беләм юк – лаф атар;
Искелекне сөрмә иткән. –
Тап, бу кем?! – Белдем: татар.

Яз эреп беткәндә кар, боз
Һәм никях вакътында кыз
Күл ясыйлар күз яшеннән. –
Җә, бусы кем, тапчыңыз?

Ат дисәң, арбасы юк һәм
Күздә канлы яше чук;
Йөгрә көн-төн, юк йокы, арганы юк.

Куркадыр: тозсыз бу ашым,
Тагы калган кайнасы;
Зәһрене сачә моңарга. –
Кем бу? – Бар кайнанасы.

Ал галстук, ак яка,
Шып-шыр кесә – байлык сата;
Кыш буенча тук була бу,

Ач җатадыр җәй ката.

Мәгълүмат тездән, белем шәп!
Юк сүзендә бер хата.
Белмидер үз үлчәвен. –
Әйт, кем булыр бу сапсата?

БӘНДӘЛӘР

Нинди күп бездә ятимнәрне талаучы бәндәләр!
Җантимерләрнең итек астын ялаучы бәндәләр.

Ярлыга ярты тиен артса – җылаучы бәндәләр,
Күзгә, ачларга аяп, төкерек сылаучы бәндәләр.

Күп, шөкер! – Бездә исәпсез күп иманлы бәндәләр,
Әмма юк соң, юк туры динле вә җанлы бәндәләр.

Бай халык! Бай милләтемдә шактый ишле бәндәләр,
Тик... Ходай, ник каргадың? – юк бер дә башлы бәндәләр.

Бездә бар комган, читек, казылык сатучы бәндәләр,
Бармы ачларга сынык икмәк атучы бәндәләр?

Без хәез-истинҗаны ятлап та белгән бәндәләр,
Без «фани» тормышны ташлап, бик тиз үлгән бәндәләр.

Бездә бик күп бит «Мөхәммәдия» көйләүче бәндәләр,
Тик менә... бик-бик сирәк идеал биләүче бәндәләр.

Бездә байтак зур авызлы, оста телле бәндәләр,
Тик күренми күпне белгән, тук күңелле бәндәләр.

Ис тә киткеч бездә күп зур-зур сакаллы бәндәләр,
Әмма һич артык күренми хәлле-маллы бәндәләр.

Бездә аз-маз чыккалый динне танучы бәндәләр,
Бармы мәзлум кыз-хатынны кызганучы бәндәләр?

Күп – «мөселманлык калыпта» дип белүче бәндәләр,
Күп – газаплы, көчле яшьләрдән көлүче бәндәләр.

Юкмы диңгезнең суын зәмзәм дип эчкән бәндәләр?
Бармы бер чында адәмлеккә ирешкән бәндәләр?

Бездә беткәнме оятсыз, исрек, азгын бәндәләр?
Бармы үз халкын сөеп эшләүче алтын бәндәләр?

Бездә, шиксез, күп – намазны ташламаучы бәндәләр,
Азмы таз башлыкны пакь дингә ямаучы бәндәләр?

Бездә бар: «Илһам, каләм – сатлык», – диюче бәндәләр,
Ак яка, тарту, эчү – «аклык» диюче бәндәләр.

* * *

«Амур» – фәхеш рестораны,
Яшәп килә күп заман.

Шул «Амур»да мөселманнар
Хаҗ кыйлалар тидия.

Әгәр булса җомга көн,
Бер дә кайтма – шунда кун;
Гаҗаибләр, гараибләр
Син күрерсең тидия.

Әгәр белсәң мулланы,
Укып чыккач җомганы,
Кыткылдагач тамагы,
Вәгазь сөйләп тидия,

Әкрен басып җыш кына
«Амур» якка ычкына.

## ЯЛГЫЗЛЫКТА

[*«Шагыйре мәшһүр» Вакыйф Җәлалигә тәкълид*]

Мин уйлыйм, йә көләм, йә егълыймын да,
Мин уйныйм, һәм йөрим, һәм йоклыймын да;
Мин ашыйм, йә эчәм, йә кикрәмен дә,
Мин йөрим һәм торам, һәм сикрәмен дә;
Мин төчкерәм, йә пошкырам, йә какрамын да,
Мин мышныйм, һәм сөйлим, һәм акрамын да;
Мин киенәм, йә тишенәм, йә ябынамын да,
Мин сөртенәм, йә таям һәм абынамын да, –
Шуның өчен сине яратамын да.

## ИСКӘРМӘ ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

## 1909

7 бит.

**Күңел.** «Әлислах»ның 1909 елгы 10 февраль (60 нчы) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев шигырьләре, 3 нче дәфтәр»нең 2 нче басмасына (1909) һәм «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Шигырьнең соңгы юлындагы *«саклау»* сүзе «Әдәбият»та *«җуймау»* дип үзгәртелгән.

Текст «Әдәбият»тан алынды.

Тукай әлеге шигырен «Күңел җимешләре» исемле китабының тышлыгына эпиграф итеп урнаштырып, беренче строфа икенче юл башламын «Бел, сөекледер...» дип үзгәрткән.

Кәбир Бәкер «Йолдыз» газетасының «Яңа әсәрләр» бүлегенә урнаштырылган бәяләмәсендә «Әдәбият» җыентыгына уңай бәя бирә: «Бу мәҗмугада дәрҗ ителгән шигырьләр шагыйрь әфәнденең иң соңгы вә бер кыйсеме дә матбугатка бертөрле дә кермәгән яңа шигырьләрдер /.../ бередә бик оригинальный шигырьләр дә бар. «Тәрәддөд вә шөбһә» шигыре мисалында шагыйрьнең рухи халәтендәге өметсезлек, хандра, шөбһәләрнең вакытлы бер нәрсә икәнлеген күрсәтә. Бәяләмә «Тукаев шигырьләре, кирәк кафия, кирәк вәзен җәһәтеннән булсын, чын татар шигырьләредер... Тукаев шигырьләрен укыганда, гаҗәп бер җиңеллек, кафия вә сәҗегъләрнең татар гармониясенә тәмамилә килеп торганлыгы хис ителә.

Шуның илә бәрабәр мәгънә җәһәтеннән дә бөек бер галилек, чын шагыйрьләрдә генә була торган муаффәкыятьлек күренеп тора. Шуның өчен Тукаевны «чын татар шагыйре» дип танучы вә аның шигырьләрен иң әүвәл тәкъдир итүче Фатих Әмирхан вә Борһан Шәрәф әфәнделәр алданмадылар дип беләм».

«Күңел җимешләре» җыентыгына авторның 1908 елгы фоторәсеме урнаштырылган һәм «Сабах» идарәсенең «Берничә сүз» бирелгән: «Габдулла әфәнденең шигырьләре, аларның әдәбиятымыз эчендә алган мөхтәрәм урыннары тугрысында сүз сөйләп тору гаммәгә мәгълүм булган бер хакыйкатьне тәкрар булыр иде.

Халкымыз тарафыннан хосусый бер игътинаэ вә хосусый бер шок белән укыла торган бу шигырьләр, эчләрендәге милли аһәң, милли хиссият, милли гармонияләре белән күптән инде татарның йөрәгенә тирән бер эз калдырып киләләр. Кавагыйде әдәбия җәһәтеннән нәзым вә шигырьләрне аерырлык хәлгә һаман әле килеп йитмәгән халкымызның да төрле гонваннар астында нәшер ителә торган әллә никадәр нәзым мәҗмугалары белән Габдулла әфәнденең шигырьләрен саташтырмавын хәтеремезгә алсак, бу шигырьләрнең татар күңелендә никадәр тирән хис калдырганлыгын тугъры тәхмин итәрмез. Шулай, Габдулла әфәнденең гомуми шигырьләренә вә аларның әһәмиятенә даир сүз сөйләп торырга хаҗәт юк. Фәкать бу «Күңел җимешләре» мәҗмугасындагы бер хосусият аерым игътибарны җәлеп итәдер. Габдулла әфәнде мәҗмуганың иң өске бер йиренә: «Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!» – дигән девизын язып куя да, шул юлны тәгъкыйб итеп китә: күңел чынлап та яна, чынлап та сызлана. Ул әүвәл эзләнеп карый, ниһаять, бер тынычсызлык һәм гасабилык белән тормышның кадагын, иң мөһим нурлы бер почмагын табарга тырыша.

/.../ Без бу мәҗмугада Габдулла әфәнде Тукаевның әүвәлге мәҗмугаларында очралмаган рух вә халәте рухиягә очрыймыз. Шагыйрьнең үзенчә тәгъбир иткәндә, аның каләме астында хәзер инде «Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы», бәлки, «Хәзер генә сыгылып, сыгылып җылаган яшь»нең зур-зур тамчылары коелалар. Кем белә, бәлки, бу рух вә бу мәсләк шагыйремезнең мөстәкъбәлдә язачак бөтен шигырьләренә баш мәсләк булып китәр. Ул вакытта бу мәҗмуга шагыйремезнең тормышында вә рухындагы иң мөһим бер инкыйлабның башлап тышка чыгышы булачактыр.

Менә шуны хәтергә алып, без дә мәҗмуганың бу хосусиятенә, Габдулла әфәнденең шигырьләрен истиля итә башлаган бу рухка кариәләремезнең хосусый дикъкатьләрен җәлеп итәмез. Һәрникадәр вазифа тәнкыйтьчеләргә раҗих бер вазифа булса да, вакытлы матбугатымызда әдәби әсәрләр тәнкыйденә бик аз урын бирелү һәм билнисбәтән бик аз әһәмият бирелү сәбәпле бик күп хосусыятьләр тәнкыйтьчеләр тарафыннан бөтенләй игътибарсыз уздырыла икәнлеген хәтеремезгә алып, без берничә сүз әйтеп китүне үз вазифамыздан тыш санамадык. «Сабах» идарәсе».

Китапның соңгы 47–48 нче битләрендә Тукайның «Сабах» көтепханәсе тарафыннан нәшер ителгән әсәрләре исемлеге һәм аларга кыскача аннотация урнаштырылган.

Җыентык «Теркәү дәфтәре» буенча 26 мартта дөнья күрә. «Шура» журналының 1911 елгы 7 нче (1 апрель) санында бу турыда түбәндәге язма бирелә: «Тәкърыйз. Габдулла әфәнде Тукаев шигырьләреннән гыйбарәт бер мәҗмуга улыб, «Сабах» тарафыннан нәшер улынмыштыр. Бунда Габдулла әфәнденең иң гүзәл шигырьләре интихаб иделенеб басылмыштыр. Бәгъзе берләрене «Шура»га нәкыль итсәк кирәк».

«Йолдыз»ның 1911 елгы 5 апрель (666 нчы) санында Галимҗан Ибраһимовның «Габди» имзасы белән басылган бәяләмәсе басылган. Аның тексты түбәндәгечә: «“Диван”, “Әдәбият” һәм “Җуаныч”» сахибе Габдулла әфәнде Тукаевның соңгы шигырьләре җыелып, «Күңел җимешләре» исеме илә мәйданга чыкты. Бер-бер артлы аккан мәҗмугалары эченә тагы берәү ялганды.

Башка мәҗмугаларында булган кебек, монысында да шагыйремез төрле мәүзугъ вә төрле мәтлабны кулга алган, үз рухының төрле һәм аерулы күренешләрен тасвир иткән. Монда кайгы да, көенеч тә, изтираб та бар; уен-көлке дә юк түгел; һәҗүләргә дә урын бирелгән. Дәхи бер җәһәте әүвәлдә бер гади һәм тупасрак ингыйкас ителә торган иман вә игътикад хисе – шагыйрьнең бу әсәрендә голүви бер рәвештә мәйданга чыккан. Буңа «Мигъраҗ»ы ачык шәһадәт итә. Бу мәүзугъләр вә мәтлабларның һичберсе Габдулла әфәнде өчен яңа вә башлангыч түгел – боларның орлыгы, төсе әүвәлге мәҗмугаларда да тулып ята. Ул мәйданга чыкканнан бирле кайгыра да, елый да, көлә дә, сүгә дә һәм вәгазьли дә.

Ул әллә кайчан ук:

Беттем мин, яшь малай, беттем гомергә;
Иске шан, эссе кан кайтмас гомер дә... –

мәзмунендә сүзләрне күп сөйләде, күп язды. Аның «Күңел»е, «Шөбһә вә тәрәддөд»ләре күптән бирле мәйдандадыр. «Вакъты гаҗезем» дә күз алдында. Шуның өчен дә мин бу мәҗмуганың мөкаддимәсендәге «Берничә сүз»не хаксыз

күрәм. Бу мөкаддимә кирәксез иде. Аннан гөнаһ исе чыгып тора. Нашир теләсә дә, шагыйрь әфәнде моны үзе керттермәү тиеш иде.

Габдулла әфәнде табигать белән бик дуст түгел. Аның җәмале гомумән шагыйрьләр өчен «Мөкаддәс зикер вә вирд» булса да, Тукаевка гаид мәҗмугаларда без бу зикерне бер дә очратмый, шуңа күрә аның хакында «җәмал вә нәфасәт белән мөнәсәбәте юк» дип нык ышанырга якын идек.

«Күңел җимешләре»ндә исә бу хакта бер яңалык бар. Шагыйремез шагыйрьләрнең «мөкаддәс зикер» булган җәмале табигатьне дә бераз сайрап куйган:

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата...

Тагын шуны әйтергә, Габдулла әфәнде хәзер үз хиссиятен әүвәлгеләрдән артык тулырак, киңрәк һәм ачыграк әйтеп җиткезә ала, һәм бундагы тәгъбирләр, ифадәләр биннисбә шигъри вә җанлылар.

Тел хакында исә бик мактап булмый. Без шагыйремезнең «Балалар күңеле» һәм «Җуаныч» теленнән бик күп ераклашуына тәәссеф итми мөмкин түгел.

Гарәп, фарсы сүзләреннән, чит тәгъбирләрдән арчылуы матлуб иде. Теләнгән мәгънәне бик ачык чыгарган шу зикер илә сүземне бетерәм:

И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Хәзергә җитәр».

9 бит.

**Васыятем.** «Әлислах»ның 1909 елгы 10 февраль (60 нчы) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «3 нче дәфтәр»нең 2 нче басмасына (1909), аннары «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Икетомлыкның 1 нче томында (1943) чыккан.

Текст «Әдәбият»тан алынды.

Шигырь 1909 елның гыйнвар ахырында Тукайның «Актык сүзләр» дигән фельетоны белән бер үк вакытта язылган; аларның матбугатта чыгу аралары ун көн генә.

Соңгы дүрт юлы, эпиграф рәвешендә, М.Бигиев язган «Рәхмәте илаһия гомумияте хакында борһаннары» исемле мәкалә алдыннан да бирелгән.

Тукай үлгәч, «Васыятем»шигыренең баштагы ике юлы шагыйрьнең үз васыяте буенча табуты өстенә ак ефәк тасмага язып эленә.

Әлеге шигырь кулъязмасының фотокүчермәсе бүгенге көндә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә саклана (9 ф., 1 тасв., 9 эш).

10 бит.

**Тәрәддөд вә шөбһә.** «Әлислах»ның 1909 елгы 18 февраль (61 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «3 нче дәфтәр»нең 2 нче басмасына (1909), аннары «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. «Әлислах»та һәм «3 нче дәфтәр»дә икенче юл – *«Шикләнәм...»*, 19 нчы юл *«Бер заманнар...»* дип башлана.

Текст «Әдәбият»тан (1909) алынды.

[1] *Ризван* – Коръәндә искә алынган оҗмах сакчысы.

[2] *Вилдан вә гыйльманым* – Коръәндә искә алынган оҗмахтагы хезмәтче егетләр.

11 бит.

**Хатыннар хөррияте.** «Яшен»нең 1909 елгы 7 нче (2 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «3 нче дәфтәр»нең 2 нче басмасына (1909), аннары «Әдәбият»ка кертелгән.

Текст «Әдәбият»тан (1909) алынды.

Тукай рус шагыйре В.В.Князевнең (1887–1937) «Либерал средней руки перед банкетом» дигән шигырен татар мохитенә якынлаштырып тәрҗемә иткән. Русча тексты түбәндәгечә:

– За женские права вступаю в смертный бой!
Вперед, соратники! Труби сильнее, пресса!
Да льется женский труд широкою рекой
В безбрежный океан всемирного прогресса!
Дорогу женщине! Да царствует она
На поприщах труда искусства и науки,
Как царствуем и мы!..
Позвольте-с ! Вот те на!
Да что ты, матушка, глупее что-ль, бревна?..
Ты только посмотри!.. Сюда смотри, на брюки!..
Ну! Это что?.. Пятно... Почистить было лень?
Измяты обшлага у глаженой рубахи,
Нет пуговиц совсем... И это каждый день!..
Ведь есть же, черт возьми, подобные неряхи!..

[1]*«Сатирикон»* – 1908—1914 елларда Петербургта рус телендә чыккан атналык сатирик журнал.

[2]*Чапаны да, Бохары да ашарга калсын этләргә!* – Бу юлда Бохарада һәм аның аркылы татарлар арасында да таралган хатын-кызны чапан бөркәндереп йөртү кебек күренешләргә шагыйрьнең тискәре мөнәсәбәте чагыла.

12 бит.

**Авыл җырлары (Өченче көлтә).** «Яшен»нең 1909 елгы 7 нче (2 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Ахырга «дүртенче вә бишенче көлтәләре бәйләнмәктә» дип куелган. Бу тәртиптә Тукайның үзе исән чакта чыккан җыентыкларында юк.

Текст «Яшен»нән алынды.

[1]*Унөч яшьлек кызга тисәң, хаҗның әҗре җуела.* – 1907–1908 елларда Казанда «Ончы хаҗи» дип йөртелгән бер сәүдәгәр – Гыйльметдин Ибраһимов – үзенең унөч яшьлек асравын көчләгән дигән хәбәр тарала. Соңыннан бу хәбәрнең дөрескә чыгуы, азгынлыгы, сатып алучыларны оятсыз алдавы өчен, Ончы хаҗиның суд җаваплылыгына тартылуы турында газеталарда хәбәрләр күренә.

[2]*«Сабах» сабын сатмыйдыр.* – «Сабах» – китап бастыру һәм сату өчен 1908 елда Казанда оештырылган сәүдә ширкәте; китаптан башка галантерея маллары белән дә сәүдә иткән. Тукай шуңа ишарәли.

[3]*Пәдрәтдин* (подрядтан) – югары булмаган бәягә яллап, бер үк төрле әйберне (товарны) күп эшләтүгә караганда, кыйбатрак түләп, аерым заказ белән эшләтү отышлырак дигәнне аңлата.

[4]*Дин гыйльменә бигрәк чумган Апанаев Бәдретдин.* – Тукай бу сәүдәгәрнең «Бәянелхак» ише газеталарда дини мәсьәләләр турында мәкаләләр бастыруына ишарәли.

[5]*«Чүкеч» сабын кимреп җылый «Яшен» суккан чагында.* – «Чүкеч» – 1906 елның июнь аеннан Оренбургта чыга башлап, 1910 елның мартына кадәр дәвам иткән көлке журналы. Нашире һәм мөхәррире – Тимерша Соловьев (1875–1947). «Әлислах» белән «Яшен»нән алдарак дөньяга килеп, ул үзен татарда юмор-сатира сүзен әйтә торган бердәнбер журнал итеп күрсәтергә омтыла. Әмма эчтәлеккә шактый ярлы була, формасы һәм рәсемнәре белән дә артык алга китә, зур эшләр күрсәтә алмый.

1908 елда Оренбургка барып, «Чүкеч»тә эшли башлаган Зариф Бәшири белән Тукай арасында еш кына каршылыклар булуы билгеле. «Чүкеч»не З.Бәшири «Әлислах» белән «Яшен»не сүгү, Әмирхан белән Тукайны хурлау органына әвереләдерә. Тукайның «Уклар» журналын чыгарганын күздә тотып, «...бывший мукшы, әй, яңлыш әйтәм, бывший укчы әфәнде» дип тә язып чыга. Монда Тукай Зариф Бәширигә ишарә ясый.

[6]*Сак берлән Сок кыяматтә берсен берсе очрата.* – Сак һәм Сок – халык авыз иҗатында, имеш, ана каргышыннан икесе ике фантастик кош булып очып киткән, берсен берсе күрә алмыйча, урманнарда «сак-сок» дип кычкырып очып йөргән ике бала. Алар кыямәт көнне – дөнья бетеп, барлык мөэминнәр кубарылып, Ходай каршына хөкемгә килгәндә генә очрашачаклар, имеш.

[7]*Биш талчокчы, өч фахишә театрны пычрата...*

*Театрны буяу җитми, концерт ясаган була.* – Казанда 1906–1907 елларда артист Габдулла Кариев (1886–1920) җитәкчелегендә «Сәйяр»(сәяхәтче, ил гизүче) исемле татар театры труппасы төзелә. Чын милли театр дәрәҗәсенә күтәрелеп, ул тиз арада халыкның мәхәббәтен казана. Әмма театрда сәнгатьтән ерак торган, әхлаксызлыгы белән аты чыккан адәмнәр дә була. 1908 елда берничә кеше «Сәйяр»гә каршы чыгып, үзләре театр һәм концертлар оештыра башлыйлар. Югарыдагы юллар шуңа ишарә.

[8]*Бәйрәмдә кибет япмыйм, дип, частан казак алдырма*. – 1905 елга кадәр приказчикларга атна арасында ял бирелмәгән. 1905 елгы революциядән соң, атнага бер көн кибетне ябып, приказчикларга ял бирү мәсьәләсе кузгалгач, моңа каршы төшәләр һәм, приказчикларны буйсындыру өчен, еш кына полиция дә чакырталар. Монда шул күздә тотыла.

[9]*Бөтен Казан абыстае агент хәзер Варшауга.* – Варшава сәүдә компанияләренең маллары бервакыт бөтен Казанны тутырып, игъланнары «Бәянелхак» кебек газеталарның битләрен күмеп китә; мода артыннан куарга яратучы хатыннарның телендә дә, гамәлендә дә «Варшау товарлары» була. Югарыдагы юллар шул хакта.

[10]*«Ай туган»да тусаңчы, айдай нурлы булсаңчы;*

*Яшьләр йөзен кызартканчы, «каралганчы» үлсәңче!* – Казанның атаклы сәүдәгәре һәм эшмәкәре, «Щетинкин номерлары» дип йөртелгән кунакханә хуҗасы П.В.Щетинкин (1846–1917) татар демократик яшьләре белән аралашып, алар тирәсендә чуалып йөргән Ибраһим Айтуганов дигән бер затны, төрле мәкерләре белән, христиан диненә чыгарга – чукынырга мәҗбүр итә. Үз вакытында бу хәл Казанда күп имеш-мимешләргә сәбәп була. «Казанда бер шарлатан чукынганга түзмәй, бөтен Казан мөселманнары хәрәкәткә килделәр», – дип яза бу хакта Г.Чыгътай. Тукай монда шушы хәлләрне күздә тота.

[11]*Безнең Муса һич тик тормас: яңлыш тапкан Коръәннән.* – Публицист, җәмәгать эшлеклесе, дини-фәлсәфи хезмәтләр авторы Муса Ярулла улы Бигиев (1875–1949; Муса Бигиевнең бертуган энесе) вакытлы матбугатта дини, әхлакый, иҗтимагый мәсьәләләргә кагылышлы полемик мәкаләләр белән дә танылды. Шигырь язылган вакытларда ул: «Коръәндә ялгышлар бар, төзәтергә кирәк», – дип чыгыш ясаган.

«Яшен»нең шул ук санында, «Авыл җырлары» урнаштырылган битнең икенче ягында шундый рәсем бар: чүплек өстендә кара түбәтәй кигән, күзлекле бер әтәч кытаклап, канат кагынып тора; кырыйга «Муса» дип язылган. Тирә-ягын эреле-ваклы, чалмалы тавык-чебешләр әйләндереп алган. Рәсем өстенә: «Кыт, кыт, кыт, кыт! Мин бер орлык таптым, киләңез, әйдә бергә ашыйк», – дип язылган.

Алга табарак, 11 нче биттә бирелгән «Йөз бүре күрдем» дигән фельетонда да Коръәндәге ялгышлар мәсьәләсе чагылыш тапкан:

«– Йөз бүре күрдем. Бөтен авылдагы сарыкларны ашап бетерү ихтималы бар.

– Ул кадәр үк булмас ла.

– Валлаһи менә, үз күзем белә күрдем, йөз үк булмаса да, сиксәнләп бар иде.

– Арттырасың ла, ул кадәр үк булмас.

– Ну, алайса, алтмышлап кына булсын.

– Ул да бик күп, алтмышлап бүре ничек итеп бер арага җыелып йөрсен, бүре түгелдер ул.

– Шулай да инде, алтмышлап булмаса да, кырыклап бар инде.

– Кырык бүре дә бик күп, аңар да ышанмыйм.

– Ну, ышанмасаң, егерме генә иде, алайса.

– Аңар да ышанмыйм, берни дә күрмәгәнсең!

– Валлаһи менә, берәү бар иде инде – ну, күргән.

– Булсаң, әйт инде алай, ни төсле иде?

– Мин аның ни төсле икәнен күрмәдем. Шулай да инде бүре булырга кирәк, әрәмәлек арасына бик чатырдап чабып кереп китте.

* * *

Шуның шикелле безнең Муса да Коръәндә йөз егерме кадәр бик зур хаталар күрде. Тикшерә башлагач, йөзгә, андан сиксәнгә, соңра алтмышка төшеп бара торгач, матбагада өтерне «уау» өстеннән бер миллиметр кадәр күчереп, «әлиф» өстенә куюда гына калды».

14 бит.

**Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә.** «Яшен»нең 1909 елгы 7 нче (2 март) санында идарәдән «Җаваплар» эчендә имзасыз һәм исемсез басылган. «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә» исеме белән шагыйрьнең «Яшен ташлары» дип аталган сатирик әсәрләр җыентыгына кертелгән. Текст шул басмадан алынды.

«Яшен»дә бишенче юлдагы *«рәзилләр»* сүзе «Яшен ташлары»нда *«сәфилләр»* дип, алтынчы юлдагы *«һәм»* бәйлеге *«йә»* дип төзәтелгән; ахыргы юлдагы күп нокталар урынына *«йөзгә каршы чүп белән»* сүзләре куелган.

«Яшен»дә шигырьнең ахыргы юлыннан соң «Чүкеч»кә тиебрәк язучы «Шома» әфәндегә: «Шигыреңездә ачу вә артык кызу галәмәтләре булганлыктан, һәммәсе басылмый», – дигән сүзләр бар. Тукай «Яшен»гә, «Әлислах»ка, үзенә, Ф.Әмирхан һәм Г.Камалга каршы әшәке «һөҗүмләр» белән чыккан чүкеччеләрне «котыртмас» өчен, бу шигырен уйлап чыгарылган «Шома» әфәндедән килгән хат рәвешендә бастырган.

Шигырь чынында «Чүкеч» журналында эшләгән З.Бәширигә каршы юнәлдерелгән. «Чүкеч»нең 1908 елгы июнь, 1909 елгы февраль ае саннарында З.Бәшири «Мөтәрҗим шагыйрьгә», «Ул дисезме?» исемле, Тукайга юнәлтелгән мыскыллы шигырьләрен бастыра. Тукайның «Җавап» шигыре боларга җавап итеп язылган дигән фикер бар. Әмма шигырь революциядән соң гына Тукайның кульязмалары арасыннан табылып басыла башлый. Ни өчен бу шигырьне Тукай бастырмаган, әлеге сорауга «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә» исемле шигырь җавап бирә шикелле.

[1]*Та әзәлдән ул сәфилләр үз-үзеннән бетмәдә:*

*Кауме Нухи – су белән йә кауме Люти – ут белән.* – Дини риваятьләрдә Нух белән Лут – үз кавемнәрен ислам диненә өндәргә Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәрләр, Аллаһы Тәгалә илчеләре. Ләкин халыкның күпчелеге аларны тыңламый, «сез – безнең кебек үк кешеләр, Аллаһы Тәгалә җибәрде дип ялганлыйсыз» дип, үгет-нәсыйхәтләрен кабул итми. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә Нух кешеләрен туфанда суга батырып, Лут кешеләрен җәһәннәм утына олактырып һәлак итә; алар кавеменнән иман китергән бик аз кеше котылып кала. Коръән сүрәләрендә бу риваятьләргә күп урын бирелгән. 71 нче – «Нух» сүрәсендә, мәсәлән, «гөнаһлары өчен алар суга батырылдылар һәм утка кертелделәр...» диелгән.

15 бит.

**Пәйгамбәр.** «Әлислах»ның 1909 елгы 29 март (65 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

Шигырь башына «Лермонтовтан үзгәртелгән» дип куелган. Әсәр М.Ю.Лермонтовның «Пророк» (1841) исемле шигыреннән файдаланып язылган. Ул шигырь түбәндәгечә:

С тех пор как вечный судия
Мне дал всеведенье пророка,
В очах людей читаю я
Страницы злобы и порока.

Провозглашать я стал любви
И правды чистые ученья:
В меня все ближние мои
Бросали бешено каменья.

Посыпал пеплом я главу,
Из городов бежал я нищий,
И вот в пустыне я живу,
Как птицы, даром Божьей пищи;

Завет предвечного храня,
Мне тварь покорна там земная;
И звезды слушают меня,
Лучами радостно играя.

Когда же через шумный град
Я пробираюсь торопливо,
То старцы детям говорят
С улыбкою самолюбивой:

«Смотрите: вот пример для вас!
Он горд был, не ужился с нами:
Глупец, хотел уверить нас,
Что Бог гласит его устами!

Смотрите ж, дети, на него:

Как он угрюм, и худ, и бледен!
Смотрите, как он наг и беден,
Как презирают все его!»

Бу шигыре турында Тукай 1910 елның 4 декабрендә С.Сүнчәләйгә язган хатында: «Менә Сәгыйть Рәмиев – Пушкин «Пәйгамбәр»ен, мин фәкыйрь дә Лермонтов «Пәйгамбәр»ен тәрҗемә иттек. Безнең икебезнең дә шактый шома чыктылар», – дип, бу ике фактның тәрҗемә сәнгате ноктасыннан татар поэзиясе өчен зур әһәмияте барлыгын искәртеп уза.

Тукайның «Пәйгамбәр» шигыре – Тукай иҗатының рус классикасы башлыча Пушкин һәм Лермонтов поэзиясе белән бәйләнеш нокталарын аеруча көчле чагылдырган тәрҗемәләрнең берсе. Билгеле булганча, Лермонтов «Пәйгамбәр»е дә Пушкинның шул исемдәге әсәреннән үсеп чыга һәм шуны дәвам иттерә. Аның да асыл девизы Пушкин «Пәйгамбәр»енең соңгы дүрт юлында бирелгән чакыруга аваздаш:
Восстань, пророк, и виждь, и внемли,
Исполнись волею моей,
И, обходя моря и земли,
Глаголом жги сердца людей.

Тукай исә Лермонтов «Пәйгамбәр»ен мөселман халкы тормышына якынайтып тәрҗемә итә, пәйгамбәр образына ислам тарихыннан алынган образ-сурәтләр өсти.

[1]*Гъадь* – Көньяк Гарәбстанда (Йәмәндә) яшәгән борынгы гарәпләр; исламны кабул итмәгән өчен Аллаһы Тәгалә аларны давыл (сәмум) белән һәлак иткән, имеш.

[2]*Сәмуд* – шул ук җирләрдә гъадь халкыннан соң килгән буынның исеме.

17 бит.

**Исемдә.** «Әлислах»ның 1909 елгы 21 апрель (66 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Әдәбият»ка кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

Әсәргә төшермәдә: «Бу шигырьне Габделләтыйф Мостафин тарафыннан телемезгә тәрҗемә кыйлынган русча бер пьесада күптән түгел генә гыйффәтен җуйган бер кыз үзенең бәхетле заманнарын сагынып җырлый. Пьеса басылып чыккач, анда укылса, тәэсире артыграк булыр», – дигән искәрмә бирелгән. Бу пьеса «Йиңел хезмәттә» дигән исем белән шул ук елда Казанда И.Н.Харитонов матбагасында басылып чыккан. «Русчадан сюжет алынды» диелгән. Тәрҗемәчесе Ләтыйф Мостафа дип күрсәтелгән. «Исемдә»не пьесаның төп герое Гайшә җырлый. Төшермәдә «Бу шигырьнең мөтәрҗиме мәшһүр шагыйремез Г.Тукаев» дигән сүзләр бар.

18 бит.

**Нумирга төшкән искеләр.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында басылган, аннары «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында «Яшен»нең шул ук елгы 9 нчы (21 май) санында, рәсем асты буларак, кабатлап имзасыз бирелгән. Рәсемдә: эшләпәле мужик, күкрәгендә чылбыр. Чылбырның бер башы кесәсендә. Ыштаны асылынып төшкән.

Текст «Әдәбият»тан (1909) алынды.

*Нумир* – кунакханәләрдәге бүлмә (номер) күз алдында тотыла.

20 бит.

**Дәүре галәм.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында имзасыз басылган. Тукайның үзе исән чакта басылып чыккан җыентыкларына кертелмәгән.

Текст «Яшен»нән алынды.

[1]*Йосыб китте сәяхәткә...* – Йосыф Хәсән улы Акчура (Акчурин, Акчура угылы; 1876–1935), журналист, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Сембер губернасы сәнәгатьчеләре Акчуриннар нәселеннән. 1904–1908 елларда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта. 1908 елда ул Төркиягә китә, Истанбул шәһәрендә төпләнеп, журналистлык һәм җәмәгать эшчәнлеген дәвам иттерә. Тукай монда Й.Акчураның Төркиягә китүенә ишарәли.

[2]*Рәшит икенчеләп китте...* – Габдрәшит Гомәр улы Ибраһимов (1853–1944), җәмәгать эшлеклесе, нашир, язучы, публицист. Матбугатта Рәшит казый буларак та билгеле. 1907–1908 еллар тирәсендә аның Япониягә сәяхәткә китүе мәгълүм. Япониягә сәяхәте уңае белән язылган «Дәүре галәм» («Дөнья әйләнү») исемле 160 битле истәлек 1909 елны Казанда басыла.

21 бит.

**Ишан.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында имзасыз басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

«Уклар»ның 1906 елгы санында ук мондый парча бар: «Шәкерт: Голяма вә ишан диюдән максудыңыз нәрсә? – Чапан кигән, зур чалма ураган, калын корсак сахибеме?»

Шигырь Миңлебай – камчылы ишан турында язылган. Тукайны шигырь язарга илһамландырган камчылы ишан турында Вафа Бәхтияров түбәндәге истәлеген бастырып калдыра: «Камчылы ишан Фатих Әмирханнарга каршы гына тора иде. Фатих Әмирханнарга барганда, Тукай берничә тапкыр камчылы ишанның мәчеттән чыгып килгәнен күрде. Моннан башка тагын 1907 елның ахырында беркөнне кич белән Фатихларда булдык. Фатихта бераз утыргач, кайтырга чыктык. Без чыкканда, капка төбендә байтак җигүле атлар тора иде. Башта, бу хәлне күргәч, бер «туй» мәҗлесе булырга кирәк дип уйладык. Сораштыргач, камчылы ишанның мөридләре белән гыйбадәт мәҗлесе икәнен белдек. Без дә кереп карарга булдык. Без кергәндә, өйнең залында мөридләр идәнгә түгәрәкләнеп утырганнар, түгәрәк уртасында зур чалма кигән камчылы ишан утыра. Шау килеп, «яһу, яһу, яһу» дип кычкырып утыручылар арасыннан берничәсе сикереп

торып, шул түгәрәк эчендә кычкырып йөри башлады... Бу күренештән соң озак та үтмәде, «Бер шәехнең мөнәҗәте» исемендәге шигырен язып чыгарды. Түбәндәге шигырь дә шул ук Миңлебай – камчылы ишан турында язылды».

Тукайның әлеге шигыренә мөнәсәбәттә З.Бәшири «Тутый» имзасы белән «Мулла» дигән әсәрен бастырып чыгара (исем астына «Г.Тукайның «Ишан» шигыренә гыйлавә» дип куелган). Анда түбәндәге юллар бар:

Укый Коръән вә тасылдый, тышаудай тәсбихы кулда,
Җыеп фасыйк монафыйкълар эшен эшли ул уртында.
Сират кичкән, Ходайның һәр газабыннан әман булган,
Кыяматтә шәфәгатьче була Шәмче Вәлиләргә,
Сата җәннәт билетларын, указ алган, имеш, шул да!

22 бит.

**Хәзерге өйләнүчеләр.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында имзасыз басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

23 бит.

**Булмый.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында имзасыз басылган.

Текст «Яшен» журналыннан алынды.

Бу икеюллык Тукай белән Сәгыйть Рәмиев арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләрне чагылдыра. Әлеге әсәр чыгу уңаеннан С.Рәмиев тә бу шигырьгә каршы түбәндәге юлларны яза:
Фахирмын мин тик үзем белән,
Үземнең үк сүзем белән.
Көчәнмә юкка, булалмассың
Кеше булып кыланучы,
Син ул маймыл, мин түгел,
Кара карга йә былбылмы,
Атсинчигем син түгел.

(Тулырак мәгълүматны «Хайлыйм, хайлыйм хайларга...» шигыре искәрмәсеннән карагыз.)

[1]*...чын таңчы һәм асла Гаяз булмый.* – Сүз 1905–1907 елларда таңчылар төркеме лидерларыннан берсе булган, язучы, журналист, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе Гаяз Исхакый (1878–1954) турында бара.

24 бит.

**Минһаҗ.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында «Һинди Минһаҗ» исеме белән имзасыз басылган. «Әдәбият»та (1909) «Минһаҗ» дип кенә калдырылган. Текст соңгысыннан алынды.

Шигырь Һинди Минһаҗ дип йөртелгән бер зыялыдан көлеп язылган. Минһаҗетдин Йосыф Кадерматев (1871–1925) дигән бу кеше, Һиндстанда укып кайтып, Саратов губернасы Хвалын өязендә һинд тибындагы дарелфөнүн (университет) салдырам дип, халыктан акча җыя, ләкин ул мәдрәсәне торгыза алмый. Шул вакыттагы татар матбугатында бу вакыйга сатира объекты булып китә. Мәсәлән, Тукай бу шигырен язганчы ук «Әлислах» газетасында ул хакта байтак материаллар чыга. «...Ачсак, без алай вакны ачмыйбыз – дарелфөнүн, мәдрәсәи галия, дарелфөнүн гали, әл-мәдрәсәт әл-галият фил Хуалин кеби высший школалар гына ачамыз. Руслар бездән гыйбрәт алсыннар!»; «...мәдрәсә Хуалин каласында тау башында Иделгә каратып салыначактыр».

Бу хәл «Яшен»дә түбәндәге рәсем-карикатураны урнаштырырга этәргеч бирә: тау башында шәһәр, уртада ак колонналы мәһабәт бина. Ул бөтен шәһәрне каплап тора. Арттан кара фәсле Һинди Минһаҗ башы күренә. Баштан тирә-якка нурлар чәчелгән. Рәсем астына «Хвалынский тавы башында Минһаҗетдин Йосыф тарафыннан салынган УНИВЕРСИТЕТ» дип язылган.

26 бит.

**Гласный.** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында имзасыз басылган. Тукайның үзе исән чакта чыккан җыентыкларына кертелмәгән.

Текст «Яшен»нән алынды.

Тукай бу шигыре белән «Чәйче Шәмси» дип йөртелгән кадимче бер байның Казан шәһәр думасына гласный (әгъза) булып сайлануыннан көлә.

27 бит.

*** **(«Хайлыйм, хайлыйм хайларга...»).** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган.

Текст «Яшен»нән алынды.

Рәсем-карикатурада Казан сәүдәгәре, «Бәянелхак» газетасы нашире Ә.Сәйдәшевкә охшатып ясалган портрет. Янына «Нашир әфәнде» дип язылган. Уң ягында тузган чәчле баш. Кырыена «Музей сторожы» диелгән. Сул ягында хатын-кыз башы. Кырыена «Мәрьям илә җырлый» дип куелган.

Рәсем һәм җыр түбәндәге хәлләргә ишарәле. Татар эсерларының Казанда чыккан «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», «Тавыш» газеталары патша хакимияте тарафыннан туктатылганнан соң, сәяси эшчәнлеге өчен бер ай төрмәдә утырган шагыйрь С.Рәмиев, бөтенләй эшсез калып, «Бәянелхак» редакциясенә хезмәткә керә. Ул вакытта инде «Бәянелхак»ның кушымтасы гына булып калган «Казан мөхбире» газетасында С.Рәмиев бер төркем яшьләр белән, «Уен-көлке музее» һәм «Без» исемле көлке сәхифәләре оештырып, «Музей сторожы», «Музей сторожы Тимербулат» һ.б. псевдонимнар астында «Яшен» һәм яшенчеләргә, «Әлислах» һәм ислахчыларга каршы юнәлдерелгән мәкалә-фельетоннарын, шигырьләрен бастыра.

Тукайга С.Рәмиевнең әлеге гамәлләре бер дә ошамый. Ул аны кайда гына күрсә дә, әлеге шигырьне җырлап, хурлый торган була.

[1]*Сторожлыкка ялландык Чәйдәш абзыкайларга.* – 1906–1914 елларда Казанда нәшер ителгән «Бәянелхак» газетасын чыгаручы нашир-мөхәррир Әхмәтҗан Сәйдәшев турында әйтелә.

[2+]*Проститутка Мәрьям белән парлап торып җырлыйбыз.* – Шагыйрь С.Рәмиев яхшы җырчы да була. Аның граммофон пластинкасына берничә татар көен яздырганлыгы билгеле. Мәкәрҗәдәге зур рестораннарда Мәрьям Искәндәрова белән бер-ике дуэт та җырлаганнар. Шигырьнең соңгы ике юлы шуңа ишарә булса кирәк.

29 бит.

*** **(«Бунларның берсе – үз анасы...»).** «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче (29 апрель) саны тышлыгының беренче битендә рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Рәсемдә: итәгенә «Австрия» дип язылган гаскәри. Аның кулында бала, анысына «Босния» дип язылган. «Босния»нең уң аягыннан – «Төркия», сул кулыннан «Сербия» тарта. Аска әлеге икеюллык урнаштырылган. Беренче тапкыр Н.Исәнбәт «Казан утлары» журналының 1966 елгы 4 нче санында бастырып чыгарды.

Текст «Яшен»нән алынды.

31 бит.

**Күрсәтә.** «Әлислах»ның 1909 елгы 30 апрель (67 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренмәде. (Шигырьнең ахыры чыкмый калуга «Әлислах»ның моннан соң бер генә саны һәм аның өч айга якын соңлап дөнья күрүе дә сәбәп булырга мөмкин.) Шигырь «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст шуннан алынды.

32 бит.

**Габделхәмид.** «Яшен»нең 1909 елгы 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында, «Шүрәле» имзасы белән басылган бәйләмгә кергән. «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Шигырьнең ахыргы юлындагы «Гөмберррт!» сүзе дә, имза сыман итеп, аска төшереп куелган. Псевдоним итеп «Гөмберррт!»не (өч «р» хәрефе белән) Тукай беренче тапкыр «Яшен»дә «Тотса мәскәүләр якаң» дигән сатирик шигыре астына куя.

Габделхәмид (1842–1918) – Төркиядә утыз елдан артык солтан булып утырган кеше. 1907–1908 елларда көчәйгән яшь төрекләр хәрәкәте нәтиҗәсендә Габделхәмид илдә конституция кабул итәргә мәҗбүр була. 1909 елда, конституцияне юкка чыгарырга һәм үзидарәне яңадан кайтарырга тырышуы сәбәпле, ул тәхеттән төшерелә.

[1]*Мин хәфәрә биэрән литәбгатиһи вәкага фиһи* – берәү үз халкына кое казыса, үзе үк (шул коега) төшә.

33 бит.

**Муллалар («Йөриләр бу кешеләр...»).** «Яшен»нең 1909 елгы 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган. Тукайның үзе исән чагында дөнья күргән җыентыкларына кертелмәгән.

Текст «Яшен»нән алынды.

[1]*«Әгузе»* – Коръәндә сүрәләр «Бисмиллаһир-рахманир-рахим; әгузе биллаһи минәш-шәйтан ир-раҗим» (Мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһы исеме белән; ташлар атып куылган шәйтаннан Аллаһыга сыенам) дип башлана. Мөселман кешесе һәр эшне шушы сүзләр белән башларга тиеш.

34 бит.

**Вөҗдан зарары.** «Яшен»нең 1909 елгы 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган. «“Будильник”тән» дип куелган.

Текст «Әдәбият»тан (1909) алынды.

[1]*«Будильник»* – 1865–1871 елларда – Петербургта, 1878–1917 елларда Мәскәүдә чыккан атналык сатирик журнал.

35 бит.

**Ике юл.** «Яшен»нең 1909 елгы 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган. «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Икенче юлдагы *«гыйлем»* сүзе «Яшен»дә *«белү»* дип бирелгән.

Текст «Әдәбият»тан (1909) алынды.

36 бит.

*** **(«Ничек тормак тиеш, дустым? дисеңме...»).** «Яшен»нең 1909 ел 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк.

Текст «Яшен»нән алынды.

37 бит.

**Гаилә тынычлыгы.** «Яшен»нең 1909 елгы 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган, аннары «Яшен ташлары»на (2) кертелгән.

Соңгы юлдагы *«...булсын һәм хатын телсез»* дигән сүзләр «Яшен»дә *«...булсын хатыны телсез»* дип бирелгән.

Текст «Яшен ташлары»ннан (2) алынды.

38 бит.

**Киңәш («Ялангач калдыйсаң...»).** «Яшен»нең 1909 елгы 9 нчы (21 май) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк.

Текст «Яшен»нән алынды.

[1]*Мыраулый башла бик ямьсез, алып үрнәк Бәширидән.* – 1909 елда «Чүкеч» журналында сәркәтип булып эшләүче шагыйрь, язучы Зариф Бәшири (1888–1962) бу журнал битләрендә Тукай шәхесенә тигән, аның иҗатын кимсеткән язмаларын бастырган. Әлеге шигырь юллары аңа ишарә.

39 бит.

**Ике кояш.** «Мәдхия» исеме белән бу шигырь беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томында (1930) басылган.

Шигырь беренче татар профессиональ актрисасы, режиссер, «Нур» труппасын оештыручы, ТАССРның атказанган артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның (1885–1974) Татарстан Республикасы Милли архивында саклана торган альбомына кертелгән. Тукайның үз кулы белән язылган әлеге кульязмасында шигырь «Ике кояш» дип атала, язылу датасы 19–$^{26}$v 09 дип күрсәтелгән.

Текст альбомнан алынды.

40 бит.

**Эштән чыгарылган татар кызына.** «Яшен»нең 1909 елгы 10 нчы (24 июнь) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган, аннары «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

Казанның зур йорт хуҗаларыннан һәм зур сәүдәгәрләреннән булган Гыйльметдин Хаҗи Ибраһимов үз өендәге яшь бер асрау кызны көчли, шуннан соң аны куып чыгара. Тукай, бу вакыйганы ишетеп, үзенең яраткан «Зиләйлүк» көенә салып, әлеге шигырен яза.

«Яшен»дә «Зиләйлүк» көенә дип язылган, исем асты бирелмәгән.

К.Бәкер үзенең бәяләмәсендә бу шигырьне «Тукаевның иң муаффәкыятьле вә тәкъдир ителергә тиешле булган» әсәрләр рәтендә саный... Аныңча, «Без бу шигырьләрне укып, бөтен татар дөньясындагы укучылар белән хиссиятләремезне уртаклаша аламыз».

41 бит.

**Бәгъзе зыялыларымыз.** «Яшен»нең 1909 елгы 10 нчы (24 июнь) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

42 бит.

**Гомер хакында.** «Яшен»нең 1909 елгы 10 нчы (24 июнь) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларына кертелмәгән.

Текст «Яшен»нән алынды.

43 бит.

**Ачы хәкыйкать.** «Яшен»нең 1909 елгы 10 нчы (24 июнь) санында «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Татар бае» исеме белән басылган. Исем астына «“Бакырган”нан» диелгән. «Яшен ташлары» җыентыгында шигырьнең исеме «Ачы хакыйкать» дип бирелгән. Текст шуннан алынды.

«Яшен ташлары» «Теркәү дәфтәре» буенча 1911 елның 1 августында басылып чыга. Ул авторның «Бер лыгырдау» исемле кереш сүзе белән ачыла. Биредә әлеге җыентыкны дөньяга чыгаруның тарихы һәм ни өчен шушы исем белән атавы бәян ителә: «Мәйдандадыр ки олуг мөхәррирләремездән Фатыйх Кәримов, иң элек аннан-моннан җыеп, «Аннан-моннан» атлы мәҗмугa чыгарды.

Аннан соң Гаяз әл-Исхакый җәнабләре дә, үзләренең төрле урыннарда чәчелеп яткан язуларын бер җиргә җыеп, «Җыентык» исемендә җыйнак кына бер китап таратты.

Болардан соң Фатыйх әфәнде Әмирхан җәнабләре, үзенең вак-төяк тәхриратеннән җыеп, «Вак-төяк» исемле әсәр бастырды.

Бәс, боларны күргәч, минем дә төрле урында чәчелеп яткан «чүп-чарым» исемә төште. Мәзкүр өч мөхәррир кеби, минем дә шул чүп-чарны бер почмакка себереп өясем килде.

Китабымның исемен үземә махсус бер фикер белән «Башыңдагы чабата» дип куймакчы булган идем дә, «Матбугат клоуны» диярләр дип шүрләдем.

Шул сәбәпле инде туктаган «Яшен» журналы хатирәсе өчен җыйган чүп-чарымны «Яшен ташлары» дип атарга карар бирдем. Шүрәле».

[1]*«Бакырган»нан.* – «Бакырган» китабы – татарларда кульязма килеш борыннан укылып килгән мәшһүр китап. Анда XII–XVIII гасыр төрек-татар поэзиясе әсәрләре тупланган. Җыентыкның күбрәк өлешен XII гасырда Урта Азиядә яшәгән Сөләйман Бакыргани дигән суфи шагыйрь (вафаты 1186 елда) шигырьләре алып тора. Шуңа да китап «Бакырган китабы» дип аталган. Тукай бу әсәрен андагы:

Адәм угълы үлгүче,
Кара җиргә кергүче;
Кем яхшыдыр, кем яман –
Шунда мәгълүм булгучы, –

дип башланган шигырьнең формасын, ритмын файдаланып язган.

45 бит.

**Төрекчәдән («Сөйгәненеңне мин кочам, дип...»).** «Әлислах»ның 1909 елгы 21 июль (68 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Икенче юлдагы «җанаш» сүзе «Әлислах»та «җанкәй» дип бирелгән.

Текст «Әдәбият»тан алынды.

46 бит.

**Гашыйк.** «Әлислах»ның 1909 елгы 21 июль (68 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. 11 нче юлдагы *«җанаш»* сүзе «Әлислах»та *«җанкәй»* дип бирелгән.

К.Бәкер үзенең бәяләмәсендә бу шигырьне «Тукаевның иң муаффәкыятьле вә тәкъдир ителергә тиешле булган» әсәрләр рәтендә саный... Анынча, «Без бу шигырьләрне укып, бөтен татар дөньясындагы укучылар белән хиссиятләремезне уртаклаша аламыз».

Текст «Әдәбият»тан алынды.

[1]*Хәзрәти Муса тәхәммелсез тәҗәлли нурына.* – Коръәндә язылганча, Синайдагы Тур тавы башына Аллаһы Тәгалә белән күрешергә килгән Муса пәйгамбәр Тәңредән бер генә мәлгә йөзен күрсәтүен үтенә. «Күзең чагылып сукыраерсың», – дип кисәтә Аллаһы Тәгалә тавышы; ләкин, бик үтенгәч, кыска бер мизгелгә йөзен ачса, Муса пәйгамбәр Аллаһы Тәгалә нурына чыдамый, һушы китеп егыла.

47 бит.

**Вакъты гаҗезем.** «Әлислах»ның 1909 елгы 21 июль (68 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Соңгы строфадагы *«бу золмәтләр»* сүзе «Әлислах»та *«саташмаклар»* дип бирелгән.

Текст «Әдәбият»тан алынды.

48 бит.

**Шекспирдән («Күрәм кайчакта...»).** «Әлислах»ның 1909 елгы 21 июль (68 нче) санында «Шекспирдән бер мәфһүм» исеме һәм «Гъ.Т. 26 июнь, 1909 сәнә» датасы белән басылган, «Әдәбият»ка (1909) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

49 бит.

**Китап.** «Йолдыз»ның 1909 елгы 3 октябрь (453 нче) санында басылган. «22 сентябрь, 1909 сәнә» дигән дата куелган. Г.Тукайның «Балалар күңеле» китабына кертелгән. Текст шуннан алынды.

Китапка «Сабах» ширкәте идарәсеннән «Бер-ике сүз» исеме белән түбәндәге кереш бирелгән: «Мөгаллимләремез мәктәптә балаларга укытыр өчен язылган шигырьләргә бик мохтаҗ икәнлекләрен күреп, без, шул ихтыяҗны бетерүдә беренче адым уларак, Габдулла әфәнде Тукаевның шушы мәҗмугасын мәйданга куябыз.

Тукаевның моңарча басылган мәҗмугаларында да балаларга муафикъ шигырьләр булгаласа да, муафикъ булмаганы күбрәктер.

Шунлыктан балаларның фәкать үзләренә махсус бер мәҗмуга ясау кирәк булды.

Моңарча мөгаллимләремезнең аңлыраклары балалар рухына килешерлек шигырьләр бер дә булмаганга, балаларга бер шигырь дә укытмыйлар вә бикләтмиләр дә иде.

Әмма бәгъзеләре исә, «Беренче сада», «Икенче сада» яисә, Мәҗит Гафуриның «Милли шигырьләр» дигән бер әйбере кеби, балалар белән һич мөнәсәбәте булмаган шигырьләр белән балаларны саташтыралар иде.

Бу мәҗмуга русларның иң могътәбәр шагыйрьләреннән Плещеев, Майков, Позняков, Федоровларга Габдулла әфәнденең кәмаль муаффәкыять илә икътибас вә тәкълид иткән шигырьләреннән гыйбарәт.

Әгәр бу мәҗмугамызга мәгълүм әфәнделәр тарафыннан илтифат әсәре күрелсә, без киләчәктә дә мәҗмугаларны бер-бер артлы мәйданга чыгара торырмыз».

Җыентык «Теркәү дәфтәре» буенча 23 ноябрьдә дөньяга чыга. «Вакыт» газетасы үзенең 1 декабрь санында: «Балалар бәхетенә зур бер адым. Шагыйрь Габдулла Тукайның «Балалар күңеле» намендәге әсәреннән 1 нче җөзьэ басылып чыкты», – дип хәбәр бирә.

1910 елның 10 гыйнварында «Йолдыз» газетасының «Яңа әсәрләр» бүлегендә Кәбир Бәкернең әлеге җыентыкка бәяләмәсе дә дөнья күрә: «Бездә, мәктәпләрдә, чын татар телен өйрәтә вә шуның белән бергә гали хиссиятләр тудыра торган бер кыйраәт китабы юк иде, – дип яза автор. – Менә алдымда беренче шагыйрьләремездән Тукаев җәнабләренең «Балалар күңеле» исемле шигырьләр мәҗмугасы. Бу мәҗмуганың башыннан алып ахырына кадәр бар шигырьләре дә балалар өчен язылган вә азмы-күпме кирәкле хиссиятләр тудыра торган, балалар күңеленә азык бирә торган шигырьләрдер. Хосусан «Туган тел» балалар рухына бик якын һәм бик муаффәкыятьле бер рәвештә язылган.

Моңарчы булган уку китапларында көйле әсәрләр зур урын ала. Балалар хәтта бик тәэсирле мәкаләләрне дә «Фазаилеш шөһүр» китабы көенә салып укыйлар һәм бөтен бирә торган тәэсирен җуялар иде. Бу китапка кертелгән шигырьләр исә көйгә килми, чөнки тәэсирле уку үзенә күрә бик зур бер кәмаләт санала торган нәрсә. Шуның өчен мәктәп балаларын тәэсирле укырга да өйрәтергә кирәк. Бу китап исә шуңа хезмәт итәчәк».

«Шура» журналының 1910 елның 3 нче санында да «Балалар күңеле» җыентыгына кыскача тәкъриз басыла: «Балалар күңеле. Ибтидаи мәктәп балалары укыр өчен мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев тарафыннан язылып, «Сабах» хәраҗәте илә басылмыштыр. 90 бит».

Тукай «Китап» шигырен рус балалар шагыйре Н.И.Позняковның (1857–1910) «Книга» дигән шигыреннән иҗади файдаланып язган.

Ул оригиналның кайбер строфаларын, чагылган фактларның татар халкы тормышына яки үз иҗади рухына туры килмәве аркасында, төшереп калдырган.

50 бит.

**Мөкаддимә.** Әсәр Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә саклана (9 ф., 1 тасв., 1 эш). Ул «Мәктәп шигырьләре. Г.Тукаев» дип исемләнгән, исем астына «1909 сәнә, 12 үктәбер» диелгән, Тукайның үз кулы белән язылган сигез битле кульязма дәфтәргә кертелгән. «Мөкаддимә» шигыре дәфтәрнең беренче битенә үк урнаштырылган. Аны беренче тапкыр С.Исәнбаев «Казан утлары» журналының 1966 елгы 4 нче санында бастырып чыгарды. Аннары ул, архивтан алынып, Тукайның икенче Дүрттомлыгының 2 нче томына (1976) кертелде.

Текст Тукайның кульязма дәфтәреннән алынды.

51 бит.

**Сөбханалла, сөбханалла.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

К.Бәкер үзенең бәяләмәсендә бу шигырьне «Тукаевның иң муаффәкыятьле вә тәкъдир ителергә тиешле булган» әсәрләр рәтендә саный... Аныңча, «Без бу шигырьләрне укып, бөтен татар дөньясындагы укучылар белән хиссиятләремезне уртаклаша аламыз».

52 бит.

**Эш.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*...тынарсың җомга көн.* – Мөселманнарда атнаның алтынчы (җыелып намаз укый торган) көне – җомга (ял көне).

53 бит.

**Әнә-менә.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*...мантыйк тутырган.* – Иске мәдрәсәләрдә укытылган формаль-схоластик логика.

[2]*«Тәхрире мәрьәт» тәрҗемәсе.* – Сүз гарәпчәдән татар теленә тәрҗемә ителгән китап турында бара.

Китапның авторы – алдынгы фикерле гарәп (Мисыр) язучысы (чыгышы белән көрд) Касыйм Әмин (1865–1909). 1899 елда басылган «Тәхрире мәрьәт»ендә ул хатын-кызга ирләр белән тигез хокуклар бирү мәсьәләсен бөтен гарәп дөньясында беренче мәртәбә күтәреп чыга. Китап, тиз арада таралып, барлык мөселман илләрендә кайнар бәхәсләр уята. «Тәхрире мәрьәт» 1912 елда И.Ю.Крачковский (1883–1951) тәрҗемәсендә русча да басыла.

Китапның зур әһәмиятен күздә тотып, Ф.Әмирхан, Г.Тукай аның татарчага тәрҗемәсенә игътибар итәләр. Тәрҗемәчесе – журналист, җәмәгать эшлеклесе, Закир әл-Кадыйри (1878–1954). Әмирхан китапны гарәп сүзләре күп катнашкан корама булуы, «җөмләләр тәшкиленең авырлыгы» өчен тәнкыйтьли, мулла белән шәкерт кенә аңлый алырлык, ди. Тукай исә аны «чеп-чи бәрәңге кәлҗемәсе»нә охшата.

54 бит.

**Могъҗиза.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*Ярылмас ай икегә...* – дини риваять буенча җирдәге могъҗизаларына ышанмыйча, сихерче дип атап, Мөхәммәд пәйгамбәрдән күктә могъҗиза күрсәтүен, мәсәлән, кодрәте белән айны икегә ярып, ике кисәген ике якка җибәрүен, аннары аларны ике җиң очыннан чыгарып, үзенә сәҗдә иттерүен сорыйлар. Мөхәммәд моны үтәп чыга, имеш. Бу риваять дини эчтәлекле китапларда да чагылыш тапкан. Мәсәлән, Таҗетдин Ялчыголның (1768–1838) «Рисаләи Газизә»се. Шәрхе «Сөбәтел-гаҗизин» дигән китабында:

Мәдәд кыйлса Ходай галәм арай,
Хәбиб итсә ишарәт, айрылыр ай, –

дигән икеюллык бар. Тукай менә шуларга ишарәли.

[2]*...кара таштан төя тугъмас.* – Дини риваять буенча сәмүд халкын хак дингә өндәргә килгән Салих пәйгамбәрдән үзенең Аллаһы Тәгалә вәкиле икәненә ышандыру өчен могъҗиза күрсәтүен сорыйлар: «Менә шул кара таштан дөя чыгар», – диләр. Салих таягы белән сугуга, бик шәп бер ана дөя пәйда була. Аңа карап сәмүдләр барыбер күктәге Аллаһы Тәгаләгә иман китермиләр, пәйгамбәр китү белән, дөяне суеп ашыйлар. Югарыдагы сүзләре белән Тукай Коръәндәге шушы риваятькә ишарәли.

55 бит.

**Туган авыл.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*...мин шунда туган...* – бу шигырь Тукайның туган авылына (хәзерге Арча районы Кушлавыч авылы) багышлап язылган. Чыннан да, авыл калку урынга салынган, ерак түгел чишмәсе дә бар.

[2]*...рәсүлемез Мөхәммәдне.* – Ислам диненә нигез салучы Мөхәммәд пәйгамбәр (570 ел тирәсендә туган – 632 елда үлгән).

56 бит.

**Чыршы.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

57 бит.

**Яңгыр илә Кояш.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

59 бит.

**Милли моңнар.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Соңыннан Тукай бу шигырен «Халык әдәбияты» исемле китабында (1910) халык иҗатына ияреп язылган «Сонгый җырлар» (шигырьләр) рәтенә кертә. «Әдәбият»та 9 нчы юлда *«чиккән»* сүзе *«күргән»* дип, 11 нче юлдагы *«белән»* сүзе *«берлә»* дип бирелгән.

Текст «Халык әдәбияты»ннан алынды.

Шигырьнең язылу тарихы турында М.Гали болай дип яза: «Көннәрнең берсендә Тукай, «Болгар» номерларында үз бүлмәсендә утырганда, бик матур бер җыр тавышы ишетә. Үзенең халык җырларына һәм халык көйләренә булган зур мәхәббәте аркасында ул чыдый алмый, коридорга чыга. Җыр тавышы тагын да якынрак һәм тагын да ачыграк ишетелә. Ирексез, ул шул тавыш килгән якка китә. Ул вакытта бик сирәк җырланган көй булганлыктан, Тукай бу көйнең нинди көй булганлыгын да тиз генә аңлап җитә алмый. Ишеге ярык кына калдырып ачылган бер бүлмәгә килеп туктый һәм, аның ишек яңагына башын куеп, тирән уйларга калып, бүлмә эченнән килә торган җыр тавышын тыңларга керешә. Ул бүлмә Сәгыйть Рәмиев бүлмәсе булып чыга һәм кроватьта ятып моңлы калын тавыш белән «Әллүки» көенә җырлаучы кеше дә Тукайның иң яраткан җырчысы – шагыйрь Сәгыйть Рәмиев була. Башка вакытта Сәгыйть белән күбрәк шаярып сөйләшергә яраткан Тукай бик җитди кыяфәт белән аның бүлмәсенә керә дә:

– Әйт, туган, нинди көй җырлыйсың син? Синең бу җырың минем аяк буыннарыма китте, – ди.

Сәгыйть, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:
– Нигә, белмисеңмени, «Әллүки» ич, – ди.
Шуннан соң Тукай үзенең «Милли моңнар» шигырен язып, аны Сәгыйтьтән «Әллүки» көенә җырлата һәм үзе дә аны шул көйгә яки «Зиләйлүк» көенә салып җырлап йөри».
Кәбир Бәкер «Йолдыз» газетасының «Яңа әсәрләр» бүлегенә урнаштырылган бәяләмәсендә бу шигырьне «Тукаевның иң муаффәкыятьле вә тәкъдир ителергә тиешле булган» әсәрләр рәтендә саный... Аныңча, «Без бу шигырьләрне укып, бөтен татар дөньясындагы укучылар белән хиссиятләремезне уртаклаша аламыз».

60 бит.
**Яратырга ярый.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

61 бит.
**Япун хикәясе.** «Әдәбият»та (1909) басылган. Текст шуннан алынды.
Әсәр рус язучысы В.П.Буренинның (1841–1926) «Японская сказка» исемле көйле хикәясеннән тәрҗемә. Тукай хикәянең төп өлешенә зур үзгәреш кертми, тик Буренин хикәясендәге «император» сүзен «хан» дип алмаштыра һәм, үзеннән кайбер детальләр өстәп, хикәяне тулыландыра.
Р.И.Нәфыйков бу поэманың сюжетын Тукай В.П.Буренинннан түгел, ә «Уралец» газетасының 1903 елгы 13 декабрь санында басылган «Японский каменщик» дигән әкияттән алган булырга мөмкин дип әйтә.

65 бит.
**Күңел йолдызы.** «Йолдыз»ның 1909 елгы 29 ноябрь (472 нче) санында басылган, «Күңел җимешләре»нә (1911) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.
«Йолдыз»да әсәргә түбәндәге искәрмә бирелгән: «Күптән инде Габдулла Җәүдәтнең шул ике сәтыры күңелемә ошагач, мин дә бер нәрсә язган идем. «Йолдыз»га мөнәсәбәте булганга, шунда дәрҗ иттем».

[1]*Тәнәфферләр, тәхаттырлар, тәрәххемләрлә дөньядан*
*Гөзарым, захмедар васле бер һиҗрә мөкәүкәбдер.* – Нәфрәтләнү, хәтерләүләр, ачынулар (кызганулар) белән дөньядан үтәчәк юлым яралы (күңел) кавышу һәм аерылулар белән йолдызланган (нурланган).
[2]*Габдулла Җәүдәт* (1869–1932) – төрек шагыйре, журналисты. Эпиграф итеп китерелгән икеюллыгы «Бер кыйтга» исемле шигыреннән.

66 бит.
**Киңәш («Чикмә гамь...»).** «Йолдыз»ның 1909 елгы 29 ноябрь (472 нче) санында басылган. «Йолдыз»да шигырь ике кисәктән тора: беренчесе – *«Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен...»* дип, икенчесе *«Чикмә гамь шул нәрсәгә...»* дип башлана. Аска «27 ноябрь, 1909 сәнә» дип куелган. «Күңел җимешләре»ндә (1911) шигырьнең беренче алты юлы *«Киңәш»* исеме белән, калган өлеше *«Сәрләүхәсез»* исеме белән аерым-аерым бирелгән.
Тукайның әлеге шигыре Н.И.Позняковның «Не жалей о днях минувших» шигыре тәэсирендә язылган. Әмма оригиналдан ераклашу сәбәпле, үз әсәре булып үсеп киткән.
Текст «Күңел җимешләре»ннән алынды.

67 бит.
**Сәрләүхәсез.** «Йолдыз»ның 1909 елгы 29 ноябрь (472 нче) санында басылган (югарыдагы «Киңәш («Чикмә гамь шул нәрсәгә...»)» шигыре искәрмәсен карагыз).
Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.
«Күңел җимешләре» китабы наширләре фикеренчә, «аның «Ачы хәсрәт» көйләре, «Сәрләүхәсез», «Теләү бетте», «Өмид»ләре рухның иң эчке катында киләләр дә укучыны да үзләре галәменә тарталар. Болар инде каләмне күз яшенә манчып язылганнар».
Әсәр Н.И.Позняковның «Если в сердце человека...» дип башланган шигыреннән өлешчә файдаланып язылган.
Позняковның:

Если в сердце человека
Хочешь струн коснуться всех,
Тон настраивай на горе,
А не на веселый смех.
Много тех, что не встречали
Света на пути зеленом,
А такого нет, чтоб мрака
В сердце не таил больном, –

дигән юлларны эченә алган, төшенкелек хисләре белән сугарылган, субъектив тойгыларны гына чагылдырган шигыренә Тукай ике строфа өстәп, яңа фикер бирә:
Әмма дөнья нинди кызык, нинди хозур,
Бу дөньяда кемнәр бар, дип, миннән дә зур.

68 бит.
**Теләү бетте.** «Йолдыз»ның 1909 елгы 20 декабрь (481 нче) санында басылган. «17 декабрь, 1909 сәнә» дип куелган.
Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.
Әсәр А.С.Пушкинның «Я пережил свои желанья...» (1821) дип башланган шигырен иҗади файдаланып язылган. Пушкин шигыре:

Я пережил свои желанья,
Я разлюбил свои мечты;

Остались мне одни страданья,
Плоды сердечной пустоты.

Под бурями судьбы жестокой
Увял цветущий мой венец –
Живу печальный, одинокий,
И жду: придет ли мой конец?

Так, поздним хладом пораженный,
Так бури слышен зимний свист,
Один – на ветке обнаженной
Трепещет запоздалый лист!..

Тукай, рус классикларының гадилек, кыскалык алымнары кулланып язган шигырьләрен тәрҗемә иткәндә һәм файдаланып язганда, фикерне татар укучысына аңлаешлы итеп ачарга омтылган, татар халык телендәге канатлы сүзләр, фразеологик әйтемнәр, мәкальләр кулланган.

69 бит.

**Туган тел.** «Балалар күңеле»нең 1 нче (1909) һәм 2 нче (1911) басмаларында басылган.

Фатих Сәйфи-Казанлы тарафыннан төзелгән Өчтомлыкның 2 нче томында (1930) әлеге шигырьнең кульязмасы турында түбәндәге аңлатма бирелә: «Татар мәдәният йорты янындагы китап палатасында Г.Тукайның ике кульязмасы саклана. Бу кульязмада Тукай үзенең шигырьләренең тарихын күрсәтеп барган. Киләчәк искәрмәләрдә «кульязма» дип әйтелсә, шунда саклана торган кульязма дип белергә кирәк».

Хәзерге вакытта бу кульязмаларның язмышы билгесез. Алга таба шигырьләрнең язылу тарихына караган әлеге мәгълүматлар «Кульязма» дип биреләчәк.

Шигырьнең 6 нчы юлы «Балалар күңеле»нең (1909) 1 нче басмасында *«Кечкенәдән тышка чыккан шатлыгым, кайгым минем»* дип, кульязмада һәм «Балалар күңеле»нең (1911) 2 нче басмасында *«Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым белән»* дип бирелгән.

Текст 2 нче басмадан алынды.

«Балалар күңеле» исемле җыентыгына бирелгән бәяләмәсендә Кәбир Бәкер Тукайның әлеге шигыре турында: «“Туган тел” балалар рухына бик якын һәм бик муаффәкыятьле бер рәвештә язылган», – дип искәртә.

71 бит.

**Ана догасы.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган.

Шигырьнең 11 нче юлы кульязмада: *«Агадыр чишмә төсле мескиннең күзләреннән яшь»,* – дип бирелгән. Язылу датасы «1909, үктәбер 19» итеп куелган.

Текст «Балалар күңеле»ннән (1909) алынды.

72 бит.

**Таян Аллага.** Беренче тапкыр «Яңа кыйраәт»тә (1909) басылган, 2 нче басмасына (1910) һәм «Балалар күңеле»нә (1909, 1911) «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә» исеме белән кертелгән. Кульязмада да «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә» дип исемләнеп, язылу датасы «1909, ноябрь» дип куелган. Икетомлыкның 1 нче томына (1943) «Таян Аллага» исеме белән урнаштырылган.

Текст «Балалар күңеле»ннән (1911) алынды, исеме Икетомлыктан (1943) алып куелды.

Шигырь И.С.Никитинның «Молитва дитя» шигыренә бик охшаш. Ул шигырь түбәндәгечә:

Молись, дитя: сомненья камень
Твоей груди не тяготит;
Твоей молитвы чистый пламень
Святой любовию горит.

Молись, дитя: тебе внимает
Творец бесчисленных миров,
И капли слез твоих считает,
И отвечать тебе готов.

Быть может, ангел, твой хранитель,
Все эти слезы соберет.
И их в надзвездную обитель
К престолу Бога отнесет.

Молись, дитя, мужай с летами!
И дай Бог в пору поздних лет
Такими ж светлыми очами
Тебе глядеть на Божий свет!

Но если жизнь тебя измучит,
И ум, и сердце возмутит,
Но если жизнь роптать научит,
Любовь и веру погасит –

Приникни с жаркими слезами,
Креста подножье обойми:

Ты примиришься с небесами,
С самим собою и с людьми.

И вновь тогда из райской сени
Хранитель – ангел твой сойдет
И за тебя, склонив колени,
Молитву к Богу вознесет.

*1853*

73 бит.

**Бабай.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь Өчтомлыкның 2 нче томында (1930) И.С.Никитинның «Дедушка» (1857) исемле шигыреннән, беренче Дүрттомлыкта (1955) исә, Н.А.Некрасовның «Дедушка» исемле шигыреннән файдаланып язылган, диелә. Икесендә дә бабай образы бар. Әмма аларның сурәтләнешендә охшашлык юк диярлек.

Н.А.Некрасов шигыреннән өзек түбәндәгечә:

Дедушка древен годами,
Но еще бодр и красив,
Зубы у него целы,
Поступь, осанка тверда,
Кудри пушисты и белы,
Как серебро – борода.

И.С.Никитин шигыре болай башлана:

Лысый с белою бородою
Дедушка сидит.
Чашка с хлебом и водою
Перед ним стоит.
Бел как лунь,
На лбу морщины...

74 бит.

**Уянмас йокы.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Кулъязмада язылу вакыты «1909, үктәбер 28» дип бирелгән.

Текст «Балалар күңеле»ннән алынды.

75 бит.

**Ай һәм Кояш.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Кулъязмада язылу вакыты «1909, үктәбер 15» дип куелган.

Текст «Балалар күңеле»ннән алынды.

76 бит.

**Җир йокысы.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Кулъязмада язылу вакыты «1909, үктәбер» дип бирелгән.

Текст «Балалар күңеле»ннән алынды.

Тукай бу шигырен И.З.Суриковның «Зима» исемле шигыренең бер өлешеннән иҗади файдаланып язган. Үзе бер урында да күрсәтми.

И.З.Суриков шигыре түбәндәгечә:

Белый снег, пушистый,
В воздухе кружится
И на землю тихо
Падает, ложится.
И под утро снегом
Поле забелело,
Точно пеленою
Все его одело.
Темный лес что шапкой
Припокрылся чудной
И заснул под нею
Крепко, непробудно...
Божьи дни коротки,
Солнце светит мало, –
Вот пришли морозцы
И зима настала.
Труженик-крестьянин
Вытащил санишки,
Снеговые горы
Строят ребятишки.
Уж давно крестьянин
Ждал зимы и стужи,
И избу соломой
Он укрыл снаружи,
Чтоб в избу ветер
Не проник сквозь щели,
Не надули б снега

Вьюги и метели.
Он теперь покоен –
Все кругом укрыто,
И ему не страшен
Злой мороз, сердитый.

77 бит.

**Кышка бер сүз.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Кулъязмада бу шигырь «Кыш белән бәхилләшү» дип исемләнгән, ә язылу вакыты «1909» дип куелган.

Текст «Балалар күңеле»ннән алынды.

Шигырь А.Н.Майковның «Весна» исемле шигыреннән өлешчә файдаланып язылган. Шигырьнең тексты түбәндәгечә:

Уходи, зима седая,
Уж красавицы весны
Колесница золотая
Мчится с горной вершины!
Старой спорить ли, тщедушной,
С ней – царицею цветов,
С целой армией воздушной
Благовенных ветерков!
А что шума, что гуденья,
Теплых ливней и лучей,
И чиликанья, и пенья!
Уходи себе скорей,
У нее не лук, не стрелы,
Улыбнулась лишь – и ты,
Подобрав свой саван белый,
Поползла в овраг, в кусты!..
Да найдут и по оврагам!
Вон – уж пчел рои шумят,
И летит победным флагом
Пестрых бабочек отряд!

78 бит.

**Кошларга.** «Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь А.Н.Плещеевның «Напрасно, птички...» исемле шигыреннән иҗади файдаланып язылган. Шигырьнең тексты түбәндәгечә:

Напрасно, птички, вас мое
Присутствие тревожит:
Спокойно пойте все, что Бог
Вам на сердце положит.
Я не поставлю западни
Вам ни в саду, ни в поле,
И сам я знаю хорошо,
Что значит жить на воле.

79 бит.

**Сабыйга**.«Балалар күңеле»ндә (1909) басылган. Кулъязмада язылу вакыты «1909, үктәбер 21» дип куелган, шигырьнең 7 нче юлы «Син әле үс һәм укып шунда аңларсың барын» дип бирелгән.

Текст «Балалар күңеле»ннән алынды.

80 бит.

**Карлыгач.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды.

Кулъязмада язылу датасы «1909, үктәбер 21» дип күрсәтелгән.

Балаларга багышланган бу әсәр рус язучысы И.С.Никитинның (1824–1861) «Гнездо ласточки» шигыреннән файдаланып язылган. Тукай Никитиндагы су тегермәне, андагы исерек тегермәнче турында сөйләгәннәрне төшереп калдыра да фәкать карлыгачның яшәү рәвеше хакында җентекле мәгълүмат бирә.

**Гнездо ласточки**

Кипит вода, ревет ручьем,
На мельнице и стук, и гром,
Колеса-то в воде шумят,
А брызги вверх огнем летят,
От пены-то бугор стоит,
Что мост живой, весь пол дрожит.
Шумит вода, рукав трясет,
На камни рожь дождем течет,
Под жерновом муку родит,
Идет мука, в глаза пылит.
Об мельнике и речи нет.

В пыли, в муке, и лыс, и сед,
Кричит весь день про бедный люд:
Вот тот-то мот, вот тот-то плут...
Сам, старый черт, как зверь глядит,
Чужим добром и пьян, и сыт;
Детей забыл, жену извел;
Барбос с ним жил, барбос ушел...
Одна певунья – ласточка –
Под крышей обжилась,
Свила-слепила гнездышко,
Детьми обзавелась.
Поет, пока не выгнали.
Чужой-то кров – не свой;
Хоть не любо, не весело,
Да свыкнешься с нуждой.
В ночь темную под крылышко
Головку подогнет
И спит себе под гром и стук,
Носком не шевельнет.

*1856*

81 бит.

**Кышкы кич.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Кулъязмада язылу вакыты «1909, үктәбер 21» дип күрсәтелгән.

Әсәр А.Н.Плещеевның (1825–1893) «Зимний вечер» исемле шигыреннән файдаланып язылган. Тукай шигырьнең эчтәлеген татар тормышына якынайта, татар балаларының тормышына хас детальләр кертә, тасвирлавының конкретлылыгы, тәрҗемә ритмикасының тәфсилле, салмак яңгыраш алуы күзгә ташлана.

**Зимний вечер**

Хорошо вам, детки, –
Зимним вечерком
В комнатке уютной
Сели вы рядком,
Пламя от камина
Освещает вас...
Слушаете жадно
Мамы вы рассказ;
Радость, любопытство
На лице у всех;
Часто прерывает
Маму звонкий смех.
Вот рассказ окончен,
Все пустились в зал...
«Поиграй нам, мама», –
Кто-то пропищал.
«Хоть уж девять било,
Отказать вам жаль»...
И послушно села
Мама за рояль.
И пошло веселье,
Началась возня,
Пляска, песни, хохот,
Визг и беготня!
Пусть гудит сердито
Вьюга под окном,
Хорошо вам, детки,
В гнездышке своем!
Но не всем такое
Счастье Бог дает;
Есть на свете много
Бедных и сирот.
У одних могила
Рано мать взяла;
У других нет в зиму
Теплого угла.
Если приведется
Встретить вам таких,
Вы как братьев, детки,
Приголубьте их.

*1872*

82 бит.

**Кошчык.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь рус мәгърифәтчесе К.Д.Ушинский (1824–1870) төзегән «Родное слово» (Для детей младшего возраста. Петербург, 1908. 192 с.) хрестоматиясендәге Ф.А.Туманскийның (1799–1853) «Птичка» дигән әсәренә ияреп язылган. Ләкин Тукай шигырьгә башка мәгънә сала, сабый аңларлык күләмдә ирекнең кадере турында сөйли. Тоткынлык – кысан читлеккә, ирек яшел урман, киң кырларга тиңләштерелә.

**Птичка**

Вчера я растворил темницу
Воздушной пленницы моей:
Я рощам возвратил певицу,
Я возвратил свободу ей.
Она исчезла, утопая
В сиянье голубого дня,
И так запела, улетая,
Как бы молилась за меня.

*1827*

83 бит.

**Бишек җыруы.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Әсәр татар халык авыз иҗаты йогынтысында язылган. Халкыбыз гасырлар дәвамында бишек җырлары иҗат иткән, сабый беренче изге сүзләрне әнисе көйләгән бишек җырларыннан ишеткән. Тукайның «Бишек җыруы» шундый вариантларның берсе булып тора. Кулъязмада «1909, үктәбер 16» датасы куелган.

84 бит.

**Бәхетле бала.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды.

85 бит.

**Бала белән Күбәләк.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Кулъязмада язылу датасы «1909, үктәбер 29» дип куелган. Шигырь К.Д.Ушинскийның «Родное слово» (Год второй, 1908) уку китабында басылган Л.Н.Модзалевскийның (1837–1896) «Мотылек» шигыреннән файдаланып язылган. Тукай, андагы төп фикерне саклаcа да, күбәләк образын үзенчәлекле итеп, «Мотылек»та булмаган рәвештә сорау-җавап формасында ача.

**Мотылек**

Мальчик:

Расскажи, мотылек,
Чем живешь ты, дружок?
Как тебе не устать
День-деньской все порхать?

Мотылек:

Я живу средь лугов,
В блеске летнего дня,
Ароматы цветов –
Вот вся пища моя.
Но короток мой век –
Он не долее дня:
Будь же добр, человек,
И не трогай меня!

*1864*

86 бит.

**Мәктәптә.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Кулъязмада «1909, үктәбер 25» дип искәрмә бирелә.

87 бит.

**Эш беткәч уйнарга ярый.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Шигырь К.Д.Ушинскийның «Родное слово» (Для детей младшего возраста. Год второй) исемле хрестоматиясендәге А.Н.Майковның «Кончил дело – гуляй смело» хикәясеннән файдаланып язылган. Тукай прозаны артык детальләрдән арындыра, җыйнакландыра һәм шигырьгә әйләндерә. Кулъязмада язылу датасы «1909, үктәбер 23–24» дип күрсәтелә.

89 бит.

**Арба, Чана, Ат.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Тик 1985 елгы басмада шигырьнең өстән 6 нчы строфасындагы *«катышып»* сүзе *«кушылып»* дигән сүз белән алыштырылган. Язылу датасы кулъязмада «1909» диелгән.

90 бит.

**Кярханәдә.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. «Теркәү дәфтәре»ндә «Балалар күңеле» (1 нче җөзьэ) китабының дөньяга чыгу вакыты «1909 ел, 23 ноябрь» диелгән. Китапның тышлыгында исә «1910» датасы тора. Шагыйрь 1909 елның җәендә Гурьевкада фабрикант Хәсән Акчуриннарда 5 көн кунакта була, анда вакытта

фабрика-заводларга кереп йөрүе турында истәлекләр бар. Шигырьнең шуннан алган тәэсирләр йогынтысында язылуы мөмкин. Шигырь 1909 елның 31 октябрендә язылган.

91 бит.

**Кәҗә белән Сарык хикәясе.** «Балалар күңеле»ндә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. 1909 елның 10 ноябрендә язылган бу әсәр шагыйрьнең «Шүрәле», «Су анасы» кебек әкият-балладалары төркемен дәвам итә.

**1910**

94 бит.

**Татар мөхәрриренә.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 3 гыйнвар (486 нчы) санында басылган. «Г.Тукай. 1910 сәнә, беренче гыйнвар» дип куелган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

[1] *Гашир* – гошер алучы; шәригать буенча һәр мөселман барлык табышының уннан бер өлешен (гошер) фәкыйрьләр, зәгыйфьләр файдасына – җәмәгать фондына бирергә тиеш. Әмма гамәлдә кайбер мөлкәтле кешеләр тарафыннан бу җиренә җиткереп үтәлмәгән, гошер сәдакасының бирелгән кадәресе белән гадәттә намуссызрак мулла-мунтагай туенган. Тормышындагы шәхси һәм иҗтимагый-социаль сәбәпләр аркасында күңеле төшкән моментта язылган шигыре белән Тукай Яңа елның (1910) беренче көнен газаплы уйланулар белән каршы ала.

95 бит.

**Нәсыйхәт.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 7 гыйнвар (488 нче) санында «Г.Тукай» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

[1]*Хозыр Ильяс* – дини мифологиядә дөнья беткәнче үлмичә яши торган, яхшылыкка – яхшылык, яманлыкка яманлык белән әҗер кайтаручы пәйгамбәр. Христианнарда – Илья-пророк.

Шигырь Коръәннең 113 нче «Фәлакъ» («Таң») сүрәсенә ияреп язылган.

96 бит.

**Мәҗрух указ.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 7 февраль (501 нче) һәм «Ялт-йолт»ның шул ук елгы 1 нче (15 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Йолдыз»да язылу датасы «4 нче февраль, 1910 сәнә» дип куелган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

1909 елның көзендә элекке Самар губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе) Бозаулык шәһәрендә мулла булып торган язучы һәм журналист Чыгътай (Галиәсгар Гафуров, 1867–1942) «Исабәт» («Хакыйкатькә ирешү») исемле китап язып бастыра. Бу китабында ул Алла, пәйгамбәр һәм ислам дине, аның йолалары, динчеләр адресына карата үзенчәлекле фикерләрен әйтә. Диннең, Коръәннең күктән иңүен кире кага, Коръәнне Мөхәммәднең үзе оештырганлыгын, шулай ук анда үз теләгенә муафикъ булган нәрсәләрне генә кerткәнлеген күрсәтә. «Исабәт» тирәсендә динчеләр шау-шу күтәрәләр. Диния нәзарәте Чыгътайның указын ала. Ул «Йолдыз» газетасында үзенең китабыннан һәм атеистик караш-ларыннан баш тартуы, тәүбә итүе турында хат бастырып чыгара (1910 ел, 31 гыйнвар) һәм, указын кайтару өчен, Уфага Диния нәзарәтенә китә. Үзләре белән якын аралашып йөргән сәләтле язучы һәм журналист Чыгътайның муллалык указын кулыннан җибәрмәс өчен, үз-үзенә каршы килеп, тәүбә итүеннән Тукай ачы көлә. Аның «Мәҗрух указ» шигыре Чыгътай тәүбәсе басылганнан соң бер атна үткәч чыга. Шул ук вакытта «Ялт-йолт» журналының бу шигырь басылган санында, «Исабәтченең тәүбәсе» исемле рәсем-карикатурада, бер чалмалының (ул Чыгътайга охшатып ясалган) күп чалмалылар алдында кул күтәреп, тәүбә догасы укып утырганлыгы күрсәтелә.

Тукай, үзенең «Ник? Нигә?» дигән шигырендә Чыгътай мәсьәләсенә яңадан кагылып:

Ник бу Чыгътай «дау» ясый да, нигә соңра тәүбәсе?
Бүреләрдән куркътисәң, урманга бармау яхшырак, –

дип, Чыгътайның шәхси мәнфәгать өчен үз фикереннән кайтуын тәнкыйтьли.

«Йолдыз»да (1910) басылган шигырьнең соңгы дүртьюллыгында 2 нче юл *«Дәваларга Өфегә чаклы бардым»* дип бирелгән.

[1]*Хиҗаз* – Согуд Гарәбстанындагы Мәккә, Мәдинә, Җиддә шәһәрләре урнашкан өлкә. Мөхәммәд пәйгамбәр белән бәйләнеше булганга, мөселманнар бу шәһәрләрне изге дип санаганнар. Шагыйрь Чыгътайның Мөхәммәдне изгегә санамавына ишарә итеп, киная белән: «Тисен бу, дип, Мөхәммәд хәзрәтенә, төзәп бер ук аттым Хиҗазга», – ди.

[2]*Ук ... килеп ләкте кулымдагы указга.* – Монда Тукай Чыгътайның хәлен борынгы Бабил хөкемдары Нәмруд хәле белән чагыштыра. Риваятьтә Нәмруд ислам диненә өндәргә җибәрелгән Ибраһим пәйгамбәр белән бәхәскә кереп, нииндидер күктәге Аллага буйсынырга теләмичә, күккә ук ата; угы, канга буялып, кире үз башына төшә.

«Күңел җимешләре» җыентыгын чыгарганда, наширләр «/.../ шагыйремездә әүвәлдән дә шактый куәтле хиссияте диния тагы бер кат куәтләнә: «Катиле нәфескә» «Мәҗрух указ» шикелле шигърият җәһәтеннән йомшак, ләкин күңелдән сөйләнгән нәрсәләр» дип язганнар.

97 бит.

**Кәҗә тугърысында.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 1 нче (15 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Ялт-йолт»та «Газеталардан» дигән баш астында мондый юллар китерелә: «Бездә кәҗә асраган кешеләр, бик начар нәселләрне генә асрап, һичбер төрле карамаганлыктан, елына 10–25 чиләктән артык сөт ала алмыйлар. Хәтта җәй көнендә, «ул үзенә ашарга таба» дип, бер дә ашатмыйлар да. Шуның өчен кәҗә һәртөрле караклыкларга бирелеп,

«нәфрәте гомумия»гә мөстәхикъ буладыр. («Сөт кәҗәсе». «Йолдыз, 508 номер, 23 февраль».) Шуннан соң эре хәрефләр белән «Бу хосуста кәҗәнең үз фикере» дип куела, һәм шигырь башланып китә.

Журнал вариантындагы *«Бакчачендә гизәр аның тояклары»* дигән юл Биштомлыкның 2 нче томында (1985), рифма җәһәтеннән булса кирәк, *«Бакчачендә гизәр аның аяклары»* дип үзгәртеп басылган.

«Имеш» һәм «имди» рефреннарын куллану «Кыйссаи Йосыф»тагы шигырь төзелешенә охшашлы итә.

99 бит.

**Зур бәшарәт!** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 1 нче (15 март) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган.

Текст «Яшен ташлары»ннан (2) алынды.

1910 елда Муса Бигиевнең «Рәхмәте илаһия гомуми» («Алланың рәхмәте барлык кешегә дә») дигән китабы басылып чыга. Китапта Ходайның рәхмәте киң булуы, мөселманнарның да, мөселман түгелләрнең дә ахирәттә оҗмахка керәчәкләре Коръән аятьләре белән ныгытылып сөйләнә. Китап чыгу белән зыялы катлам арасында шау-шу күтәрелә, татар-мөселман газета һәм журналлары, аеруча «Дин вә мәгыйшәт», «Бәянелхак», айлар буе озын-озын мәкаләләр бастыралар. Тукай бу шигырендә, «зур сөенеч» дип, шул китаптан, аның тирәсендәге шау-шудан көлә.

100 бит.

**Җәйге таң хатирәсе.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 23 март (518 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

«Күңел җимешләре» җыентыгы башындагы «Берничә сүз»дә наширләр бу шигырь турында: «"Галибанә яктырып әкрен генә таң ата"да шагыйремезне үзенең матурлыгы белән мәфтүн итә. Иң куәтле һәм иң гүзәл шигырьләреннән берсен илһам итә. Ләкин бу мәфтүнияәть озакка сузылмый: нииндидер бер дәһшәтле дулкын Габдулла әфәндене үз эченә ала да «тормышның нурлы почмагын» башка нәрсәләрдә эзләндерә башлый», – дип язганнар.

Әсәр рус шагыйре А.М.Федоровның (1868–1949) «Рассвет» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

**Рассвет**

От сияния победной
Алой утренней зари
Грустно меркнет месяц бледный,
Звезд тускнеют янтари.
Ветерок летит, вздыхая,
Перед близостью утра,
И с зеленой степи, тая,
Поднимается чадра.
В красоте своей волшебной
Развернулась степь кругом,
Птичьих гимнов звон хвалебный
Пал на грудь ее дождем,
И, дивясь великолепью
Каждой травки и цветка,
Точно лебеди, над степью
Серебристой встали цепью
Кочевые облака.

101 бит.

**Авыл җырлары (Дүртенче көлтә).** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 2 нче (1 апрель) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Бу җырлар «Яшен»нең 1908–1909 еллардагы 2, 3 һәм 7 нче саннарында басылган.

[1]*Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит – мәчет Токиода.* – «Дәүре галәм» һәм «Минһаҗ» шигырьләренә бирелгән искәрмәләрне карагыз.

[2]*Әфьюн, каптырма утмәгәч, «Карга» язып уйныйдыр.* – Бу юллары белән Тукай Аксак Низами (Яшел Низаметдин) дип йөртелгән бер кадимче сәүдәгәргә нисбәт ителгән, яңалыкка, тәрәккыяткә каршы юнәлдерелгән «Китабел хәдид ли ибталил җәдид, яки Мисыр каргасы» («Җәдидчеләргә каршы тимердәй нык китап, яки Мисыр каргасы») исемле урам китабыннан көлә.

«Ялт-йолт»ның бу җырлар урнаштырылган санында бер карганы икесе ике аягыннан тотып тартучы кешеләр төшерелгән рәсем бар. Астына «Ысулы кадимчеләр арасында «Китабел хәдид, яхуд Мисыр каргасы» өчен низагъ вә мөхарәбә» дип язылган. Бу түбәндәге хәлне аңлата: әлеге кара брошюра һәм шуныңише нәрсәләр бер-бер артлы чыгып, әдәбият дөньясын пычрата башлагач, демократик матбугатта («Яшен», «Ялт-йолт», «Әлислах» битләрендә) аларга каршы кискен тәнкыйть алып барыла, һәм кадимчеләр, үз яшерен имзаларыннан баш тартып, берсен берсе төртеп күрсәтергә тотыналар. Мәсәлән, мулла һәм шагыйрь Садыйк Иманколый (?–1938) бер газетада, «Карга» минеке түгел, Мөхәммәтҗан Хафизныкы, дип чыга һ.б.

[3]*Кәримевләр Шакирҗаны ... аның төсле ганканы.* – Сүз матбугатта күтәрелгән мәсьәләләр турында еш чыгыш ясаган Шакирҗан Хәмиди («Борадәран Кәримевләр» матбагасында корректор) турында бара.

*Ганка* – фантастик кош, ахмаклык, аңгыралык символы итеп йөртелә. Начар укучы шәкертләргә карата мыскыллау сүзе итеп кулланылган.

[4]*Хөҗҗәт, Нәүрузи кебек.* – Сүз капма-каршы юнәлештәге газета-журналларга актив язышкан публицист, сибирияле Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдев (1917 елда вакытлыча мөфти дә булып тора) һәм журналист, Төркиядә укып кайткач, 1915 елдан «Сибирия» исемендә газета чыгарган, Вәгыйз Нәүрузов (Октябрьдән соң Колчак армиясендә офицер, аклар газетасы «Агыйдел»нең редакторы) турында бара.

[5]*Чыгътай мулла* – «Мәҗрух указ» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз.

102 бит.

**Күңелле сәхифәләр.** «Күңелле сәхифәләр» («Мәктәп мөкяфәте», 4 нче китап) исемле җыентыкта басылган.

Текст шуннан алынды.

16 битлек бу китап төсле рәсемнәр белән бизәлеп, балалар зәвыгына туры килерлек итеп эшләнгән.

104 бит.

**Имтияз алган бала.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) беренче шигырь булып басылган. 1909 елда язылганлыгы әйтелгән. Текст шуннан алынды.

105 бит.

**Һәр ялтыраган алтын түгел.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) елда басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды.

106 бит.

**Безнең гаилә.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылган. Текст шуннан алынды.

107 бит.

**Гали белән Кәҗә.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) 3 нче биттә басылган. Текст шуннан алынды.

108 бит.

**Фатыйма белән Сандугач.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылган.

Текст шуннан алынды.

Шигырь рус шагыйре Н.Г.Цыгановның «Соловушко» («Что ты, соловьюшко...») (1832) әсәреннән файдаланып язылган.

[1]*Кыйл миңа изге дога.* – Татарларның борынгы ышанулары буенча, имеш, күктә сайраган тургай (шулай ук бүтән кошлар да) изгелек эшләгән кешегә дога (яхшы теләк) укый. Бу урында Тукай шуны истә тота.

109 бит.

**Һәркемнең ашыйсы килә.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылган. Текст шуннан алынды. Шигырь 1909 елда язылган.

110 бит.

**Ялкау Маэмай.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды.

111 бит.

**Шаян Песи.** «Күнелле сәхифәләр»дә (1910) басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды.

112 бит.

**Кызыклы Шәкерт.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды.

113 бит.

**Бичара Куян.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды. Шигырь 1909 елда язылган.

114 бит.

**Ак Бабай.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды. Шигырь 1909 елда язылган.

115 бит.

**Кичә һәм бүген.** «Күңелле сәхифәләр»дә (1910) басылып, 1909 елда язылганлыгы искәртелгән. Текст шуннан алынды.

116 бит.

**Мигъраҗ.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 13 апрель (527 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Йолдыз»дан алып «Шура» журналы үзенең 1910 елгы 9 нчы (1 май) санына урнаштырган. «Күңел җимешләре»нә кертелгән.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Коръәннең «Исра» (17 нче) сүрәсендә Мөхәммәднең Мәккәдәге әл-Хәрам мәчетеннән Коддестәге әл-Акса мәчетенә Бурак исемле мифик хайванга атланып ясаган төнге хыялый сәяхәте һәм аннан яктылык баскычы буенча, Алла белән сөйләшү өчен, күккә ашкан төне – ләйләт әл-Мигъраҗ турында сөйләнә. Бу могъҗиз вакыйганы истә калдыру нияте белән мөселманнар рәҗәб аеның 27 нче көнендә мигъраҗ төнен искә алалар. Пәйгамбәрнең шушы сөйләгәннәре нигезендә фәрештәләрнең Мөхәммәдне Иерусалимдагы (Коддес) Сөләйман (Соломон) сарае кыясына менгерүләре турында риваять туган.

Г.Тукай бу шигырен Коръәннең шушы сүрәсеннән һәм риваятьләрдән файдаланып язган.

118 бит.

**Ике иптәш арасында.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 3 нче (15 апрель) санында «Һөҗүвият» дигән рубрика астында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Шигырь А.С.Пушкинның «Любопытный» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

– Что ж нового? «Ей-богу, ничего».
– Эй, не хитри: ты, верно, что-то знаешь.
Не стыдно ли, от друга своего,
Как от врага, ты вечно все скрываешь.
Иль ты сердит: помилуй, брат, за что?
Не будь упрям: скажи ты мне хоть слово...
«Ох! Отвяжись, я знаю только то,
Что ты дурак, да это уж не ново».

119 бит.

**Ник? Нигә?** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 3 нче (15 апрель) санында имзасыз басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Ф.Сәйфи-Казанлы төзеп чыгарган Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) урнаштырылган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

[1]*«Болакыл хак»* – болай дип Тукай «Бәянелхак» газетасын атый. Аның редакциясе шәһәр уртасыннан узган, ул заманда пычрак һәм сасы Болак елгасы буена урнашкан булган.

[2]*Нигә мәнфур... агълашубән: «Әлфиракъ!»* – Тукай бу юллары белән китапчыларның табыш артыннан куууларын тәнкыйтьли.

[3]*Нигә курка... Дәһри кырак!* – «Зур бәшарәт!» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз.

[4]*Нәрсәгә... «Карга» язу?* – «Авыл җырлары» (Дүртенче көлтә) шигыренә бирелгән искәрмәләрне карагыз.

[5]*Ник Шакирҗанел Хәмиди... салам сыйрак!* – «Авыл җырлары» (Дүртенче көлтә) шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз.

[6]*Ник бу Чыгътай... бармау яхшырак.* – «Авыл җырлары» (Дүртенче көлтә) шигыренә бирелгән искәрмәләрне карагыз.

[7]*Нигә тончыкты «Чүкеч»... йөзенә былчырак?!* – «Авыл җырлары» (Өченче көлтә) шигыренә бирелгән искәрмәләрне карагыз.

[8]*Ник Орынбурда... «Мәгыйшәт» тагы бер кат шахшырак.* – Сүз 1906 –1918 елларда Оренбургта атнага бер тапкыр чыга торган «Дин вә мәгыйшәт» журналы (нашире һәм мөхәррире Мөхәммәдвәли мулла Хөсәенов (1871–1933) турында бара.

120 бит.

**Катиле нәфескә.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 15 апрель (528 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

«Күңел җимешләре» җыентыгы башындагы «Берничә сүз»дә наширләр «/.../ шагыйремездә әүвәлдән дә шактый куәтле хиссияте диния тагы бер кат куәтләнә: «Катиле нәфескә», «Мәҗрух указ» шикелле шигърияте җәһәтеннән йомшак, ләкин күңелдән сөйләнгән нәрсәләр» дип язганнар.

Кайберәүләр, язучы һәм журналист Мәхмүт Галәүнең Тукай турындагы истәлегенә таянып, шигырьнең язылу тарихы журналист Исхак Бикчуринның асылынып үлүе белән бәйле түгелме икән дигән фикердә иделәр. Бу хәл була алмый, чөнки Исхак Бикчурин шигырь басылып чыгып өч ел үткәннән соң гына, 1913 елның 20 апрелендә үзен үзе үтергән. Бу хакта «Кояш» газетасының 1913 елгы 21 апрель санында некролог бар. Шулай да, К.Бәкернең 1914 елда язган «Тукай Петербургта» китабын игътибар белән укысаң, мәсьәләгә ачыклык кертергә мөмкин. Шагыйрь Казанда чакта бервакыт муенына элмәк салу фикеренә килгән һәм бу ниятен тормышка ашыру омтылышы да ясаган. Шунысы кызык: үзен үзе җиңгән шагыйрь шигырь басылган көнне кичен «Шәрык» клубына халык әдәбияты турында лекция укырга юнәлә.

121 бит.

**Газаптан соң.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 19 апрель (529 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Әсәр А.Н.Майковның (1821–1897) «В альбом» шигыреннән файдаланып язылган.

Жизнь еще передо мною
Вся в видениях и звуках,
Точно город дальний утром,
Полный звона, полный блеска!..
Все минувшие страданья
Вспоминаю я с восторгом,
Как ступени, по которым
Восходил я к светлой цели...

*1857*

122 бит.

**Ачы тәҗрибә авазы.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 21 апрель (530 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Шигырь басылып 4 көн үткәннән соң, «Йолдыз»ның 25 апрель санында төзәтү (тәсхих) бирелә: «Ачы тәҗрибә авазы» сәрләүхәле шигырьнең 2 нче сәтырында *«яшме»* сүзен *«яшемне»* дип һәм 25 нче сәтырында *«Менә шул чак тәмам аптырыйм да»* җөмләсен *«Менә шул чак тәмам мин аптырыйм да»* дип укырга тиеш», – диелә. Моннан соң булган басмаларда шушы төзәтелгән текст варианты кулланылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Тормышта кешегә ышану-ышанмау, икейөзлелек мотивы төрки-татар әдәбиятында элек-электән үк чагылдырылып килә. Шагыйрь шушы традицион мотивны үзенчә эшкәртә, буыннар яшәешендә сыналган «ачы тәҗрибә авазы» рәвешендә тәкъдим итә.

124 бит.

**Җәй көнендә.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 25 апрель (531 нче) санында «Яз хәбәре» шигыреннән соң «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Шигырь рус шагыйре В.И.Водовозовның (1825–1886) «Летом» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

125 бит.

**Мәҗлес.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 25 апрель (531 нче) санында басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Әсәр А.С.Пушкинның «Веселый пир» (1819) исемле шигыреннән файдаланып язылган.

Я люблю вечерний пир,
Где веселье председатель,
А свобода, мой кумир,
За столом законодатель,
Где до утра слово *пей!*
Заглушает крики песен,
Где просторен круг гостей,
А кружок бутылок тесен.

Һәр ике шигырьдә дә тема бер үк кебек: мәҗлес, дуслар, кәеф-сафа корып утыру. Әмма Тукайда азатлык, ирек киңрәк мәгънәдә. Бу чорда кара реакция әкренләп чигенә башлаган, Россия яңа күтәрелеш алдында торган вакыт. Шуңа күрә дә шагыйрь «хөррият белән шатлык рәис» булган, дуслар утырган мәҗлесне генә сөюен әйтә. Пушкин үзенең мәҗлестәшләрен «гость» дип атаса, татарда җыелышып эчү хупланмаганга, Тукай руслардагы кунак төшенчәсен «эчкән кешеләр» сүзе белән алыштыра.

126 бит.

**Яз хәбәре.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 25 апрель (531 нче) санында, «Русчадан» дип искәртелеп, имзасыз басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

«Йолдыз»да өстән 5 нче юл – *«Яз җитәдер, файдасы юк, күпме гайрәтләнсә март»*, 8 нче юл *«Тиздән иснәрмез: кызыл, ал, ак чәчәкләрнең исен!»* дип бирелеп, «Күңел җимешләре»нән (1911) үзгәртелгән текст басылган. Тукай бу шигырен XIX гасыр рус шагыйре А.Н.Майковның (1821–1897) «Ласточка примчалась из-за бела моря...» дип башлана торган исемсез шигыре сюжетыннан файдаланып язган.

Ласточка примчалась
Из-за бела моря,
Села и запела:
Как, февраль, ни злися,
Как ты, март, ни хмурься,
Будь хоть снег, хоть дождик –
Все весною пахнет!

*1858*

[1]*Ясин* – Коръәннең 36 нчы сүрәсе. Аны үлем түшәгендәге кешенең баш очында укыйлар.

127 бит.

***** («Ике хатын берлә тормыш...»).** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 4 нче (1 май) санында рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Ахырына «Авыл хәбәрләрендән» дип куелган. Беренче тапкыр Тукайның икенче Дүрттомлыгының 2 нче томына (1976) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Рәсемдә татарча җыештырылган бүлмә. Сандык өстенә мендәр өелгән. Стенада Мәккә-Мәдинә сурәте. Ике хатын өстәл кырыенда бер-берсенә артын куеп утырган: әле генә ачуланышканлыклары аңлашыла. Кәҗә сакаллы, кара түбәтәйле ир пары чыгып торган самовар күтәреп килә. «Хатын өстенә хатын алсаң, менә шулай була ул» дигән шигъри юл – шушы манзарага төртеп күрсәтү.

Мәгълүм ки, «Яшен», «Ялт-йолт» журналларында рәсем асларының, – барысының да диярлек, – темаларын Тукай бирә, рәсем асты текстларын яза. Шигырь Тукайның «Авыл җырлары» стилендә язылган. Теле-стиле Тукайның биш көлтә «Авыл җырлары»ннан аерылгысыз булуы, темасы (Г.Исхакыйның шул елларда сәхнәдә уйналган «Өч хатын берлән тормыш» пьесасына да ишарә бар) бу икеюллыкны анык дип расларга нигез бирә.

128 бит.

**Кайчакта.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 2 май (534 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Биографиясеннән күренгәнчә, 1910 ел – шагыйрь өчен бик авыр чор. Сатирик «Яшен» журналы чыгудан туктагач, Тукай ике кулсыз калгандай була. Ниһаять, «Яшен»гә алмашка «Ялт-йолт» журналы килә. Ләкин сәламәтлек ягыннан Тукайның күңеле тыныч түгел. Бу чор матбугатына игътибар итсәң, апрель-май айларында шагыйрьнең кулы эшкә бармаганлыгы, аның журнал сораганга яисә инерция беләнрәк кенә язганлыгы күренә. Күңеленең халәтен үзе үк шушы «Кайчакта» шигырендә искәртә.

129 бит.

**Гомер юлына керүчеләргә.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 16 май (540 нчы) санында, «Позняковка тәкълид» икәнлеге күрсәтелеп, «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Язылу датасы «12 нче май, 1910 сәнә» дип куелган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Шигырь рус шагыйре Н.И.Позняковның (1856–1910) «В жизнь вступающим» әсәреннән файдаланып язылган.

131 бит.

**Өмидсезлек.** «Вакыт»ның 1910 елгы 22 май (620 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Фәтхи Бурнаш төзеп чыгарган «Г.Тукай шигырьләре» җыентыгында: (Казан: «Гажур» нәшере, 1926) басылган.

Текст «Вакыт»тан алынды.

Революция чигенгән, реакция котырынган бер чорда шагыйрь иҗатында төшенкелек, өметсезлек мотивлары көчәя. Халык язмышын уйлап ачыргаланган Тукайда трагик яңгыраш үзәк мотивка әверелә башлый.

132 бит.

**Хале хазир.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 10 июнь (550 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «6 нчы июнь, 1910 сәнә» дип куелган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Йолдыз»дан алынды.

133 бит.

**Үкенеч.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 1 июль (558 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «28 июнь, 1910 сәнә» дип куелган.

Газетада шигырьнең өстән 10 нчы юлы *«Яна күкдә ничек бер данә йолдыз»* дип бирелә. «Күңел җимешләре»ндә (1911) шушы ук юлдагы сүзләрнең урыннары гына алыштырылып, *«Ничек күктә яна бер данә йолдыз»* рәвешендә тәкъдим ителә.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

134 бит.

**Хасият.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 6 июль (560 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган, «2 июль, 1910 сәнә» дип куелган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Газетада ахырдагы икеюллык:

*Ни дирсең, сүз татар тугърында булса,*
*Тиле төсле, диерсең: «ул сакаллы», –*

дип бирелсә, «Күңел җимешләре»ндә:

*Ни дирсең, сүз татар тугърында булса?*
*Табалмый сүз, диерсең: «ул – сакаллы», –*

дип үзгәртелгән.

Биштомлыкның 2 нче томына (1985) *«дирсең»* сүзе *«дисең»* рәвешендә бирелә.

135 бит.

**Яшьләр.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 9 нчы (15 июль) һәм «Йолдыз»ның шул ук елгы 25 июль (567 нче) саннарында басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Газетада шигырь исемсез бирелгән һәм ахырда «Г.Тукай. 18 июль. 1910 сәнә» дип күрсәтелгән.

136 бит.

**Танса.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 10 нчы (1 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

137 бит.

**Иссез чәчәк.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 22 август (578 нче) санында «Русчадан» дип күрсәтелеп, «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «6 август, 1910 сәнә» дип куелган.

Газетада шигырьнең 1 нче *«Болынлыкта үсәр гади генә, иссез чәчәк, яңлыш»* һәм 5 нче *«Шуның күк безне тәүфикъле дуст-ишләр һәм белешләр дә»* юллары «Күңел җимешләре»ндә (1911) үзгәртелгән.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Әсәр рус шагыйре И.И.Дмитриевнең (1760–1837) «Полевой цветок» исемле парчасыннан файдаланып язылган.

Простой цветочек, дикой,
Нечаянно попал в один пучок с гвоздикой;
И что же? От нее душистым стал и сам –
Хорошее всегда знакомство в прибыль нам.
*1805*

138 бит.

**Сибгатуллин.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 11 нче (15 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Бу – 1905–1907 елларда Уральскида «Фикер», «Уралец», «Уральский дневник» газеталарын һәм «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналларын чыгаручы, соңыннан җырчы, артист булып киткән Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинга (1883–1941) багышланган сатирик шигырь. Тукайга аның зәвыксызлыгы, тыйнаксызлыгы, рестораннарда җырлап йөрүе һич тә ошамый. Шуңа күрә җае чыккан саен аны әсәрләрендә җәмәгатьчелек алдында фаш итеп тора, усал көлә. Ул елларда К.Мотыйгыйның бу эшләре «Дин вә мәгыйшәт» журналында да тәнкыйть ителә.

139 бит.

**Күгәрчен.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 15 август (575 нче) санында Тукайның «Т.» имзасы белән басылган. Шигырьнең исеменнән соң «Русчадан» дип куелган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Әсәр А.С.Пушкин әтисенең абыйсы В.Л.Пушкинның (1766–1830) «Голубка» (1806) исемле шигыренә нигезләнеп язылган.

Голубка, под кустом прижавшись, говорила:
Ах, ястреб пролетел! Какая злость и сила!
Но, право, я должна судьбу благодарить,
Что ястребом она меня не сотворила!
Не лучше ль жертвою, а не злодеем быть?

Ә В.Л.Пушкин бу әсәрен француз шагыйре Жан-Жак Бассардан (1743–1831) тәрҗемә иткән. Текстлар бер-берсе белән туры килә. Әмма Тукай эчтәлекне детальләштерә төшкән.

140 бит.

**Баскыч.** «Йолдыз»ның 1910 елгы 22 август (578 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән, «Русчадан» дип басылган. Әмма ялгышлык белән әсәрнең 4 нче юлы төшеп калган була һәм Тукай газетаның 26 август (579 нчы) санында төзәтмә бирә.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Бу шигырь А.Е.Измайловның (1779–1831) «Лестница» исемле шигыреннән файдаланып язылган. Ул шигырьнең тексты:

Стояла лестница однажды у стены.
Хотя ступени все между собой равны,
Ну верхняя ступень пред нижним гордилась.
Шел мимо человек: на лестницу взглянул,
Схватил ее, перевернул, –
И верхняя ступень внизу уж очутилась.
Так человек иной на вышке стоит,
Гордится, и глядишь, как раз на низ слетишь!
Возьмем в пример Наполеона:
Как Сатана с небес, так он слетел со трона.

А.Е.Измайлов үзе бу әсәрне француз теленнән тәрҗемә иткән.

141 бит.

**Бер мән.** «Вакыт»ның 1910 елгы 22 сентябрь (671 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган. «Казан, 23 август» дип куелган. Текст шуннан алынды.

143 бит.

**Мөбарәк тәсбих өзелде.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 13 нче (15 сентябрь) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

«Ялт-йолт»та 2 нче кызыл юлда «*...күптән вакыт булса да катмый, һаман ага да ага».*

5 нче кызыл юлда: «*Һәммәсе секундта* бер олугъ... *һәлакәт булачагын».*

15 нче кызыл юлда: «...чуарлап *куныштканнар, әүвәлгечә шаулашмыйлар, тын гына фаҗигъ вакыйга көтәләр».*

18 нче кызыл юлда *«агар сулар дәфгатән агудан туктадылар,...*» дип бирелә.

Тукай Лев Толстойның үлеме уңае белән язылган бу язмасын шигырьләр җыентыгына урнаштыра һәм почмагына:

Ушбуны яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве,
Мәсьәлә бик зур – сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве, –

дигән эпиграф куя. Аннан күренгәнчә, тетрәткеч вакыйга Тукайны шигырь язарга этәрә, әмма үзе күрсәткән сәбәпләр аркасында ул проза жанрына мөрәҗәгать иткән. Шулай да әсәрне шигырь җыентыгына кертә, чөнки «Мөбарәк тәсбих өзелде» – нәсер, хәзерге төшенчә белән әйткәндә, чәчмә шигырь. Формасы, башлам рефреннары, аллегория, метафора, сынландыру, эчке рифма, сурәтле сүзләр – барысы да шигырь арсеналыннан.

Л.Н.Толстой 1910 елның 7 (20) ноябрендә вафат була. Г.Тукай нәсере исә журналның 15 сентябрь датасы белән чыккан санында басылган. Ничек аңларга? Эш шунда ки, ул чагында журналлар, аеруча демократик юнәлештәге басмалар, материаль кысынкылыклар сәбәпле генә түгел, цензура киртәләре аркасында да (реакция чоры!) нык соңлап чыгалар. Бу очракта «Ялт-йолт»ның 15 сентябрь саны ай ярымнан артык вакытка соңлаган, типографиядә басылуы Толстой үлгән көннәргә туры килгән. Ялт-йолтчылар, оперативлык күрсәтеп, Тукай нәсерен тиз генә шушы санга урнаштырганнар.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

[1]*Андреев, Максим Горький, Потапенко, Куприн, Сологуб, Мережковский, Григорий Петров, Скиталец* – биредә сүз Андреев Леонид Николаевич (1871–1919), Максим Горький (Пешков Алексей Максимович) (1868–1936), Потапенко Игнатий Николаевич (1856–1929), Куприн Александр Иванович (1870–1938), Сологуб (псевдоним, чын фамилиясе – Тетерников) Федор Кузьмич (1863–1927), Мережковский Дмитрий Сергеевич (1866–1941), Скиталец (псевдоним, чын фамилиясе – Петров) Степан Гаврилович (1869–1941) турында бара.

[2]*Мәрьям анасы, яки имамы* – бер җепкә тезелгән тәсбих төймәләре арасында баш төймә. Монда күчермә мәгънәдә.

[3]*Һушы китеп егылган Максим Горький* – шул чактагы газеталардан алынган хәбәр.

145 бит.

**Актык тамчы яшь.** «Вакыт»ның 1910 елгы 22 сентябрь (671 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

«Күңел җимешләре» китабының баширләре «Актык тамчы яшь» шигырен ихлассыз чыккан дип язалар.

146 бит.

**Граммофонда татар җырлары.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 14 нче (1 октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Текст «Яшен ташлары»ннан (2) алынды.

147 бит.

**Ит базарында тәрәкъкый.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 14 нче (1 октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән (югарыдагы шигырь белән икесенә бер имза) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*«Бәянелхак»* – 1906–1914 елларда Казанда чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Нашире һәм мөхәррирләре – Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр, Ш.Иманаев.

[2]*«Йолдыз»* – 1906–1918 елларда Казанда чыккан иҗтимагый-сәяси газета.

[3]*«Ялт-йолт»* – 1910–1918 елларда Казанда чыккан сатирик-юмористик, рәсемле журнал. Мөхәррире – Ә.Урманчиев.

[4]*«Чукеч»* – 1906–1910 елларда Оренбург шәһәрендә чыккан иҗтимагый-сәяси, әдәби-сатирик, рәсемле журнал.

[5]*«Без»* – С.Рәмиев карамагында «Казан мөхбире» (1905–1911) газетасына кушымта итеп чыгарылган көлке бите. Шушы бүлек аша ул башта «Яшен», аннары «Ялт-йолт» һәм «Чүкеч» журналларына каршы көрәшеп килә.

[6]*Мөселман (казлыгы) казылыгы* – үз товарын шәбрәк үткәрү өчен, шундый исем белән казылыкларны Габдулла Килдишев дигән сәүдәгәр чыгара. Ул: «Ауропа ысулында эшләнгән мөселман казылыклары», – дип, үзенең казылыклары турында газета һәм журналларда игъланнар бастырган була. Бу хәл шул еллардагы сатирик журналлар өчен көлкеле бер материал булып хезмәт итә. Шуның ачык бер мисалы «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 18 нче саны тышлыгында басылган рәсем-карикатура.

148 бит.

***** («Сәгатьләр келт-келт итәдер...»).** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 14 нче (1 октябрь) санында «Гаилә сәгадәте» дип исемләнгән рәсем-карикатура асты итеп имзасыз басылган. «Яшен ташлары»нда (1) барлык «көлтәләр»не бергә туплап, бер баш астында биргәндә, бу икеюллык та урнаштырылган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Рәсем-карикатурада калфаклы бер хатын ялгызы гына чәй эчә, читтәрәк самовары кайнап утыра. Стенадагы сәгать берне күрсәтә. Урындыкта бала, ире өйдә юк.

149 бит.

**Елның дүрт фасылы.** «Яңа кыйраәт»тә басылган.

Текст шуннан алынды.

«Яңа кыйраәт» исемле китап җыентык буларак «бөтенләй яңа тәртип белән эшләнеп, монда бик күп яңа фикер вә әхлакый мәкаләләр вә яңа шигырьләр кертелеп тәкъмил ителә».

«Мөгаллим әфәнделәр дикъкатенә» дигән кереш сүздә кыйраәт китапларының максатлары, бурычлары нәрсәдән гыйбарәт икәнлеге хакында болай язылган: «Боларны үзләренә рәгъбәтләндереп укуда мәкалә хасил иттерергә, укуга нәрсәләрен аңларга вә андан кирәгенчә нәтиҗә чыгарырга өйрәтергә, сөйдерергә вә мәкруһ күрсәтергә һәм мөкаддәс ана теленең дөрест тәртип вә тәэлифе белән белешләндерергә тиешле вә муаззафлардыр».

Тышлыкта беренче якта – «Мәгариф» китапханәсе тарафыннан нәшер ителмеш мәктәп китаплары исемлеге һәм икенче ягында «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабының матбагага бирелүе хакында игълан урнаштырылган.

Җыентыкка 1 нче басмадан да алынып 25 исемдәге әсәр кертелгән. Шулардан «Елның дүрт фасылы» шигыре беренче мәртәбә басыла. «Русчадан» дип куелган.

Бу әсәр рус телендәге дәреслекләрдә басылып йөргән «Четыре времени года» исемле шигырьдән файдаланып язылган.

Тает снежок,
Ожил лужок,
День прибывает...
Когда это бывает?
Солнце печет,
Липа цветет,
Рожь поспевает...
Когда это бывает?
Пусты поля,
Мокнет земля,
Дождь поливает...
Когда это бывает?

Снег на полях,
Лед на реках,
Вьюга гуляет...
Когда это бывает?

151 бит.

**Төш.** «Вакыт»ның 1910 елгы 20 ноябрь (696 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Гетедән» дип куелган. «Күңел җимешләре»ндәге «Берничә сүз»не язучылар (наширләр) уенча, «Төш» шигыре ихлассыз чыккан.

«Вакыт»та 3 нче строфаның 1 нче юлы *«Дүрт ягымны чорнап алган гаскәрләрдә...»* дип, 5 нче строфаның 1 нче, 2 нче һәм 3 нче юллары *«Егълап туйгач килде аңар шатлык янә: Юкка гына егъладым, ди, шашып кына», «Югалтсам тик югалттым (ди) шаһлык кына»* дип бирелгән.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

152 бит.

**Өзелгән өмид**. «Вакыт»ның 1910 елгы 29 ноябрь (700 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Тукай, «...менә шушылай дип бер шигырьчек яза башладым» дип, «Өзелгән өмид»нең баштагы 6 юлын С.Сүнчәләйгә 1910 елның 9 ноябрендә язган хатына теркәп җибәрә. Икенче хатында исә (1910 ел, 4 декабрь) «Минем синең хатың эченә язып җибәргән күңелсез шигыремнең ахырлары да «Вакыт»ның бәйрәм нумерында басылып чыкты» дип хәбәр итә. Шулай итеп, шигырь 9 ноябрьгә үк инде яртылаш язылган була.

Бу шигырь 1914 елда ук русчага да тәрҗемә ителеп басыла.

153 бит.

**Кайда? Кем?** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 18 нче (1 декабрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган, «Ялт-йолт»тагы 3 нче строфаның соңгы юлы *«Түнтәр аулы чалмалы карт марҗасы»* дип бирелгән. Шигырьнең 3 нче юлы «Ялт-йолт»та 2 нче строфаның 1 нче юлы *«Кем җигәр безгә тәдәнни арбасы?»* дип бирелгән.

Текст «Яшен ташлары»ннан (2) алынды.

[1]*Бер авылның чалмалы карт марҗасы.* – Бу шигырь дин эшлеклесе, кадимчелек вәкиле, Вятка губернасының Малмыж өязе Түнтәр авылы кешесе Ишми ишан – Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев (1849–1919) турында. Ул Түнтәр авылында мәдрәсә тоткан. Алдынгы фикерле татар дин әһелләренә, яңа ысул белән эшләүче мәдрәсәләргә («Буби» һ.б.) каршы эш алып бара. Большевиклар тарафыннан атып үтерелә. Дини эчтәлекле китаплар авторы.

154 бит.

**Тәләһһеф.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 18 нче (1 декабрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Буби»лар вакыйгасы уңае белән язылган. «Мәҗмугаи асарь»гә (1914) кертелгән. Текст соңгысыннан алынды.

Петербургта яшәүче Кәрим Сәгыйть, «Җан азыклары» җыентыгы белән танышкач, «Тәләһһеф» шигыре хакында, «фәсыйх вә балигъ, чын ихластан әйтелгән мәгънәсе бөек, дөрес шигырь...» дип, Тукайга хат яза.

155 бит.

**Өйләнү – түгел сөйләнү.** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 19 нчы (15 декабрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Яшен ташлары»на (2) урнаштырганда 9, 41, 46, 71 нче юллар

*«Хатын алмак читен эш һәм мәшәкъкать»,*
*«– Алай булгач, өйлән син, чикмә ваем»,*
*«Сәбәп булса һаман юк кычкырышка»,*
*«Баеп китсә алар сәүдә юлында»* дип үзгәртелгән.

Текст «Яшен ташлары»ннан (2) алынды.

Тукай бу шигырьгә «Иванов-Классиктан» дип куйган. «Классик» – А.Ф.Ивановның (1841–1894) псевдонимы. Әсәр аның «Советы» исемле 44 юллы шигыреннән файдаланып язылган.

Шигырь:

К тебе за советом приехал я, кум,
Есть важное дело, поставь, брат, на ум.
Я вздумал жениться: загрызла тоска...
– Ну, что же? И с Богом женись, брат, Лука... –

дип башлана.

Тукай, шигырьнең эчтәлеген гомумән саклаган хәлдә, андагы күренешләрне беркадәр киңәйтеп бирә һәм әсәр 86 юллы булып иҗат ителә.

«Совет» шигыренең ахыры болай бетә:

И так, что же делать?.. А но вас совсем,
Друзья адвокаты! Не верю вам всем!
Пойду я жениться, схватишься за ум,
Пойди же ты к черту с советами, кум!..

Тукай шигырьнең бу соңгы строфасын төшереп калдырып, аның урынына яңаны өстәгән.

158 бит.

**...га («Бул кеше...»).** Тукай үлгәч, кульязмалары арасыннан табылып басыла башлаган. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Әсәр Тукайның замандашлары арасыннан эчкече бер куштанга атап язылган. Бай балаларының калдык хәмеренә сатылып, аларның вак йомышларын үтәп йөрүче күздә тотыла. Шагыйрь бу эшнең укымышлылык белән сыешмавын, гыйлемне әрәм итү икәнлеген искәртә.

159 бит.

***** («Кушмый ишан хилкасендә...»).** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 19 нчы санында (15 декабрь) рәсем-карикатура асты итеп имзасыз басылган. Шигырь беренче тапкыр Биштомлыкның 2 нче томына (1985) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Карикатура өстенә «Әннәсолул хәдидә» кайда тәсниф ителгән?» дигән баш куелган. Карикатурада түгәрәк өстәл. Аның артында чалмалы, түбәтәйле, фәсле искеләр тезелешеп утырган хилка (түгәрәк). Уртада Гыйлаҗ мулла (өстенә «Әннәсолул хәдидә» язучы» дип язылган). Гыйлаҗ мулла артында аңа терәлеп үк Биби басып тора (кырыена «Чаршау Биби» дип язылган). Уң якта – Ишморатов бай (астына «Дудка» дип куелган). Өстәлдә – шешәләр, стаканнар. Гыйлаҗ мулла алдында кәгазь, кулында карандаш. Артта, уңдарак, калфаклы бер хатын. Түшәмдә куыклы лампа яна – төн уртасы.

Карикатура астында әлеге дүртьюллык.

«Биби. Нәрсә язасың, хәзрәтем?

Гыйлаҗ. Әле, җаным, синең арттан җөри-җөри, оныткanмын. Кушмый хәзрәт бер китап җазарга кушкан иде».

*Әнәсолул хәдидә* – Әннәсолул хәдидә ли-иб татыйль ысулы җәдидә. (Ысулы җәдидәне юкка чыгара торган тимер кебек нык китап.)

*Ишморатов* – Ишморатов Габдрахман Әхмәт улы (1857–1922), Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре, җирбиләүче, фабрика, ат заводы хуҗасы. Казан шәһәр думасы гласные. Җәдидчелеккә, җәдиди мәдрәсәләр ачуга каршы була. «Дудка» үз кубызына биетүче дигәнне аңлата.

*Кушмый хәзрәт* – Ишми ишан, Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев («Кайда? Кем?» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз).

[1]*Прахут Мәхүб, Чаршау Биби* – фахишәләр, Казанда фәхешханә тотучылар.

[2]*Гыйлаҗ абзаң Сәрвәри* – элекке Казан өязе Тимерче авылы (хәзер Татарстан Республикасының Биектау районына карый) мулласы Гыйлаҗ (Гыйлаҗетдин) Мөхетдинев Сәрдәи.

**1911**

160 бит.

**Борын.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 20 нче (1 гыйнвар) санында «Шүрәле» имзасы белән «Русчадан» дип басылган.

Текст «Яшен ташлары»ннан (2) алынды.

161 бит.

**Кушмый ишәк җырлый.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 20 нче (1 гыйнвар) санында «Түнтәреф» кушаматы-псевдонимы белән басылган. Бу псевдоним журналда, гомумән, татар вакытлы матбугатында бүтән очрамый. Шигырь беренче тапкыр икенче Дүрттомлыкның 2 нче томына (1976) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Тукай бу шигырен үзенең биш «көлтә»дән торган сатирик «Авыл җырлары» тибында язган («Авыл җырлары»ның Беренче, Икенче «көлтә»ләрен шушы басманың 1 нче томыннан, Өченче, Дүртенче, Бишенче «көлтә»ләрен шушы томнан карагыз). «Авыл җырлары»нда һәр строфа бер шәхескә багышланган булса, бу җыр бөтене белән Вятка губернасы Малмыж өязе Түнтәр авылы кешесе, кадимчелек вәкиле Ишми ишан Ишмөхәммәд Динмөхәммәтев (шушы томдагы «Кайда? Кем?» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз) турында. Тукай Ишми ишанның (Кушмый ишәкнең) хәл-теләкләрен үзеннән сөйләтә. Шуның өчен дә имзаны аның исеменнән «Түнтәреф» дип куя.

[1]*Әптрәхмәнем...* – Габдрахман Ишморатов («Кушмый ишан хилкасендә...» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз).

[2]*Чәчле абзыкайларга!* – патша чиновниклары, поплар күздә тотыла.

162 бит.

***** («Төркия янгын эчендә...»).** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 20 нче (1 гыйнвар) санында имзасыз басылган. Беренче тапкыр икенче Дүрттомлыкның 2 нче томына (1976) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Журналның 9 нчы битендә рәсем-карикатура бирелгән. Анда фәсле, мыеклы бер төрек басып тора, аның тирә-ягы ут, төтен, ялкын белән чорнап алынган. Аска сул якка әлеге икеюллык урнаштырылган.

[1]*...дерзиләр, арнаут (албаниялеләр)* – 1911 елга кадәр Төркия кул астында яшәгән халыклар.

163 бит.

**...га («Шома тормыш юлында...»).** «Шура» журналының 1911 елгы 2 нче (15 гыйнвар) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Пушкиннан мокътәбәс» дип куелган.

Текст «Күңел җимешләре»ннән (1911) алынды.

Г.Тукай замандашларыннан К.Мостакайның (1883–1974) истәлекләренә караганда, шигырь атаклы тәрҗемәче Солтан Рахманколыйга (1888–1916) багышланган (истәлек Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә (9 ф.) саклана).

Әсәр А.С.Пушкинның «Когда твои младые лета...» (1829) исемле шигыре тәэсирендә язылган.

Когда твои младые лета
Позорит шумная молва,

И ты по приговору света
На честь утратила права;

Один среди толпы холодной
Твои страданья я делю
И за тебя мольбой бесплодной
Кумир бесчувственный молю.

Но свет... Жестоких осуждений
Не изменяет он своих:
Он не карает заблуждений,
Но тайны требует для них.

Достойны равного презренья
Его тщеславная любовь
И лицемерные гоненья:
К забвенью сердце приготовь;

Не пей мутительной отравы;
Оставь блестящий, душный круг;
Оставь безумные забавы:
Тебе один остался друг.

164 бит.

**Мияубикә.** Г.Тукай шагыйрь С.Сүнчәләйгә 1911 елның 4 мартында язган хатында: «Мин бу арада балалар өчен «Песи Г.Җамал» яки «Песибикә» исемле бер рәсемле рисалә язып бетердем. Шактый муаффәкыятьле чыкты», – дип хәбәр итә. Өч айдан бу рисалә «Мияубикә» исеме белән китап булып басылып та чыга.

«Бер-ике сүз» дип «Сабах» идарәсеннән бирелгән сүз башында: «Без моннан мөкаддәм шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев тарафыннан балалар ичүн тәртип ителгән әсәрләрне «Мәктәп мөкяфәте» исемендә бер серия (мәҗмуга) итеп нәшер иткән идек. Ләкин без, ул мәҗмуганы никадәр яхшы вә гүзәл итеп чыгарсак та, балаларга үзебезнең уйлаганымызны бирә алдык вә, гомумән, анлар каршында булган бурычымызны үтәдек диеп әйтә алмыймыз. Чөнки ул мәҗмуганың китаплары үземезгә дә гаять кыйммәт төшдекләреннән, бәһәләрене дә кыйммәтрәк куярга мәҗбүр булган идек. Шуның өчен ул китапларны югарырак сыйныфлар вә хәллерәк балалар алып укый алсалар да, фәкыйрь вә яланаяклы балалар да укып файдаландылар диеп булмый. Инде менә без, шуны игътибарга алып, «Мәктәп көтепханәсе» исемендә арзанлы вә һәрбер укый-яза белгән яланаяклы балалар аңларлык рәвештә яңа бер серия ачтык вә шул мәҗмугадан беренче китап уларак шагыйрь Габдулла әфәнденең ошбу «Мияубикә» нам әсәрене мәйданга куйдык. «Мияубикә»дә Габдулла әфәнде, балаларның иң якын дусты вә иптәше булган песинең холык вә табигатене яза вә, аның халәте рухиясен, тикшереп, егермегә аера да шул егерме халәтне гаять мәһарәт илә тасвир итә. Вә иң ахырдан песинең үлеп яткан халәтене язып аңар мәрсия укый вә бу мәрсияне «һәм кыямәт көн мине күрсәң мыраулап каршы ал» диеп бетерә. «Мәктәп көтепханәсе» мәҗмугасыннан шундый балалар рухына муафыйк булган әсәрләр бер-бер артлы чыгып торачак вә һәркайсы рәсемле», – диелә. Шулай итеп, Г.Тукай әсәре яңа бер көтепханәгә нигез салуда, балалар әдәбиятын үстерүгә этәргеч бирүдә башлап җибәрүче була.

Китапның ахырына Г.Тукай: «Живописное обозрение» журналыннан икътибас ителеп, шигырьгә әйләндерелде», – дип куйган.

Текст китаптан алынды.

[1]*Дәфтәреңдә, бәлки, күптер яхшылык.* – Ислам дине буенча һәр кешенең ике иңендә ике фәрештә утыра, аларның берсе аның яхшы гамәлләрен, икенчесе начар гамәлләрен язып бара, үлгәннән соң шул дәфтәрләрне чагыштырып-үлчәп, йә оҗмахка, йә тәмугка җибәрергә хөкем чыгарыла.

«Йолдыз»ның 1911 елгы 21 июнь (699 нчы) санында «Яңа әсәрләр» рубрикасында «Габди» псевдонимы белән язучы Г.Ибраһимовның әсәр хакында бәяләмәсе басылып чыга.

«Русча журналдан алып эшләнгән бу әсәрнең мөндәриҗәсе зыянсыз; балалар, шаять, күңел табарлар... Җиңел, ачык, чат татарча һәм аңлаешлы язылган вә оста гына тәрҗемә дә кылынган бу әсәрнең бөтен фазыйләте телендә, тик телендә генәдер. Бу ягы белән караганда, балалар рәхәтләнеп укырлык кына түгел, ана телемезне гамәли белүләре ала-чала булган кайбер язучыларымыз да күз салсалар, байтак өлге алырлыктыр. Китапның азагында: «Русчадан алынып, шигырьгә әйләндерелде», – диелгән. Бу ялгыш. Безгә шигырь белән нәзымны аера белергә күптән вакыт инде. Бу әсәр шигырь түгел, бәлки нәзым вә мәнзумә генә».

Моңа каршы җавап итеп, «Йолдыз»ның 30 июнь (703 нче) санында Г.Тукай «Аз гына төзәтү» исемле мәкаләсен бастырып чыгара.

«...Минемчә, соңгы җөмләдән мөхтәрәм укучыларның «Мияубикә»не язучы нәзым белән шигырьне саташтыра икән дигән фикергә заһиб булу ихтималлары бар. Шуның өчен изах итәмен ки, «Мияубикә»не шагыйрь, саф поэзия, чын шигырьгә әйләндердем дип ышанганга күрә, «шигырьгә әйләндерелде» дип куйган.

...Габдинең югарыдагы сүзләре ялгыз бер интикадчының фикере генә дип тәлкыйн ителсен».

Әсәр турында «Сәгъде Вәкъкас» имзасы белән язган Сәгыйть Сүнчәләйнең дә «Шура»ның 1911 елгы 18 нче (15 сентябрь) санында бәяләмәсе басылып чыга. Әсәргә, гомумән, уңай бәя бирелә. Автор фикеренчә, «Мияубикә»нең җитешмәгән урыннары булса, «сәҗгы-рифмаларның (актык сүзләрнең) ямьле оеша алмаулары өстән-өстәнлектер».

172 бит.

**Ана илә Бала.** «Күңел җимешләре»ндә (1911) басылган. Текст шуннан алынды.

1912 елда педагог Хәлим Искәндәров әсәрне «Белем йорты» исемле дәреслек-хрестоматиягә дә урнаштырган.

«Күңел җимешләре» җыентыгы башындагы «Берничә сүз»дә каширләр: «Ана белән бала», «Мигъраҗ» шикелле бөтен җәһәтләреннән тәкъдир ителерлек шигырьләр язылалар... Ләкин «тормышның шагыйрь эзли торган» нурлы почмагы һаман табылмый кала», – дип язалар.

173 бит.

**Карга.** «Күңел җимешләре»ндә (1911) басылган. Текст шуннан алынды.

174 бит.

**«Сакмар суы» көенә.** «Күңел җимешләре»ндә (1911) басылган. Текст шуннан алынды.

Г.Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» (1913) мәкаләсендә «Сакмар суы» көенә» (1911) шигыре хакында: «Бервакыт үлем белән шаярып сөйләшкән Тукаев хәзер дөньяга куркып, рәнҗеп һәм җәберсенеп карый. Үзен ят вә мәхәббәтсез кебек хис итә... Аңа гүя әйберләрнең дә төсе үзгәргән булып күренә», – дип яза.

175 бит.

**Җил.** «Күңел җимешләре»ндә (1911) басылган. Текст шуннан алынды. Шигырьнең исеменнән соң «Пушкиннән» дип куелган.

Тукай бу әсәрне 1909 елда ук тәрҗемә иткән булырга тиеш, ләкин ул беренче тапкыр 1911 елда чыккан «Күңел җимешләре» җыентыгында гына басыла. Р.Башкуров Икетомлыкның 2 нче томына (1948) таянып эш иткән булырга кирәк, чөнки аның 410 нчы битендә әсәр «1909 елда язылган» дип күрсәтелгән.

Әсәр А.С.Пушкинның «Сказка о мертвой царевне и о семи богатырях» (1833) исемле әкиятендәге бер өзектән файдаланып язылган. Ул өзек түбәндәгечә:

Ветер, ветер! Ты могуч,
Ты гоняешь стаи туч,
Ты волнуешь сине море,
Всюду веешь на просторе,
Не боишься никого,
Кроме Бога одного.

176 бит.

**Эшкә өндәү.** «Күңел жимешләре»ндә (1911) басылган. Текст шуннан алынды.

Бу шигырь шул чордагы русча уку китапларында бик күп басылып килгән Я.Гротның «Труд» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

Дети! Надо трудиться:
Бог нас создал для труда.
Ах, от праздности родится
Много горя и стыда!
В жизни лучшие мгновенья
Покупаются трудом;
Сладкий час отдохновенья
Лишь усталому знаком.
Цвет здоровья возвышается,
Прелесть всех житейских благ;
Тот полный его вкушает,
Кто проводит день в трудах.
Не в богатстве счастье наше;
Но кому же нищета
И ее лохмотья краше,
Чем достаток, плод труда?
У прилежного веселье
Украшает дом и стол;
Скуку лишь дарит безделье;
Праздный голоден и – гол.
Тот, кто хочет доброй славы,
Должен хлеб свой в поте есть:
Не за игры и забавы
Достается людям честь.
Без усилий, без терпенья
Не бывал никто велик;
Труд – источник возвышенья:
Счастлив, кто к нему привык!
Дети, дети, не лениться!
Труд всегда приносит плод:
Будешь смолоду трудиться –
Встретишь старость без забот.

8 строфадан торган шигырьне Г.Тукай 3 строфага калдырып иҗади тәрҗемә иткән.

«Күңел җимешләре»ндә «Эшкә өндәү» шигыре исеме астында «Плещеевтән» дип басылуы хата булса кирәк.

177 бит.

**Иртә.** «Күңел җимешләре»ндә (1911) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырьнең баштагы 3 строфасы «Бәянелхак» газетасы тарафыннан чыгарылган «Мәгълүмат» (1908) исемле игъланрекламалар җыентыгында «Караван» чәй фирмасы рекламасы рәвешендә имзасыз басылган «Тәүлек» дигән әсәрнең (бу

шигырьне шушы басманың 1 нче томыннан карагыз) баштагы өлешен тәшкил итә. Шуңа соңгы дүртьюллык кушылып, «Күңел җимешләре»ndә (1911) мөстәкыйль шигырь төсендә басылган.

Р.Башкуров Тукайның «Иртә» шигыре А.С.Пушкинның «Вишня» исеме белән басылган әсәрнең «Утро» дигән өлешеннән файдаланып язылганлыгын ассызыклый. Менә ул шигырьнең тексты:

**Утро**

Румяной зарею
Покрылся восток.
В селе, за рекою,
Потух огонек,
Росой окропились
Цветы на полях,
Стада пробудились
На мягких лугах.
Седые туманы
Плывут к облакам,
Гусей караваны
Несутся к лугам,
Проснулися люди,
Спешат на поля,
Явилося солнце,
Ликует земля!

178 бит.

***** («И төрек, иң әүвәл үк...»).** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 21 нче (20 апрель) санының тышлыгында рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Журналның шул саны тышлыгының беренче битендә борын бик озын кылыч булып салынып төшкән, башына фәс кигән бер төрек сурәте бирелгән һәм бер ягына «Тасвире әфкяр мөхәррире» дип язылган.

180 бит.

**Шигърият һәм нәсер.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 22 нче (1 май) санында «Сөенче Алаев» имзасы белән басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

«Сөенче Алаев» имзасын Тукай бүтән кулланмый. Имзадан ук күренгәнчә, Тукай бу шигырен шагыйрь С.Сүнчәләйгә (1889–1937) пародия итеп язган. Чыннан да, С.Сүнчәләй иҗатының башлангыч чорында тормышның чәчәге һәм сандугачы хакында җырларга ярата. Тукай бу шигыре белән яшь шагыйрьгә (һәм бер аңа гына да түгел!): менә тормышның чәчәкле-сандугачлы ягы (строфаның баштагы ике юлы), менә аның чәнечкеле ягы – нәсере (тормыш прозасы) дип күрсәтеп бирә.

[1]*Ишми* – шушы томдагы «Кайда? Кем?» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз.

[2]*Хаҗитарханда Камил булган агач* – бу урында Әстерхан шәһәрендә дә чыгыш ясаган Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның (1907 елдан ул җырчы булып китә) үз репертуарына карата талымсызлыгы тәнкыйтьләнә.

[3]*Сәйяр «артистлар» да корсак кайрыйлар.* – «Сәйяр» труппасы артистлары ачлы-туклы ил гизеп, мәдәният нуры тараталар.

[4]*...Бетмәде шул «Мөхбире» дә, «кых, тефү!»*

*Һәм Рәмиевнең шигырьдә шау-шуы.* «Мөхбир» – «Казан мөхбире» газетасы; аның яшьләргә тупас «Без»е белән кадарга тырышуы Тукайның теңкәсенә тигән. Монда икеюллыкның бер юлында – «Мөхбир», икенчесендә С.Рәмиев искә алынуы аңлашыла: вакытында С.Рәмиев – «Без»не оештыручы һәм анда иң күп язучы. Икенче яктан, шигырь үлчәме өлкәсендәге эзләнүләрендә С.Рәмиев субъектив, формаль карашларга да (мәсәлән, Әстерханда 1907–1914 еллар арасында чыккан «Идел» газетасының редакциягә килгән шигырьләргә консультацияләрендә, анализларында) юл куйды. С.Сүнчәләй шигырьләренә дә тикшерү уткәрде. Әлбәттә, С.Рәмиев күпчелек очракта дөрес, квалификацияле анализ ясый. Әмма С.Сүнчәләй, күрәсең, Тукайга үзенең ризасызлыгы хакында язган. Тукай аңа: «С.Р.нең вәзеннәр тугърысында артык лаф сугуына исегез китмәсен», – дип киңәш бирә (1911 ел, 1 гыйнвар хаты).

182 бит.

***** («Приемныйның ишекләре...»).** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 23 нче (4 июнь) санында тышлыкта карикатура асты итеп урнаштырылган. (Рәсемдә пыр тузып ике этәч сугыша.)

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Башта бу икеюллык:

Приемныйның, ай, ишеге тар ләхеттән тар икән:
Әчтерханда «Борһан», «Идел» – ике этәч бар икән,–

рәвешендә «Авыл җырлары»ның «Беренче көлтә»сендә китерелә. «Яшен ташлары»нда (1) барлык «көлтәләр»не бергә туплап, бер баш астында биргәндә, Тукай бу икеюллыкны төшереп калдыра.

184 бит.

**«Шура» шигырьләреннән.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 24 нче (15 июнь) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

«Ялт-йолт»та беренче итеп баш мәкалә урынына «Шүрәле» имзасы белән «Кечкенә сәяхәт» урнаштырылган, аның артыннан ук, имза куймыйча гына, шушы шигырь бирелгән. Гадәттә, Тукай әсәрләре, ачык имза беләнме ул, псевдоним яки имзасыз гынамы, журналның башында ук бер-бер артлы урнаштырылуын искә алсак, шигырьнең баш мәкалә артыннан ук китерелүе һәм имзасыз булуы Тукай авторлыгы файдасына сөйли.

186 бит.

**Иһтида.** «Шура»ның 1911 елгы 12 нче (15 июнь) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «1911 сәнә, 13 май» дип куелган. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Шура»дан алынды.

188 бит.

***** («Уңга да мин әйләнәм...»).** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 23 нче (4 июнь) санында рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Беренче тапкыр икенче Дүрттомлыкның 2 нче томына (1976) кертелгән.

«Ялт-йолт»ның 8 нче битендә чалмалы бер җил тегермәне ясалган. Шигырьдә әләк белән җәдид мәктәпләрен яндырып, яптырып, мөгаллимнәрен сөргенгә җибәрткәндә, иске карашлы муллаларның ике яклы роль уйнауларына ишарә ителә.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

190 бит.

**Яшен яшьнәгәндә.** Г.Тукай кулъязмалары арасыннан табылып, беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томында (1930) басылган. Шигырьнең оригиналы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсе архивында Г.Тукай фондында саклана (9 ф., 1 тасв., 1 эш, 1 б.). «Гъ.Т. 26 июнь, 11 сәнә» дип куелган.

Текст кулъязмадан алынды.

Бу шигырь «Ялт-йолт» журналының рәсми редакторы Әхмәт Урманчиевның өендә сакланган Г.Тукай кулъязмалары арасыннан чыккан. Кулъязмада шигырьнең исеме янында ук «Исерек вакытымда язылган» дигән искәрмә дә бар. Ф.Сәйфи-Казанлы аны «Исерек чагында язылган» дип укыган һәм, тексттан аерып алып, томның аңлатмалар һәм искәрмәләр өлешенә урнаштырасы иткән. Аннан соңгы басмаларда исә бу искәрмә турында бер сүз дә әйтелми. Факсимилесен биргәндә дә ул сүзләрне (Г.Тукайның үз искәрмәсен!) төшереп калдыралар. 1985 елгы томда гына факсимиле, ниһаять, тулысы белән бирелә, ә басма тексты эчендә исә ул китерелми. Күрәсең, бу сүзләр Г.Тукай образына – сөекле шагыйребез образына тап төшерү дип уйлангандыр.

191 бит.

***** («Һәзад-дөнья әкалле...»).** Биштомлыкның 2 нче томында (1985) «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 23 нче (4 июнь) санында рәсем-карикатура асты итеп басылган дип әйтелә, әмма бу санда әлеге дүртьюллык юк.

Текст Биштомлыктан алынды.

192 бит.

**Читен хәл.** «Шура»ның 1911 елгы 17 нче (1 сентябрь) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «14 июль, 1911 сәнә» дип куелган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

194 бит.

**Гөнаһ.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 25 нче (1 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырьнең исеменнән соң рус хәрефләре белән «Бальмонтътан» дип куелган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

Әсәр К.Д.Бальмонтның (1867–1942) «Грех» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

Кто создал безумное слово,
О, слово постыдное: – Грех!
Чуть смоешь пятно, вот оно означается снова,
Мешает, меняет, глушит и уродует смех.
Как жалкий воришка,
Запрячется в спальню, в углу притаится как мышь
И смотрит – меж двух не случится ли в ласках излишка, –
Скривится, чу шорох: «Довольно», «Не более», «Лишь».
Лишь то, а не это. Лишь тот, а не с этой, а с тою.
Вот только. Вот столько. Шипенье, шуршанье змеи.
О, дьявол убогий, кропишь ты святою водою,
Но где осветил ты поганые брызги свои?
Прочь! Прочь, говорю я!
Здесь грешен лишь тот, кто осмелится вымолвить: «Грех».
О, свежесть ручьев! О, смеющийся звук поцелуя!
Весна и разливы! Счастливый ликующий смех!

Тукай К.Д.Бальмонтның шигырен турыдан-туры күчереп алмый, ул аңарга үзенең мәгънәсен сала. Ә инде соңгы юллар К.Д.Бальмонт шигыренең идея-сәнгать эчтәлегенә бөтенләй туры килми.

195 бит.

**Авыл җырлары (Бишенче көлтә).** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 25 нче (1 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Тукайның үзе исән чакта чыккан җыентыкларында бу тәртиптә бирелмәгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Шигырь вакытлы матбугаттагы тискәре күренешләрне, көнкүреш, мәдәният өлкәсендәге җитешсезлекләрне, бигрәк тә андагы иҗтимагый зарарлы якларны тәнкыйть итүгә багышланган.

[1]*Мәкәрҗәгә баралар тәтәйләрнең ирләре* – Мәкәрҗә ярминкәсе Түбән Новгород янәшәсендә, Иделнең сулъяк ярында, Макарьев монастыре янында урнашкан. Исеме татарчалаштырылган. Ул XVI гасыр урталарыннан 1816 елга кадәр ел саен июль-август айларында уздырыла. 1817 елдан Түбән Новгород шәһәренә күчерелә, халык телендә элеккеге исеме саклана. Анда бөтен Россия шәһәрләреннән һәм чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр үз товарлары белән сату итәләр. Мәкәрҗә ярминкәсе Октябрьдән соң да берникадәр вакыт эшли һәм 1929 елда бөтенләй туктатыла.

[2]*Бакыр бабай бакчасы* – Казанда хәзерге Карл Маркс һәм Пушкин урамнары чатындагы бакча, хәзер ул урында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры. Бу бакчада рус шагыйре Г.Р.Державинга (1743–1816) куелган бакыр һәйкәл булган. Шуңа күрә татарлар бу бакчаны «Бакыр бабай бакчасы» дип йөрткәннәр.

Ирләре ярминкәгә киткәч, бай хатыннары шул бакчага күңел ачарга йөргәннәр. Мондый хәлләр Г.Камалның «Уйнаш» комедиясендә чагылыш тапкан. Тукайның «Уйнаш»тагы яман күз» дигәне шуңа ишарә.

[3]*Ботански бакча* – Казанда Кабан күле буена урнашкан (хәзер Һади Такташ урамында) Ботаника бакчасы (Ботанический сад).

[4]*Кушмый ишан* – Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев («Кайда? Кем?» шигыренә бирелгән искәрмәне карагыз).

«Сакалына хөрмәт беткәч, милләт сата ачудан», – дип, Тукай Ишми ишанның татар халкы арасындагы алдынгы карашлы кешеләр өстеннән донослар ясавына ишарә итә.

[5]*Бәдәлчеләр-мәккәчеләр* – татар байларыннан кайберләре, хаҗ кылырга Мәккә шәһәренә үзләре бара алмасалар, акча биреп, үзләре өчен башка берәүне җибәргәннәр. Бу акчаны «бәдәл» дип, Мәккәгә кеше өчен барып хаҗ кылучыны «бәдәлче» дип атаганнар.

[6]*Баш хәерче Морадлары* – Морад-Морадelмәкки дигән кеше – шул бәдәлчеләрнең иң шомарганнарыннан берсе.

[7]*Эшсез картка туй иттек* – 1910 елда Мөхәммәдьяр Солтановның мөфти булып торуына 25 ел тулуны билгеләп үтелә. Монда шуңа ишарә.

[8]*Камил мәхдүм* – К.Мотыйгый (1883–1941), җырчы буларак, үз репертуарына карата талымсызлыгына ишарә.

Соңыннан Тукай шушы биш көлтәне берләштереп, кайберләрен төшереп, яңаларын өстәп һәм редакцияләп, «Яшен ташлары» (1) исемле җыентыгында «Авыл җырлары» исеме белән бастырып чыгара. Бу вариант түбәндә китерелә:

**Авыл җырлары**

Алтын йөзек фирисә, арасыннан җил исә;
Татар бае хаҗга киткән, шартлый мәллә югыйсә?

Җанкай-җанаш, пумала баш, чыкма урамга җаланбаш;
Җөрмә, шәкерт, кәләпүшсез, урыс булдың, ярамас.

Башыңдагы чабатаңның сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды Бәдигъ мәзин күркәсе.

Безнең Казанның кызлары киенмәсә дә матур;
Татар башы чокыр-чакыр, себермәсәң дә такыр.

Актыр пәке саплары, күктер пәке саплары;
Алтмыш биштә, җитмеш биштә кызның матур чаклары.

Үсә, пешә, тәмле була алмагачның алмасы;
Сузсаң, Мәскәүгә җитәрлек ишаннарның чалмасы.

Атланмайны бик җаратам: әнкәй атлый шул аны;
Татар хатыны азмыйдыр: чапан саклый шул аны.

Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена;
Унөч яшьлек кызга тисәң, хаҗның әҗре җуела.

Алтын балдак бармакта, әйләнәдер салмакка;
Ончы хаҗи хәлен сөйлим, – әйдә барыйк аулакка.

Кушмый ишан капкасы, нарат икән тактасы;
Нарат булмый нәрсә булсын, бар да донос акчасы.

Безнең урам – таш урам, ташу ага басудан;
Сакалына хөрмәт беткәч, милләт сата ачудан.

«Ай туган»да тусаңчы, айдай нурлы булсаңчы;
Яшьләр йөзен кызартканчы, «каралганчы» үлсәңче!

Бер ишан хәзрәт симерттем, күркә, тавык ашатып;
Сагынсам, корсагын карыйм, чүмәләгә охшатып.

Ала карганың баласы әрсезләнә – тук була;
Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит – мәчет Токиода.

Җомры тояк тайларда, матур кызлар байларда;
«Әхбар» тәэмин иткән байлар җөри икән кайларда?

Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны.

Ак Иделнең аръягында атлар йөри чабында;
«Чүкеч» сабын кимреп җылый «Яшен» суккан чагында.

Хәтфә калфак киштәдә, эшләнүе бистәдә;
Морад кебек теләнчене күралмассың төштә дә.

Җөгрәлмәдем, җитәлмәдем, тоталмадым үрдәкне;
Иран халкы онытмыйдыр шаһтан күргән «хөрмәт»не.

Җанкәй, сачең бер көлтә, җиккән атны өркетә;
Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә?

Каф тавы артында үсә самарау кош баласы;
Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфөнүн саласы.

Эскерипкәм тарый-тарый, тарый булса да ярый;
Мөштәриләр юк, ди, – инде игълан булса да ярый.

Мөлхимәләр балдагы төрек халкын алдады;
Алдаласа алдаласын, үкенечкә калмады.

Мендем тауга, тоттым карга, саескан түгел, чәүкә;
Җыен җегет арасында нишләп йөри ирдәүкә?

Сәгатьләр келт-келт итәдер, төн уртасы җитәдер;
Йокласа да курка, мескин, – исрек ирен көтәдер.

Арыслан киек сикермәс, каршысында тау булса;
Байбәтчәгә нәрсә кайгы – «шамшамиткә» сау булса.

**(Озын көйгә дә бер җыру)**

– Алма аша, җаный, ай, алма аша.
– Алма ашасам, тешем камаша.
Казан бае, махсус номер алып,
Наташалар белән маташа.

Тукайның «Авыл җырлары»на ияреп, охшатып, байтак авторлар тарафыннан күп җырлар языла. Алар «Ялт-йолт»та да, бүтән көлке журналларда да, газета битләрендә дә очрый. «Акмулла» (Троицк, 1911–1916) журналының, мәсәлән, 1915 елгы 48, 49 нчы саннарында «Җырчы» псевдонимы белән басылган «Авыл җырлары»на турыдан-туры «Тукайга тәкълид» дип куелган һ.б.

196 бит.

**Гакыллылар фәлсәфәсе.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 26 нчы (15 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

197 бит.

**Кадер кич.** «Вакыт»ның 1911 елгы 6 сентябрь (839 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, аннары «Балалар күңеле»нең 2 нче басмасына (1911), «Җан азыклары»на (1912) кертелгән.

Текст «Җан азыклары»ннан алынды.

Шигырьнең язылу тарихы турында күренекле композитор Мансур Мозаффаров түбәндәгечә яза: «Бервакыт әнием Тукайдан: «Менә кадер киче җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы синдә, Габдулла?» – дип сорады. Тукай берничә көннән безгә «Бу кадер кич елда бер кич...» дип башлана торган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка китерде. Бу открытканы мин 1934–1935 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына тапшырдым».

Дөнья әдәбиятында Гете, Һәйне һ.б. шагыйрьләр үз иҗатларында Коръән аятьләренә (ә алар борынгы гарәп телендә шигырь белән язылганнар, шуңа күрә «аять»не руслар «стих» дип йөртәләр) мөрәҗәгать иткән кебек, бөек рус шагыйрьләре Жуковский, Пушкин, Лермонтов һ.б.лар да аңа мөрәҗәгать итми калмаганнар. Бу ике шагыйрьнең «Подражания Корану» дип исемләнгән шигырь бәйләмнәре бар. Пушкин, мәсәлән, 9 шигырьдән торган шигырь бәйләмендә генә дә Коръәннең 15 кә якын аятен ирекле рәвештә шигырьгә сала. «...многие нравственные истины изложены в Коране сильным и поэтическим образом», – ди Пушкин мөселманнарның изге китабына карата. Коръәннең 5, 21, 24 һәм 31 нче сүрәләрендәге аерым аятьләргә нәзыйрәсенең 1 нче строфасына (Земля недвижна; неба своды, Творец, поддержаны тобой, Да не падут на сушь и воды И не подавят нас с собой) Пушкин мондый искәрмә бирә: «Плохая физика; но зато какая смелая поэзия!»

Бу шагыйрьләр кебек, Тукай да үз иҗатында күп тапкырлар Коръәнгә мөрәҗәгать итте. «Кадер кич» шигыре – Коръәндәге «Кадер» дип аталган 97 нче сүрә һәм бүтән сүрәләрдә дә кабатланган аятьләр җыелмасының татарча шигъри яңгырашыннан гыйбарәт. Шунысы кызык: Пушкин кебек үк, Тукай да аять кысасында гына калмый:

Ул мәлаикләр җыярлар тол, ятимнәр яшьләрен,
Барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын, –

дип, әсәргә социаль-гуманистик яңгыраш бирә.

198 бит.

**Рамазан гаетендә Иблиснең шәйтаннарына хитабы.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 27 нче (11 сентябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган һәм «Иблиснең гайде фитыр тантанасы» дип исемләнгән. Җәяләр эчендә: «Үзе гармун уйный», төшермәдә: «Иблис тантанасы рәсеме ахыргы биттән каралсын», – диелгән. Журналның ахыргы битендә иблис тантанасының рәсеме бирелгән: бер көтү мөгезле җеннәр бииләр, берсе гармунда уйный.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

Тукай бу шигырендә кайбер кешеләрнең бик диндар, тәкъва күренеп тә, азып-тузып йөрүләренә шәйтан гаепле дип, үзләренең гаебен «шәйтан»га сылтауларыннан көлә.

[1]*Иблис* – ислам динендә Алла кушуы буенча Адәм пәйгамбәргә табынырга теләмәгәне өчен ләгънәтләнеп, күктән сөрелгән фәрештә; ул кешеләрне аздырып кына йөри, имеш.

[2]*«Көндез сәхәр» ясады* – Ф.Әмирханның «Көндезгә сәхәр, яки Рузасызлар (Замана хикәячеге)» дигән әсәре бар. Анда татар яшьләренең, уразадан качу өчен, кемнең дә булса квартирасына җыелышып, картлардан яшереп, көпә-көндез «сәхәр ашаулары» – заманында бик таралып, телгә кергән күренеш тасвирлана. «Җан азыклары»нда «Көндез сәхәр» сүзләрен тырнаклар эченә алуы Тукайның Әмирхан әсәренә дә ишарәләвен күрсәтә.

199 бит.

**Сайфия.** «Шура»ның 1911 елгы 18 нче (15 сентябрь) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Тукай бу шигырьгә «Иделдә сәяхәтем хатирәсе» дип куя. Шигырь Тукайның 1911 елның маенда пароход белән Әстерханга бару тәэсире белән язылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр «Гажур» басмасына (1926) кертелгән.

Текст «Шура»дан алынды.

200 бит.

**Поезд барган көйгә.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 28 нче (12 октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

202 бит.

**Тәмсил (Италия-Төркия сугышы мөнәсәбәтилә).** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 28 нче (12 октябрь) санында имзасыз басылган. «Җан азыклары»нда шигырьнең исеме астына җәяләр эчендә «Италия-Төркия сугышы мөнәсәбәтилә» дип куелган. «Ялт-йолт»тагы 6 нчы юлдагы «тотканын» сүзе «Җан азыклары»нда (1912) «тапканын» дип төзәтелгән.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

XX гасыр башында Төркиянең Африкадагы биләмәләренә кызыккан Италия 1911 елның 28 сентябрендә Төркиягә ультиматум җибәрә, Италия халкы мәнфәгатен яклау сылтавы белән, Төркия колонияләре Триполи һәм Киренаиканы оккупацияләүгә тотынуын белдерә. Октябрь башында Италия гаскәрләре яр буе шәһәрләрен бик тиз басып алсалар да, гарәп халкының һәм Төркия гаскәрләренең аяусыз каршылыгына очрап, туктап калырга мәҗбүр булалар. Союзниклары Германия һәм Австро-Венгриянең өстереп-кыздырып торулары да ярдәм итми. Шул көннәрдәге матбугатта бу хакта бик күп материаллар күренә. Тукай бу шигырен шушы вакыйгалар эзеннән язган. Шагыйрь шигырь эчтәлегендә сугышка этәргән төп көчләрнең берсен – Германияне – Арыслан, иярчене Австро-Венгрияне – Юлбарыс, Италияне – Мәче образында алып, алар арасындагы намуссыз, гаделсез һәм икейөзле мөнәсәбәтләрне калкытып куеп, колониаль сәясәтне тәнкыйть итә.

203 бит.

**Толстой фикере.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 28 нче (12 октябрь) санында имзасыз басылган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

Шигырьдә Тукайның хатын-кызга карата толстойчылык карашларын уртаклашуы күзгә ташлана. (Толстой хатын-кызларны ирләрнең эшчәнлегенә зыян китерә дип уйлаган.) Шул ук вакытта «Толстой фикере»нә үзеннән кушып язган «Үземнән гыйлавә»не җиңелчә шаяру, юмор белән тәмамлый.

Ә Тукайның хатын-кызга карата толстойчылыгы милләтенә олы мәхәббәт, аның мәдәниятен, әдәбиятын үстерү һәм аңа фидакарьләрчә хезмәт итү турындагы уй-фикерләре белән тыгыз бәйләнгән.

204 бит.

**Тәүбә вә истигъфар.** «Ялт-йолт»ның 1911 елгы 28 нче (12 октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Тукай бу шигырьне «Пушкиннән үзгәртелә» дип куйган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

Әсәр А.С.Пушкинның «Десятая заповедь» (1821) исемле шигыреннән (сюжеты – «Библия»дән) файдаланып язылган. Ул түбәндәгечә:

Добра чужого не желать
Ты, Боже, мне повелеваешь;
Но меру сил моих ты знаешь –
Мне ль нежным чувством управлять?
Обидеть друга не желаю,
И не хочу его села,

Не нужно мне его вола,
На все спокойно я взираю:
Ни дом его, ни скот, ни раб,
Не лестна мне вся благостыня,
Но ежели его рабыня
Прелестна... Господи! Я слаб!
И ежели его подруга
Мила, как ангел во плоти, –
О Боже праведный! Прости
Мне зависть ко блаженству друга.
Кто сердцем мог повелевать?
Кто раб усилий бесполезных?
Как можно не любить любезных?
Как райских благ не пожелать?
Смотрю, томлюся и вздыхаю,
Но строгий долг умею чтить,
Страшусь желаньям сердца льстить,
Молчу... и втайне я страдаю.

[1]*Рауза* – ислам динендә җәннәттәге гөл бакчасы исеме.
[2]*Зөләйха* – XII–XIII гасыр шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» («Йосыф китабы») поэмасы герое.
[3]*Ләйлә* – XII гасыр азәрбайҗан шагыйре Низами Ганҗәвинең «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасы герое.
[4]*Сигез оҗмах капкасын* – ислам дине буенча җәннәтнең (оҗмахның) сигез яктан сигез капкасы бар.

205 бит.

**Көзге җилләр.** «Йолдыз»ның 1911 елгы 18 ноябрь (758 нче ) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «1911 сәнә, 13 ноябрь» дип куелган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

1910–1911 елларда Урта Иделдәге ачлык фаҗигаләре тәэсире белән язылган.

[1]*Газраил* – ислам динендә җан алучы фәрештә.
[2]*Ибраһим, Исмәгыйль* – ислам динендә аталы-уллы пәйгамбәрләр; пәйгамбәрләр арасында Мөхәммәдтән кала иң изгеләре.

Тукай эпиграф итеп рус шагыйре А.Н.Майковның «Из Аполлодора гностики» шигыреннән өзек китерә:

Не говори, что нет спасенья,
Что ты в печалях изнемог:
Чем ночь темней, тем ярче звезды,
Чем глубже скорбь, тем ближе Бог...

Кәрим Сәгыйть «Яшен ташлары» җыентыгында басылган бу шигырь белән танышкач, Тукайга: «“Көзге җилләр” өчен мин сине адәм дип кенә түгел, Ходайның иң сөекле адәме, дип тәкъдир итәм», – дип яза.

206 бит.

**Золым.** Беренче тапкыр «Гажур» басмасына (1926) кертелгән. Җыентыкны төзүче Ф.Бурнаш «Бер җирдә дә басылмаган» дигән искәрмә биргән. Текст астына «1911» датасы куелган. Текст шул җыентыктан алынды.

1938 елгы «Сайланма әсәрләр»дә китерелгән факсимилие буенча 2 нче һәм 10 нчы мисрагълар *«Тәзкирәңә мөслим дигән игълан таккан»* һәм *«Аһ-ваһыңнан һичбер минут бушанмыйсың»* дип укылырга тиеш.

207 бит.

**Кечкенә музыкант.** Тукай кульязмалары арасыннан табылып, Октябрьдән соң гына басыла башлаган. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Өчтомлыкка текст кульязма буенча урнаштырылган. Бу шигырьгә искәрмәсендә Ф.Сәйфи-Казанлы болай дип яза: «Кечкенә музыкант» шигыре дә Әхмәт Урманчиев өендә сакланган кульязмалар арасыннан чыкты. Бусының тарихы да куелмаган һәм имзасы да юк. Карандаш каләм белән генә язылган. Шигырь язылып бетмәгәнме, әллә бетеп тә соңгы кисәге югалганмы? Бу шигырьнең Тукай шигыре булуында шик юк. Чөнки шигырьнең уртасында. «“Килә аннан, бер тыңнасаң, мәче таушы. Бер тыңнасаң – чинау килә, бер тыңнасаң – майламаган арба тәгәрмәче таушы” шигыре икенче урында «Шүрәле» псевдонимы белән «Граммофонда татар җырлары» дип басылган. Шуңа күрә моның Тукай шигыре булуында икеләнерлек бер урын да юк, шуның өстенә кульязмасы – бөтенләй Тукай рәсме хаты. Шуны да әйтергә кирәк, бу кульязма карага язылган хәленчә, бер дә эшләнмәгән, шуңа күрә кайбер мисрагъларында зур кытыршылык бар. Кайсы елны язылуы да куелмаган».

208 бит.

**Төрекчәдән («Эзләдем, филлаһ...»).** «Яшен ташлары»нда (2) басылган. Текст шуннан алынды.

**1912**

209 бит.

**Сабитнең укырга өйрәнүе.** «Татар әлифбасы» һәм аңа кушымта «Бүләк»тә басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Текст беренче тапкыр беренче Дүрттомлыкның 2 нче томында (1955) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*«Бүләк» атлы әлифба алып кайтты...* – И.Н.Харитонов китабына кушымта «Бүләк» дип исемләнгән, сатып алучыга бушлай бирелгән.

Типография хуҗасы И.Н.Харитонов (1869–1954) татар язуы өчен махсус хәрефләр койдыра һәм, шуны пропагандалау максатын күздә тотып, «Татар әлифбасы» дигән рәсемле китап чыгарырга карар итә. Тукайның бу шигыре китапка кушымта итеп чыгарылган «Бүләк» дигән китапчыгында басылып чыга.

211 бит.

**Гыйбрәт вә нәсыйхәт.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Шүрәле» имзасы белән чыккан «Казанга кайтыш» дигән мәкаләнең ахырында басылган. Аерым шигырь буларак, беренче тапкыр «Гажур» басмасына (1926) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

212 бит.

**Авыл мәдрәсәсе.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Казанга кайтыш» исемле мәкалә эчендә басылган. Текст эчендә Г.Тукай үзе «Бәет» дип куйган, аннары, ахыргы дүрт юл өстәлеп, «Җан азыклары»на (1912) «Авыл мәдрәсәсе» исеме белән мөстәкыйль шигырь итеп урнаштырылган.

[1]*Әфтияк* – дөресе – Һәфтияк, Коръәннең җидедән бер өлеше.

«Ялт-йолт»тагы *«Кыш буе шул мөһмәлятне...»,*

«Җан азыклары»нда *«Кыш көне шул мөһмәлятне...»,*

«Ялт-йолт»тагы *«Яз көне туктый укудан һәр күсәк угълы күсәк...»,*

«Җан азыклары»нда *«Яз көне туктый күшәүдән...»* дип үзгәртелгән.

Текст «Җан азыклары»ннан алынды.

213 бит.

**Бәет.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Казанга кайтыш» исемле мәкалә эчендә басылган. Мәкаләсенең бу урынында Тукай авыллардагы ачлык хәлләре турында сөйли. Аерым шигырь буларак, Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

214 бит.

***** («Читтәге бик күп өяздә...»).** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Казанга кайтыш» исемле мәкалә эчендә басылган. Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) «Мәктәп һәм школа» исеме белән кертелгән. Шигырь Икетомлыкның 1 нче томында да (1943), беренче Дүрттомлыкның 2 нче томында да (1955) искәрмәдә «Авыл мәдрәсәсе» шигыренең «Ялт-йолт»та басылган вариантының соңгы өлеше дип ялгыш тәкъдим ителә. Болар – бер-берсенә бәйләнешле икесе ике әсәр.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

215 бит.

***** («Җырласаң да, жегет...»).** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Казанга кайтыш» исемле мәкалә эчендә басылган. Аерым шигырь буларак беренче тапкыр Икетомлыкның 1 нче томына (1943) «Җыр» исеме белән кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

216 бит.

***** («Теләрсәң кемне сүк...»).** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Казанга кайтыш» исемле мәкалә эчендә басылган. Бу икеюллыкны Тукай «Минем Шүрәлинский девизым» дип тәкъдим итә. Аерым шигырь буларак беренче тапкыр Биштомлыкның 2 нче томына (1985) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

217 бит.

**Яз галәмәтләре.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 36 нчы (31 март) санында тышлыкта, «Городской ломбард» дигән рәсем асты итеп, имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

Рәсемдә ломбардның ишегалды сурәтләнгән, халык кайсы капчыгын, кайсы төенчеген, кайсы пәлтәсен тотып шунда килә.

219 бит.

**Хөрмәтле Хөсәен ядкяре.** «Йолдыз»ның 1912 елгы 10 апрель (817 нче) һәм «Ялт-йолт»ның шул ук елгы 37 нче (15 апрель) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Ялт-йолт»та «1912 сәнә, 7 апрель» дип куелган.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

Шигырь инкыйлабый хәрәкәт эшлеклесе, публицист, Тукайның якын дусты Хөсәен Ямашев (1882–1912, 13 март) үлү мөнәсәбәте белән язылган. Тукай монда халкы һәм туган Ватанына тугрылыклы хезмәт итеп, шул юлда җанын фида кылган якты шәхес образын тудыра, аның татар халкына, милләтенә багышлаган эшчәнлегенә соклана.

«Ялт-йолт»ның шул ук елгы 39 нчы (1 июнь) санында түбәндәге төзәтү урнаштырылган:

«Яңлыш уйланмасын.

Мәгълүмдер ки, 37 нче номер «Ялт-йолт»тагы «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» сәрләүхәле шигырь мәзкүр журналга басылудан мөкаддәм «Йолдыз» гәзитәсендә дәрҗ ителгән иде.

Шул вакыт «Йолдыз» идарәсе шигырьдәге «әүлиялар» дигән сүзгә махсус галәмәт куеп, гәзитәнең итәгенә: «Дустлар» мәгънәсендә аңларга тиеш», – дигән бер шәрех төшерде. Шигыремнең кичекмиерәк басылуы матлуб

булганга, «шәрех»не гәзитә басылыр чакта күргән булсам да, идарәчә «әһәмиятле» шәрехне төшертә алмаячагымны белеп, шул көе табгы иттердем. Менә шул шигырьне «Ялт-йолт» журналы да, «Йолдыз»дан кисеп алып, гайнән үзенә күчергән. Күчергән, ләкин баягы кирәкмәгән шәрехне төшереп калдырырга хәтереннән чыккан. Шунлыктан мин ушбу сәтырлар белән игълан итәргә мәҗбүрмен ки, шигыремдәге «әүлиялар» сүзе үзенең чын дөрес мәгънәсе белән «изгеләр» мәгънәсендә генә аңланырга тиеш.

Теге «шәрех»нең без «Ялт-йолт»ка чит идарәдән җиһаз күчергәндә ияреп килгән үрмәкүч оясы дип кенә каралуын барча укучыларымыздан риҗа вә тәмәнни идәрем.
*Габдулла Тукаев*
26 апрель, 1912. Петербург».

220 бит.

**Янә бер хатирәм.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 37 нче (15 апрель) санында «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» артыннан «Гъ.Т.» имзасы белән басылган. Шигырьнең икенче юлы «Ялт-йолт»та «Бүлмәмә...», «Җан азыклары» җыентыгында «Ханәмә...» дип башлана.

Текст «Җан азыклары»ннан (1912) алынды.

221 бит.

**Шыер.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 37 нче (15 апрель) санында «Айнюк Самакай малае» дигән имза белән басылган. Бу имзасын Тукай шунда гына куллана. Аска «1912» дип куелган. Шагыйрьнең үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Муса Җәлил редакторлыгында чыккан «Сайланма әсәрләр»гә (Казан: Татгосиздат, 1938) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

1912 елда Х.Ямашев үлгәч, Казандагы бер төркем иптәшләре, аңа багышлап, «Йолдыз» газетасына кушымта бит чыгаралар. Шул кушымтага басар өчен, журналист, язучы һәм педагог Фәхрелислам Агиев (1887–1938) Лермонтовның «Ангел» («Фәрештә») исемле шигыренә охшатып бер шигырь язып җибәрә. Шигырь «мишәрчәрәк» килеп чыкканга, Тукай аңа пародия рәвешендә шушы шигырен яза.

[1]*Тимай бай булсаң да...* – «Тимай бай» дип элекке Сембер губернасындагы Гурьевка авылында мануфактура фабрикасы хуҗасы, эшкуар Тимербулат Акчуринны атаганнар (халык, Тимербулат исемен кыскартып, Тимай дип кенә йөрткән). Патша хөкүмәте, Тимай байның җитештерүне оста оештыру сыйфатын бәяләп, аны «За усердие» медале белән бүләкләгән.

XIX гасырның соңгы чирегендә аның тарафыннан «Тимербулат Акчуринның сәүдә-промышленность ширкәте» оештырыла. Ширкәт берничә фабриканы берләштерә. Алар Гурьевка исемле авылда эшләгәннәр.

Тимай бай 1826 елда Хорамша Акчурин гаиләсендә туган, 1906 елда 80 яшендә үлгән, кабере – Гурьевка авылында.

[2]*Сахабалар: Али, Усман, Үмәр* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең замандашлары һәм көрәштәшләре: Гали, Госман, Гомәр хәлифәләр.

222 бит.

**Һәзиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 37 нче (15 апрель) санында басылган. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Шигырь астына «Кыйссасел-әнбия (Рабгузи)» дип куелган. Моны имза-псевдоним дип тә, Рабгузи китабыннан бер өзек дип тә уйларга мөмкин. Тукай аңлы рәвештә шундый эффект тудыра. Эш шунда ки, борынгыдан килгән пәйгамбәрләр тарихын шигырьгә салган һәм татарлар арасында киң таралып, яратып укылган бу китапта Мостафа хакында түбәндәге бәет бар:

Дин, шәригать рәитене гали кыйлган Мостафа,
Көфер золмәт туларыны йиргә салган Мостафа.

Къәумигә дин күстәрмәйүн күккә ашган Гайса ул,
Өммәтинә булышу бән йирдә калган Мостафа.

Ул, ата берлән анасындыйн кәчеб, өммәт өчен
Йалбарыб Хакъдан шәфагать, саткул алган Мостафа.

Имәс мәүҗүд аның дик гәүһәре пакь;
Дәлил улдыр ки, киде таҗы лүләк.

(Дин, шәригать фикерләрен югары иткән Мостафа,
Динсезлек, караңгылык байрагын җиргә аткан Мостафа.

Кавеменә дин өйрәтмичә күккә ашкан Гайса ул,
Иярченнәренә булышу өчен җирдә калган Мостафа.

Ул, ата-анасыннан ятим калып та, иярченнәре өчен
Алладан яклавын ялварып, булышлык алган Мостафа.

Аныңдай саф хәтта асылташ та юк;
Дәлиле шул: мактау таҗын киде ул.)

Рабгузи китабындагы бу бәет күп «Әнбия»ләргә, шул исәптән Аллаһияр Суфиның «Сөбател-гаҗизин» («Гаҗизләрнең ныклыгы») китабына да, аннары аңа шәрех-аңлатма булган Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә»сенә дә килеп кергән.

«Әнбия»ләрдәге Мостафа – Мөхәммәд пәйгамбәр; бу сүз аның мәдех-сыйфатламаларыннан берсе булып, «иң сайлап алынган» мәгънәсенә туры килә.

Г.Тукай шигырендәге Мостафа исә – тарихи шәхес. Кем соң ул? Чыгышы белән кавказлы Ширванский (Исмәгыйлев) Мостафа Лотфи, 1905–1907 елгы инкыйлаб чорында Төркиядән укып кайтып, Әстерханда җәмәгать эшләренә катнаша башлый, соңыннан «Мөселман иттифакы» партиясенә кушыла, хәтта аның җитәкче үзәгенә дә үрли. «Мөселман иттифакы»ның сәяси программасын раслау өчен җыелган III съездда (Түбән Новгород, 1906 ел, 16–20 август) сәркәтиплеккә, Й.Акчура, М.Бигиев белән бергә, «кавказиялеләрдән «Борһане тәрәккъый» мөхәррире Мостафа Лотфи әфәнде Исмәгыйлевне сайладылар» дип яза «Азат халык» газетасы (1906 ел, 27 август).

Үзенең корама телле газеталары («Борһане тәрәккъый» – 1906–1911; «Хәмият» – 1907–1909; «Мизан» – 1908–1909; «Хак» – 1911) аша Мостафа Лотфи алдынгы фикерле кешеләргә еш кына һөҗүмнәр ясый, татар әдәби телен төрекләштерергә чакыра.

«Һәзиһи касыйдәтен...»не язганга кадәр үк Тукай Мостафа Лотфине күп тапкырлар сатира угына ала. Мәсәлән, «Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе «Хак» былчырагы белән кешегә тәкфир ыргытмый иде. Икенчесе Мостафа Лотфи иде».

«Ялт-йолт»ка Әстерханнан мондый хәбәр алынган: «Ширванский Мостафа Лотфи «Шураи ислам» акчасын туздырган өчен 2 ел 4 айга хөкем ителә». Шигырьдәге: «Монда кайткач дин симергән, чучка булган Мостафа», «Мисле корчаңгы көчек, читкә сөрелгән Мостафа», «Чын тиешле абзарына инде кергән Мостафа» дигән юллар шуңа ишарә.

1911 елның апрель башыннан июнь башына кадәр (ике айга якын) Тукай Әстерханда С.Рәмиевтә кунакта була. Шагыйрьнең бу чоры хакындагы истәлекләрнең берсендә түбәндәге юллар бар: «Борһане тәрәккъый» газетасында Сәгыйть Рәмиев белән Тукайга карата карикатура урнаштырылды. Берничә көннән Сәгыйть, җыярга дип, миңа «Мостафа» шигырен бирде. Икенче көнне Тукай инде хәрефкә салынган шигырен ни өчендер кире ала».

224 бит.

**Балканда.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 44 нче (13 октябрь) санында рәсем-карикатура асты итеп имзасыз басылган. Рәсемдә биек таш стена, аның бер ягында йодрыкланган дүрт куллы төрек, икенче якта мылтык тоткан солдатлар аңа аталар.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Бу икеюллык Төркия белән Балкан дәүләтләре арасындагы сугыш мөнәсәбәте белән язылган.

225 бит.

**Казан мулласы һәм булачак депутат.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 45 нче (5 ноябрь) санында рәсем асты итеп, «Шүрәле» имзасы белән басылган. Өчкә бүленгән бу рәсемдә мулланың булачак депутат кураена биюе, «депутат»ның мулла җөббәсе чабуына тотынып, икесенең дә Петербургка очулары һәм Петербург өстендә җиргә егылып төшүләре сурәтләнгән. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Бу сатирик шигырь Казан байлары һәм муллалары тарафыннан IV Дәүләт Думасына депутатлыкка күрсәтелгән юрист һәм журналист Шәехгаттар Иманаевның (1875 – ?) актык минутта сайланмый калуы уңае белән язылган.

[1]*Казан мулласы* – Галимҗан Баруди (1857–1921), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Ш.Иманаевны сайлату өчен оештырылган кампаниянең башында торган. Ишмөхәммәт мулла һ.б. карагруһларның әләге белән указы алынып, 1907 елда Г.Баруди сөргенгә җибәрелә. Аннан кайткач, указын кире кайтару өчен төрле юллар эзли. IV Думага сайлауларга әзерлек вакытында Казан сәүдәгәре, «Бәянелхак» газетасының редакторы Мөхәммәтҗан Сәйдәшевнең кияве, юрист Ш.Иманаевны депутат итеп үткәрергә тырышуы да указын кайтаруда аларның булышлыгына исәп тотуыннан була. Тукай монда шуңа ишарәли.

227 бит.

**Валлаһи.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 45 нче (5 ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән, «Мәкаләи махсуса» исемле мәкалә ахырында басылган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Шигырь шагыйрьнең Троицк сахрасында кымызда ял итүе уңае белән язылган. Ахырга: «Иштә бу – сахрада беренче көнемдә язылып ташланган бер кәгазьдән алынган җырулар!» – дип искәрмә бирелгән.

228 бит.

**Тәмсил («Әһле Балкан кечкенә...»).** «Вакыт»ның 1912 елгы 7 ноябрь (1067 нче) санында «Балкан сугышы» исемле рубрикадан соң, «Гъ.Т.» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә Икетомлыкның 1 нче томына (1943) кертелгән.

Текст «Вакыт»тан алынды.

Тукай Төркияне зурлый, аңа мәдхия җырлый. Балкан илләрен (Болгария, Сербия, Греция һәм Черногория) кимсетеп сурәтли.

230 бит.

**Аң.** «Аң»ның 1912 елгы 1 нче (15 декабрь) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томына (1930) кертелгән.

Текст «Аң»нан алынды.

*«Аң»* – 1912–1918 елларда Казанда чыккан әдәби-иҗтимагый журнал. Редакторы һәм нашире «Гасыр» китап ширкәте башлыкларыннан берсе – Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883–1938). Киңәшү-сөйләшүдә, булачак журналның идея-сәяси

һәм әдәби-эстетик юнәлешен билгеләүдә һәм Хәсәнине бу эшкә күндерүдә Тукай якыннан катнашкан. Журналга исемне дә Тукай тәкъдим итә. Бу шигыре дә журналның чыга башлавы уңае белән языла һәм 1 нче саны шуның белән ачыла. «Аң» журналында бу шигырь яңадан басыла һәм 1 нче куплеттан соң, түбәндәге дүртьюллык өстәлә:

Кем бу гафләттән итә файда, шуны күрдек торып,
Шундый төнге аучыларның өстенә йөрдек торып,
Галибанә качырдык, барчасын сөрдек торып,
Чөн дә Чыңгызча сугышка башладык дошман белән.

Соңыннан сызык астына редакция мондый аңлатма да бирә: «Бу шигырь мәрхүм шагыйремез Г.Тукаев тарафыннан «Аң»га багышланып, журналымызның беренче елгы 1 нче санында дәрҗ ителгән иде. Ләкин ул шигырьнең икенче мисрагыннан дүрт юлы, шул вакытларда матбугатымызны борындыклап алып, үзләренең каты хөкемнәрен йөрткән мәрхәмәтсез цензорлар тарафыннан журналымызда басарга манигъ ителеп, төшерелеп калдырылган иде. Инде без мәзкүр шигырьне, хәзерге көннәрнең рухына бик якын тапканлыгымыздан, тулы бер мәгънәне аңлатсын өчен, бөтенләен берьюлы, шагыйрьнең идарәмездә сакланган мәсәүвәдәсеннән гайнән күчереп, «Аң»га тәкрар дәрҗ итәмез. Цензор төшереп калдырган дүрт юл калын хәрефләр белән басылды. Идарә».

[1]*Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән...* – 1905–1907 еллардагы Беренче рус инкыйлабы күздә тотыла.
[2]*Җәбраил ачкай ул эшләргә сигез кат күккә юл...* – ислам динендә Алла белән пәйгамбәрләр арасында арадашчы ролен үтәгән Җәбраил (Җибрил) фәрештә изге кешеләрнең рухларына «күк капусын» (капкасын) ача. Күк җиде кат булып, анда чыга торган капкалар сигез.

231 бит.
**Толугышшәмси мин мәгърибиһа.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.
«Җан азыклары» – Тукайның үзе исән чакта басылып чыккан җыентыкларыннан соңгысы. Җыентыктагы 40 шигырьнең 31 е төрле вакытта язылган булса да беренче мәртәбә басылган. Алар түбәндәгеләр: «Толугышшәмси мин мәгърибиһа» («Кояшның көнбатыш яктан чыгуы»), «Үтенеч», «Дошманнар», «Кичке теләк», «Җегетләр», «Ваксынмыйм», «Бала оҗмахта», «Сагыныр вакытлар», «Тәләһһеф», «Картлар», «Авылда авырып яту», «Бәрәңге вә гыйлем», «“Йолдыз”дан да курка», «Буран», «Көтмәгәндә», «Көлке түгел», «Әхлаксызлык», «Монафикъка», «Сабыйлар җыруы», «Ни кирәк тагы?», «Пушкин вә мин», «Мөнтәкыйд», «Интикадка мөтәгалликъ», «Мәхәббәт шәрхе», «Казан вә Кабан арты», «Казан вә Казан арты», «Татар яшьләре», «Дин вә гавам», «Яңгыр», «Җил тавышы», «Авыл халкына ни җитми», «Өч хәкыйкать» (поэма). Болар арасында Пушкин, Майков, Ушинский һ.б. язучылар әсәрләреннән ирекле тәрҗемәләр, аларга ияреп язылган шигырьләр дә бар. Тышлыкта «Шигырьләр китапханәсе»ннән дигән рубрика астында төрле шагыйрьләрнең басылып чыккан әсәрләре исемлеге китерелә. «Җан азыклары» җыентыгы басылып, Петербургка килеп җитү белән Кәрим Сәгыйть, аңа карата үз фикерен әйтеп, Тукайга хат яза. Ул: «Җан азыклары» минем сиңа булган өметемне арттыра гына түгел, көткәнемне тәкмил итәр дәрәҗәсенә җитештерде», – дип бәя бирә.

233 бит.
**Үтенеч.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

234 бит.
**Дошманнар.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

235 бит.
**Кичке теләк.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*Мәхшәр* – ислам динендә дөнья беткәннән соң (кыямәт көнендә) кубарылып чыккан барлык җан иясенең җыелу урыны, көне.

236 бит.
**Җегетләр.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

237 бит.
**Ваксынмыйм.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

238 бит.
**Бала оҗмахта.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.
Тукай бу шигыренә: «Үземә таныш бер кешенең күңелемә якын бер баласы үлгәч, мәрхүм баланың кабер ташына нәкыш итәргә, дип язган идем «Гъ.Т.», – дигән искәрмәне биргән.

[1]*Хур* – ислам динендә җәннәткә керүчеләргә вәгъдә ителгән бик матур кыз.
[2]*Гыйльманнар* – ислам динендә җәннәттә хезмәтче егетләр.

239 бит.
**Сагыныр вакытлар.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.
Әсәрдә балачакның якты хатирәләре шагыйрьнең мәшәкатьләр, җан газаплары һәм көрәш тулы җитлеккән чорына каршы куеп тасвир ителә.

[1]*Җан-Зөһрә берлән Җан-Таһирне кызганып...* – XIX гасыр татар шагыйре Әхмәт Уразаев-Кормашиның (?–1883) «Таһир вә Зөһрә» поэмасы геройлары.

240 бит.

**Картлар.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь 2 кисәктән тора: берсендә шау-шулы карта уены, икенчесендә – чагыштырмача конкрет яшәешкә хас күренеш тасвирлана. Соңыннан гомумиләштерүче икеюллык китерелә.

241 бит.

**Авылда авырып яту.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь шагыйрьнең, саулыгына шифа эзләп, авылга кайткан чагында язылган. Шагыйрь үзенең кышкы авыл шартларындагы кичерешләрен чагылдыра, авыл халкының, кышкы авылның көнкүрешен бәян итә.

Бу вакытларда шагыйрьнең үпкә авыруы бик нык борчыганлыгы билгеле. Әмма ул тән газабын мөмкин кадәр тизрәк рухи тормышыннан читкә алып ташларга омтыла. 1912 елның башларында ул Өчиле авылында була, авыруы җиңеләя, кабаттан көр күңелле кеше була башлаганлыгын хәбәр итә: «Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм. Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек... Монда бөтенләй оптимистландым, ахры».

242 бит.

**Бәрәңге вә гыйлем.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

243 бит.

**«Йолдыз»дан да курка.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь мәгърифәтнең барлык чыганакларыннан файдалану түгел, бәлки «гөнаһсыз» гына «Йолдыз» газетасын кулына алырга да курыккан крестьян образын гәүдәләндерә.

[1]*«Йолдыз»* – 1906–1918 елларда Казанда чыккан иҗтимагый-сәяси газета. Нашире һәм мөхәррире – Ә.Максуди, сәркәтибе – Г.Камал, соңрак Г.Баттал. Газетада Г.Тукай, М.Гафури, Җ.Вәлиди һәм башка язучыларның шигырьләре, мәкаләләре басыла.

244 бит.

**Буран.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды. Шигырьдә зилзилә уртасында калган юлчының халәте, газаплы кичерешләре тасвирлана.

[1]*Каф тау* – мифик тау.

245 бит.

**Көтмәгәндә.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь «мин» белән шартлы мифик затның үзара әңгәмәсенә корылган. Сөйләшү дусларча бара. «Мин» әңгәмәдәшенә, үз итеп, хәтта «Шүрәлем» дип тә дәшә. Ул явыз, мәкерле зат рәвешендә күзалланмый. Шагыйрь аны «табигать иркәсе» дип әйтә.

246 бит.

**Көлке түгел.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

247 бит.

**Әхлаксызлык.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

248 бит.

**Монафикъка.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды. Исеменнән соң «Сюжет русчадан» дип куелган.

Г.Тукай бу шигырен икейөзлеләнеп йөрүче кешеләргә каршы язган.

249 бит.

**Сабыйлар җыруы.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

250 бит.

**Ни кирәк тагы?** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Исеменнән соң «Экспромтъ» дип куелган. Текст шуннан алынды.

251 бит.

**Пушкин вә мин.** Беренче тапкыр «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*Хәзрәти Пушкин авылда язды үз «Евгение»н...* – А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» романы (1823–1831) күздә тотыла. Пушкин үз романының шактый өлешен 1824–1826 елларда Псков өлкәсендәге Михайловское авылында (әтисенең утарында) яшәп яза.

252 бит.

**Мөнтәкыйд.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

«Ялт-йолт»ның 1913 елгы 53 нче (15 март) саны тышлыгында ат койрыгын тотып торган берәүнең рәсеме бирелгән. Рәсем астына:

Ул тота ат койрыгын да: «Бу – озын сач!» – дип куя.

«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаж!» дип куя, –
дигән юллар басылган. Өстә *«Габди»* дип куелган. «Габди» – Галимҗан Ибраһимовның яшерен имзасы (псевдонимы). Шигырь әдип Г.Ибраһимовтан көлеп язылган. Алар арасында урнашкан катлаулы мөнәсәбәтнең төп сәбәбе – әдәби-эстетик карашларының, төгәлрәк әйтсәк, поэзияне аңлауларының бер-берсенә туры килмәве. Шагыйрь Г.Ибраһимовның тәнкыйть мәкаләләрен кабул итә алмый, хәтере кала, оппонентының әйткән сүзен генә түгел, акрынлап үзен дә өнәми башлый. Ул күпчелек очракта аның белән фельетон телендә бәхәсләшә, әдипне көлке ситуациягә куя, яисә берәр уңышсыз гыйбарәсен эләктереп ала да хурлык тамгасы сала.

253 бит.

**Интикадка мөтәгалликъ.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

254 бит.

**Мәхәббәт шәрхе.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

*Һенрих Һәйне* (1797–1856) – немец шагыйре.

255 бит.

**Казан вә Кабан арты.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырьдә татар әкиятләре сюжетына охшатып, Октябрьгә кадәрге Кабан артындагы фәхешханәләр, пычраклыклар фаш ителә.

[1]*Кәүсәр* – ислам динендә оҗмахтагы татлы сулы елгаларның берсе.

[2]*Кисекбашның җебен...* – монда Тукай үзенең «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына ишарәли: анда Карәхмәт алты мең колачлы бауның бер башын Кисекбашның теленә, икенче башын үзенең биленә бәйләп, Кабан күле төбенә – Дию катына төшә. Ул чорда «җеп» дип бау, арканны да атаганнар.

«Җан азыклары» (1912) китабының 33 нче битендә «чучкасы» дигәннән соң, берничә строфаны редакция тарафыннан калдырылды» дип искәрмә бирелгән. Шигырь эчтәлеккә бөтенләй якын килми, ятышмый торган юллар белән тәмамлана:

Шунда кыткылдый әтәч, мыркылдый шунда дуңгызы;
Шунда хурлыкта, хәкарәттә мәхәббәт йолдызы.

Бу строфа Тукайның «Мәхәббәт шәрхе» (1912) шигырендә дә үзгәрешсез кабатлана. Әлеге юлларның «Казан вә Кабан арты» шигыренә килеп керүе, бәлки, кыскартылган өлешне ничек тә булса тутырып бетерү максаты белән эшләнгәндер?! Мәсьәлә һәрхәлдә ачыклауны сорый.

257 бит.

**Казан вә Казан арты.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

258 бит.

**Татар яшьләре.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды. 1910 елда Тукай «Яшьләр» исемле шигырендә «Җегетләр! Бездә көч юк, ахры, булмас!» – дип белдерсә, 1912 елда, Петербургка баргач, халыкка хезмәт итү өчен әзерләнә һәм киләчәккә өмет белән карый торган татар яшьләре белән аралашкач, аңарда яшәү теләге яңа көч белән кабынып китә. Шигырь шушы тәэсирләр йогынтысында язылган.

259 бит.

**Дин вә гавам.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Тукайның дингә мөнәсәбәте бер яклы гына түгел. Билгеле булганча, ул Алланың берлеген һәм барлыгын таный. Садренә, ягъни күңеленә Иман берлә Коръән урнашкан. Әмма ул үз заманының алдынгы фикер иясе буларак искелекне, динне кәсепкә әйләндерүне, наданлыкны, бозыклыкны аяусыз тәнкыйть итә. Диннең дәрәҗәсен төшерә торган күренешләрнең кайберсен шушы шигырендә ачып сала.

260 бит.

**Яңгыр.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

Әсәр А.Н.Майковның (1821–1897) «Летний дождь» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

«Золото, золото падает с неба!» –
Дети кричат и бегут за дождем...
– Полноте, дети, его мы сберем,
Только сберем золотистым зерном
В полных амбарах душистого хлеба!
*1856*

261 бит.

**Җил тавышы.** «Җан азыклары»нда (1912) басылган. Текст шуннан алынды.

262 бит.

**Авыл халкына ни җитми.** Октябрьдән соң, Тукай кульязмалары арасыннан табылып, басыла башлаган. Беренче тапкыр «Гажур» басмасына (1926) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Ф.Бурнаш: «Бу шигырь кульязмада бар иде», – дип искә ала. Ләкин кульязмасы бүгенге көндә сакланмаган.

263 бит.

**Өч хәкыйкать.** «Җан азыклары»нда (1912) «Майковтан» дип искәртелеп басылган. Текст шуннан алынды.

Бу шигырь-мәсәлнең төп авторы – фарсы телендә иҗат иткән, Көнчыгышның бөек шагыйре Җәләлетдин Руми (1207–1273). «Өч хәкыйкать» – Руминың 27 000 бәеттән (икеюллыклардан) торган «Мәснәви» исемле атаклы поэмасының бер кисәге. «Мәснәви»дәге бик күп шигырьләр, хикәяләр, кыйссалар, шул исәптән «Өч хәкыйкать» тә, дөньяның күп әдипләре, шагыйрьләре тарафыннан үз телләренә тәрҗемә ителгән, аңа ияреп, нәзыйрә итеп тә язганнар. Рус шагыйре А.Н.Майковның «Три правды (Сказка)» нәзыйрәсе – шундыйларның берсе. Тукай исә Майковтан ирекле тәрҗемә ясаган.

[1]*...Адәм теле, Хам белән Яфәс, тагын да Сам теле.* – Дини риваятьтә Адәм – беренче кеше (борынгы яһүдчә «одом» – «кеше» дигән сүз); Адәмнең улы – Нух; Нухның өч улы: Хам, Сам, Яфәс. Дөньядагы телләр шушы өч исемгә бәйләнгән, имеш: хәмит, сәмит һәм яфет телләре. Тукай исә монда чыпчыкның гомумән кеше телендә сөйләшүен аңлату өчен Адәм, Сам, Яфәс телләрен санап чыга.

269 бит.

**Балкан көйләре.** «Кояш»ның 1912 елгы 23 декабрь (8 нче) санында «Кечкенә фельетон» рәвешендә «Шүрәле» имзасы белән басылган. Тукайның үзе исән чагында чыккан җыентыкларына кертелмәгән. Беренче тапкыр Икетомлыкның 1 нче томына (1943) кертелгән.

Текст «Кояш»тан алынды.

Шигырь Балкан дәүләтләре белән Төркия арасында барган сугыш, аның Төркия өчен иң кыен чагы хакында язылган.

Патша Россиясенең булышлыгы белән, 1912 елның март-сентябрь айларында Балкан дәүләтләре Болгария, Сербия, Греция һәм Черногория арасында Төркиягә каршы политик һәм хәрби дүртлек союзы төзелә. Шушы ук елның октябрендә Төркиягә каршы сугыш ачып, бу дүрт дәүләт тиз арада аны җиңә, һәм Лондонда Төркия өчен хурлыклы килешүгә кул куела.

**1913**

271 бит.

**Шиһаб хәзрәт.** «Аң»ның 1913 елгы 2 нче (1 гыйнвар) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр «Мәҗмугаи асарь»гә (1914) кертелгән.

Текст «Аң»нан алынды.

Шигырь Ш.Мәрҗанине олылап, аның фикерләрен, дөньяга карашын хуплап, туган көненә багышлап язылган.

*Шиһабеддин Мәрҗани* (1818–1889) – тарих, этнографик хезмәтләре белән танылган күренекле татар галиме, дин реформаторы.

[1] – *Фәлән сәләф фәлән әйткән, фәлән бул, – дип...* – борынгы галимнәр әйткән сүздән чыгарга ярамый, дигән догма.

[2]*Булып бетми аның гакълы нәкыльгә кол...* – Ш.Мәрҗани борынгылар сүзенә тәнкыйть күзе белән карау, заманга ярашлы рәвештә уйлау-фикерләү ягында була.

[3]*Дәлил итә «Тәзәккәрү!» аятьләрен...* – Ш.Мәрҗани кирәк урында Коръәндәге «Тәзәккәрү!» («Искә алыгыз!»), «Тәфәккәрү!» («Уйлагыз, фикерләгез!») дип башланган аятьләрне дә куллана.

[4]*Тиздән милләт итә бәйрәм...* – татар җәмәгатьчелеге Ш.Мәрҗанинең тууына 100 ел (мөселман ай елы исәбенчә) тулуны аңа зур хөрмәт белән 1914 елда билгеләп үтте.

273 бит.

**Йокы алдыннан.** «Аң»ның 1913 елгы 2 нче (1 гыйнвар) санында «Г.Тукаев» имзасы һәм рәсем белән басылган. Беренче тапкыр Икетомлыкның 1 нче томына (1943) кертелгән. Шигырьнең кульязмасы сакланмаган.

Текст «Аң»нан алынды.

Тукай бу шигырен русчадан файдаланып язган, ләкин ул саф татарча оригиналь әсәр булып тора.

274 бит.

**Суык.** «Ялт-йолт»ның 1913 елгы 49 нчы (10 гыйнвар) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган, «1 гыйнвар, 1913 сәнә» дип куелган. Текст шуннан алынды.

[1]*Печән базары* – Иске Казанда хәзерге Татарстан, Мәскәү, Париж Коммунасы урамнарының шактый өлешен биләп, татар байларының зур һәм вак кибетләре, лабазлары, кунакханәләре, харчевнялары һәм печән үлчи торган зур үлчәүләре урнашкан зур бер мәйданның (төбәкнең) халык телендәге исеме.

[2]*Мәгыйшәтче* – «Дин вә мәгыйшәт» журналы тарафдары мәгънәсендә.

[3]*Кабан күле* – Казан шәһәре уртасындагы күл.

[4]*«Акыллы баш» Ишморат* – иске фикерле, кара эчле мулла-мунтагайны алдынгы фикерле яшьләргә каршы котыртып торучы җир хуҗасы, ат заводы иясе һәм сәүдәгәр Габдрахман Ишморатов.

[5]*Черек күл* – Казан шәһәре уртасындагы зур булмаган күл. Элек сазламык булганга, «Черек күл» дип аталган.

277 бит.

**Хәстә хәле.** «Аң»ның 1913 елгы 3 нче (15 гыйнвар) санында, 33 нче биттә «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «12 гыйнвар, 1913 сәнә» дип куелган. Текст шуннан алынды.

Бу чорда шагыйрьнең саулыгы күзгә күренеп начарлана. Гәрчә ул күп язса, күп эшләсә дә, яшәвенең мәгънәсе турында уйлана, күңелен авыр уйлар биләп ала. Шигырь шушы кичерешләр тәэсирендә язылган.

278 бит.

**Әнвәр бәк.** «Ялт-йолт»ның 1913 елгы 50 нче (28 гыйнвар) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Әсәрләре басмаларына кертелмәгән. Хәзерге татар язуында беренче тапкыр «Мирас» журналының 1994 елгы 4 нче санында Ф.Ибраһимова тарафыннан әзерләп урнаштырылган.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Тукайның соңгы сатирик шигыре «Әнвәр бәк» Төркиядә булган вакыйгаларның кайнар эзеннән языла. «Яшь төрекләр» җитәкчеләренең берсе Әнвәр бәк 1913 елның 23 гыйнварында бер төркем офицерлар белән хөкүмәт утырышына бәреп керә. Хәрби министр үтерелә, баш вәзир үз вазифаларыннан баш тартырга мәҗбүр ителә. Солтан яңа хөкүмәт билгели, һәм «яшь төрекләр»нең «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасе кире хакимияткә кайта. 1914 елда Госманлы дәүләтендә идарәне үз кулына триумвират – «өч паша» алгач хөкүмәт башлыгы була. Төркия 1918 елда сугышта җиңелгәннән соң, ул илдән кача. Соңрак Әнвәр бәк Урта Азиядә басмачылар хәрәкәтен оештыруда катнашкан. 1922 елда Кызыл Армия отрядларына каршы бәрелештә һәлак булган.

[1]*Тагы бер Гайса*

*Дарга асылса...* – дини сюжеттагы Гайсә пәйгамбәрне дарга асу вакыйгасы күздә тотыла.

[2]*Ибраһим утка атылган...* – Ибраһим – бер Аллаһыга инанырга өндәүче беренче пәйгамбәр. Потларын ваткан өчен мәҗүсиләр аны утка аталар, ләкин Аллаһның кодрәте белән утның кызуы сүрелә, һәм Ибраһим пәйгамбәр исән кала.

[3]*Өхед, Бәдер* – 624 елны Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең тарафдарлары белән Мәккә һәм Мәдинә арасындагы Бәдердә мәккәлеләрнең гаскәрен җиңә. Икенче елны мәккәлеләр Өхед тавы янындагы сугышта өстенлек алалар, шунда Мөхәммәд пәйгамбәр башына атылган таштан яралана.

Тукайның Әнвәр бәккә карата симпатиясе бераз сизелсә дә, тулаем алганда, ул – сатирик шигырь, анда ирония өстенлек итә.

280 бит.

**Даһигә.** «Аң»ның 1913 елгы 4 нче (1 февраль) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Гомере төгәлләнеп килә торган, вафатына ике ай чамасы калган вакытта да шагыйрь татар милли-азатлык хәрәкәте турында уйлана һәм газиз халкын колониаль изүдән коткару, аны иҗтимагый-мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзләгән Даһи образын иҗат итә. Ул чорда андый шәхес Гаяз Исхакый дип аңларга кирәк.

281 бит.

**Толстой сүзе («Зур бәхет инсанга...»).** «Аң»ның 1913 елгы 4 нче (1 февраль) санында 49 нчы биттә «Даһигә» шигыреннән соң «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

282 бит.

**Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре.** «Мәктәп»нең 1913 елгы 1 нче (21 февраль) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «21 февраль, 1913 сәнә» дип куелган. Текст шуннан алынды.

*«Мәктәп»* – Казанда 1913–1914 елларда айга ике тапкыр чыккан уку-укыту һәм тәрбия журналы.

Шигырь Романовлар династиясенең Россиядә патшалык итә башлавының 300 еллыгы уңае белән язылган.

Шигырь Икетомлыкның 1 нче томында (1943 б.) урнаштырылган. Ләкин 265 нче биттә «Хаккыбыз» сүзе типография ялгышы белән *«халкыбыз»* дип басылган. Китапның иң ахырындагы төзәтмәләр таблицасында бу сүз *«хаккыбыз»* дип төзәтелгән.

284 бит.

**Кыйтга («Көчләремне мин...»).** «Аң»ның 1913 елгы 6 нчы (1 март) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

285 бит.

**Шөһрәт.** «Аң»ның 1913 елгы 6 нчы (1 март) санында имзасыз, беренче итеп басылган. Текст шуннан алынды.

286 бит.

**Толстой сүзе («Кирәк анчак...»).** «Аң»ның 1913 елгы 7 нче (15 март) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Язылу вакыты «4 март, 1913 сәнә» дип күрсәтелгән. Текст шуннан алынды.

Шигырьнең кульязмасы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә (9 ф., 1 тасв., 8 эш) саклана. Аннан күренгәнчә, «Толстой сүзе»ннән соң «Тәфсирме? Тәрҗемәме?» шигыре килә һәм ахырда «Гъ.Т. 4 март, 1913 сәнә. Шифаханә» дип, язылу вакыты күрсәтелә.

287 бит.

**Тәфсирме? Тәрҗемәме?** «Аң»ның 1913 елгы 7 нче (15 март) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Коръәннең «Наср» («Ярдәм») дигән 110 нчы сүрәсендә (гарәпчәдән татарчага сүзгә-сүз тәрҗемәсендә): «Алланың ярдәме һәм җиңүе ирешкәндә, син кешеләрнең ничек төркем-төркем булып Алланың диненә керүләрен күрдең; шулай булгач, үзеңнең Раббеңне макта, данла һәм аннан тәүбә сора. Дөрестән дә, Ул – ярлыкаучы!» – диелә. Тукайның бу шигыре исә шушы атаклы сүрәгә таянып иҗат ителгән. Текстта шагыйрьнең өстәмәләре, аңлатмалары да урын алган. Мәсәлән, «Һич тә беркөч туктаталмый, манигы (киртәсе) булмый аның» һәм «Мәккәдә ачты бүген якты иманга баб (ишек) Ходай» дигән юллар – Тукайның үз сүзләре, үз тәфсире. Шуңа күрәдер дә ул бераз шикләнептер, ахры, шигыренең өстенә «Тәфсирме? Тәрҗемәме?» дип язып куйган.

288 бит.

**Мөхәрриргә.** «Мәктәп»нең 1913 елгы 3 нче (24 март) санында басылган. «Гъ.Т. 1913 сәнә, 10 март» дип куелган. Текст шуннан алынды.

[1]*Бишенче елдагы күп әүлия.* – 1905–1907 еллардагы инкыйлаб чорында демократик идеаллар белән янган кайбер кешеләрнең соңыннан үзара талашулары, шул идеаллардан читләшүләренә ишарә ителә.

[2]*Гомәр* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең фикердәшләреннән, көрәштәшләреннән берсе, ярым легендар хәлифә.

Бу – Тукайның үлеменә 23 көн кала язган соңгы шигырьләреннән берсе. Ул сөргеннән кайтучы Гаяз Исхакыйны лаеклы каршылау өчен барган кампания уңае белән язылган. Язучы, татар милләте мәнфәгатьләре өчен көрәшүче Г.Исхакый 6 ел сөрген, төрмә һәм качудан Казан шәһәренә керә алмаган. Милләтебезне уяткан, күтәргән, инкыйразның, бетүнең нәрсә икәнен аңлаткан Г.Исхакыйны Тукай бик хөрмәт итә, данлый, «кайт әле монда Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!» ди.

289 бит.

**Толстой сүзләре.** «Аң»ның 1913 елгы 8 нче (10 апрель) санында имзасыз басылган. «Мәрхүм Габдулла Тукаевның иң соңгы шигырьләре» дип, «Буш вакыт» һәм «Мәктәп» шигырьләре белән бергә бирелгән. Ахырга «1913 сәнә, 28 март. Шифаханә» дип куелган.

Текст «Аң»нан алынды.

290 бит.

**Кыйтга («Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов...»).** «Мәктәп»нең 1913 елгы 4 нче (20 апрель) санында имзасыз басылган. Шигырьнең ахырына «Соңгы шигырьләреннән» дип куелган.

Текст «Мәктәп»тән алынды.

[1]*Жуковский* – рус шагыйре, тәрҗемәче В.А.Жуковский (1783–1852).

291 бит.

**Буш вакыт.** «Аң»ның 1913 елгы 8 нче (10 апрель) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1]*«Гайнел-гыйлем»* («Белемнәр чишмәсе») – гарәпчәдән татарчага тәрҗемә ителеп, Казанда 1883 елда басылып чыккан дини-әхлакый китап. Ул иске мәдрәсәләрдә дәреслек урынына да йөргән.

Әсәр шагыйрьнең «Толстой сүзләре» циклына кергән шигырьләре хакында уйланып язылган.

292 бит.

**Мәктәп.** «Аң»ның 1913 елгы 8 нче (10 апрель) санында «Буш вакыт»тан соң басылган. Текст шуннан алынды. Ахырда «Г.Тукаев. 28 март, 1913 сәнә. Шифаханә» дип күрсәтелгән. Шушы ук шигырь 1913 елда «Мәктәп» журналының 4 нче санына да урнаштырылган (20 апрель. 97 б.). Шигырь ахырында «Г.Тукаев («Аң» журналыннан)» дип күрсәтелгән. «Мәктәп» журналында 1 нче юлдагы *«авылында дәү»* сүзләре төшереп калдырылган. Шигырьнең кулъязмасы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә саклана (9 ф., 1 тасв., 8 эш).

293 бит.

**Казан.** «Мәктәп»нең 1913 елгы 4 нче (20 апрель) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Соңгы шигырьләрендән» дип күрсәтелгән. Текст шуннан алынды.

**Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр**

**(1909–1913)**

294 бит.

**Яңа чыкты.** «Яшен»нең 1909 елгы 7 нче (2 март) санында 11 нче биттә имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь беренче тапкыр икенче Дүрттомлыкның 2 нче томында (1976) бирелде.

295 бит.

**Җабир хәзрәт мактана...** «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 5 нче (15 май) санында «Күрдем» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Җабир хәзрәт* – Уфа губернасыннан Беренче Дәүләт Думасына сайланган иске фикерле мулла, «Хәсәния» мәдрәсәсе имамы Сабир әл-Хәсәни (Сабирҗан Хәсәнев, 1866–?). Алдынгы карашлы яшьләргә каршы чыгып, байларны, сәүдәгәрләрне яклап, газета-журналларга (бигрәк тә «Бәянелхак»та) усал-усал мәкаләләр язганы өчен, Тукай бу хәзрәткә күп тапкырлар үткен сатирик укларын җибәрде. «Алай-болай» дигән фельетонында аңардан, Казан сәүдәгәре Әхмәтҗан Сәйдәшевнең «остабикәсе, кече хатыны» дип көлде; «Керешү хотбәсе» дигән памфлетында аны «юләр, консыз, җирәнгеч, кешелекнең бөтен яхшы сыйфатларыннан мәхрүм... Такырҗан Хәсәни» дип атады.

«Җабир хәзрәт мактана...» сатирасы үлчәме, теле-стиле белән генә түгел, темасы, эчтәлеге белән дә Тукайныкы булуы ихтимал дигән фикергә китерә.

[1]*...Тройскидән шәһадәт бар кулымда.* – С.Хәсәни – Зәйнулла ишан Рәсүлев шәкерте, Троицк (хәзерге Чиләбе өлкәсе) шәһәрендә «Рәсүлия» мәдрәсәсен тәмамлаган була.

296 бит.

**Табышмаклар.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 39 нчы (1 июль) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

Теле-стиле, үлчәме, тапкыр сүзлелеге, темасы һәм Тукайның аерым сүзләре, гыйбарәләре очравы күңелендә аларның Тукайныкы булу ихтималын тудыра.

Шигъри табышмаклар иҗат ителү төрки-татар сүз сәнгатендә элек-электән үк күзәтелә. «Ялт-йолт»та басылган табышмаклар да шул традицияне дәвам иттерү булып тора.

297 бит.

**Бәндәләр.** «Ялт-йолт»ның 1912 елгы 41 нче (15 июль) санында Тукайның «Мәкаләи махсуса» исемле юлъязма-очеркы артыннан ук имзасыз басылган. Ахырга «4 декабрь» дип куелган. Беренче тапкыр Өчтомлыкның 2 нче томында (1930) «Тукайга нисбәт ителгән шигырьләр» рәтенә кертелгән. Н.Исәнбәт аны «Казан утлары» журналының 1966 елгы 4 нче санында «Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре» дигән мәкаләсендә искәрмәләр белән бастырып чыгарды, аннары шигырь икенче Дүрттомлыкның 2 нче томында (1976) бирелде.

Текст «Ялт-йолт»тан алынды.

Ф.Сәйфи-Казанлы «Бәндәләр»не «...Тукайның шул вакыттагы җәмәгать хәленә ясаган тәнкыйте» дип бик дөрес бәяли һәм аның имзасыз басылуын: «Ул вакытларда цензура Тукай шигырьләрен нык тикшергәнгә күрә, имзасын куймаган булырга кирәк», – дип аңлата. Бу аңлатуда, әлбәттә, хаклык та бар. Әмма сәбәп монда гына түгел, күрәсең. Тукай журналның бер үк санында 2, 3 яки аннан да күбрәк шигырь, парча яки мәкаләләре басылган очракта, еш кына бер-ике әсәрен имзасыз да бирә. Шагыйрь үзе оештырган, чыгарган «Уклар», «Яшен», «Ялт-йолт», «Аң» журналларының гына түгел, үзе язышкан «Мәктәп» журналы, «Әлислах» газетасының да һәр саны диярлек, кагыйдә буларак, аның шигыре яки мәкаләсе белән ачыла. Әгәр инде берничә әсәре басылса, алар күп очракта бер-бер артлы, башлыча журналның алгы өлешендә биреләләр. Исем-фамилиясе, псевдонимнары яки имзасыз шигырь, фельетон, мәкаләләре аралаштырып та урнаштырыла. Әйтик, «Сәяхәте көбралар ясаучы Шүрәле» имзасы белән «Мәкаләи махсуса» баш мәкалә урынына бирелгән, аның артыннан «Бәндәләр» шигыре имзасыз гына урнаштырылган.

«Бәндәләр» шигыренең ахырына «4 декабрь» дип куелган. Әле Тукай исән чакта ук журналга язышкан, аннары редакциядә эшләгән Ф.Сәйфи-Казанлы, шигырьнең Тукайныкы икәнен исбатлау өчен, тагын болай ди: «Аннан соң «Ялт-йолт»та бары төп язучы Тукайның шигырьләренә генә тарих куеладыр иде». Монда да зур хаклык бар. Чыннан да, Тукай шигырьләренә, бигрәк тә 1910 еллардан соң, дата куела. Әмма бик сирәк очракларда гына кайбер бүтән авторларның әсәрләре астында да дата күренә.

«Бәндәләр» шигыре исә, югарыда китерелгән «техник» билге-үзенчәлекләрдән тыш, үзенең темасы, теле-стиле, сатирик көче белән «Тукайныкы булуы ихтимал» дигән фикергә китерә. Ниһаять, Тукай турындагы бер истәлектән: «1) Муса әфәнде ят кеше... өстенә фәүкыльгадә тәкәллефле, – Тукайның үз тәгъбиренчә, – төче телле. Төче теллелекне ул үзе шулай тәфсир кыйла: ул менә – Муса әфәнде була инде – юк кына нәрсәне тәкәллефләндереп зурайта, «зате галиләре, бәндәләре» ди... Әллә нәрсә вә әллә нәрсәләр катыштыра да ике арага пәрдә сала да куя. Шуның өчен, никадәр якын булырга теләсәң дә, аның белән рәхәтләнеп, тәкәллефсез сөйләшеп булмый. Ул «зате галиләре» ди бит инде. Аңа каршы син ни дип әйтергә кирәк?..»

Әйтергә кирәк, Тукайның төрле әсәрләрендә М.Бигиев хакында әйткән фикерләре нәкъ менә «Бәндәләр»дә сурәтләнгән сыйфатларның күбесенә туры килә.

[1]*«Мөхәммәдия»* – төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләби Язычы угылы (1451 яки 1453 елда үлгән) тарафыннан төзелгән көйле әсәр.

[2]*Зәмзәм* – Согуд Гарәбстанындагы Мәккә шәһәрендә Кәгъбә (мәчет) янындагы кое исеме. Шифалы дип, аның суын хаҗга барган кешеләр махсус савытларга тутырып алып кайта торган булалар.

299 бит.

***** («Амур» – фәхеш рестораны...»).** Арча районы Өчиле авылында яшәүче Гафиятулла Нәбиулла улы Нәбиуллиннан (1895 елда туган) әдәбият галиме Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан археографик экспедиция вакытында язып алынган (1982 ел, 1 июль). Тукай гомеренең соңгы айларында Казанда элекке Печән базарындагы (хәзерге Мәскәү урамы, 70 нче йорт) «Амур» кунакханәсендә яши, аның ресторанЫ Тукай номерына стена аша гына була. «Казанда бер хәрчәүнәче үзенең пәрәмәч сата торган номерларына «Амур» дип исем кушкан. Вәхәлбуки «Камыр» дип атау тиеш иде (аның да тараканлысы)», – дип көлеп яза шагыйрь бер очеркында.

300 бит.

**Ялгызлыкта.** «Ялт-йолт»ның 1913 елгы 54 нче (3 апрель) санында «Шагыйре мәшһүр Якыйф Җәмали» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь исеме астына «“Шагыйре мәшһүр” Вакыйф Җәлалигә тәкълид» дип куелуыннан ук аның кемгә пародия икәнлеге аңлашыла. Вакыйф Җәлал бик күп яза, әмма шигырь дип язганнарының күбесе нәзымнан – көйле тезмә булудан уза алмый. Ул артык талымсыз, бер кыйбласы, тоткан мәсләге сиземләнми, «Бәянелхак», «Дин вә мәгыйшәт» кебек матбугат органнарына бик теләп языша. Алай гына да түгел, демократик матбугатка һөҗүм дә иткәли. Тукайның «Тәәссер» шигыренә каршы – «Тәфәккер» (Идел. 1910. № 244), «Өмидсезлек»кә каршы «Истикъбаль өмидләре»н язган. (Идел. 1910. № 274) Анда, аерым алганда:

«Әй каләм, фикреңне язмакта косурлык (кимчелек) итмә син!
Син дә ялкынлы шигырь, яндырма һичбер кемне!
Ит сабыр, мәзлүм күңел – кан дошманы җәллад китәр», –

диелгән.

«Күңелсез минутта» шигыренә «Беттем» (Тукайдан эпиграф китерелә. Идел. 1910. № 260) памфлетын һ.б.ны яза. Бөтен иҗаты буена диярлек ялгызлыктан, үзен аңламау, танымауларыннан зарлана, сыктый. Тукай «Ялгызлыкта» дигән пародиясендә В.Җәлал әсәрләренең шундый сыйфатларына басым ясаган.

## ИКЕНЧЕ ТОМГА КЕРГӘН ӘСӘРЛӘРНЕҢ АЛФАВИТ ТӘРТИБЕНДӘ ЭЧТӘЛЕГЕ


**А**

Авылда авырып яту
Авыл җырлары (Бишенче көлтә)
Авыл җырлары (Дүртенче көлтә)
Авыл җырлары (Өченче көлтә)
Авыл мәдрәсәсе
Авыл халкына ни җитми
Ай һәм Кояш
Ак Бабай
Актык тамчы яшь
*** («Амур» – фәхеш ресторанны...»)
Ана догасы
Ана илә Бала
Аң
Арба, Чана, Ат
Ачы тәҗрибә авазы
Ачы хакыйкать

**Ә**

Әнә-менә
Әнвәр бәк
Әхлаксызлык

**Б**

Бабай
Бала белән Күбәләк
Бала оҗмахта
Балканда
Балкан көйләре
Баскыч
Бәгъзе зыялыларымыз
Бәет
Бәндәләр
Бәрәңге вә гыйлем
Бәхетле бала
Безнең гаилә
Бер мән
Бичара Куян
Бишек җыруы
Борын
Булмый
*** («Бунларның берсе – үз анасы...»)
Буран
Буш вакыт

**В**

Ваксынмыйм
Вакъты гаҗезем
Валлаһи
Васыятем
Вөҗдан зарары

**Г**

Габделхәмид
...га («Бул кеше...»)
Газаптан соң
Гаилә тынычлыгы
Гакыллылар фәлсәфәсе
Гали белән Кәҗә
...га («Шома тормыш юлында...»)
Гашыйк
Гласный
Гомер хакында
Гомер юлына керүчеләргә
Гөнаһ
Граммофонда татар җырлары
Гыйбрәт вә нәсыйхәт

**Д**

Даһигә
Дәүре галәм
Дин вә гавам
Дошманнар

**Е**
Елның дүрт фасылы

**Җ**
Җабир хәзрәт мактана...
Җәйге таң хатирәсе
Җәй көнендә
Җегетләр
Җил
Җил тавышы
Җир йокысы
*** («Җырласаң да, җегет...»)

**З**
Золым
Зур бәшарәт!

**И**
Ике иптәш арасында
Ике кояш
*** (Ике хатын берлә тормыш)
Ике юл
Имтияз алган бала
Интикадка мөтәгалликъ
Иртә
Исемдә
Иссез чәчәк
Ит базарында тәрәкъкый
*** («И төрек, иң әүвәл үк...»)
Иһтида
Ишан

**Й**
Йокы алдыннан
«Йолдыз»дан да курка

**К**
Кадер кич
Казан
Казан вә Кабан арты
Казан вә Казан арты
Казан мулласы һәм булачак депутат
Кайда? Кем?
Кайчакта
Карга
Карлыгач
Картлар
Катиле нәфескә
Кәҗә белән Сарык хикәясе
Кәҗә тугърысында
Кечкенә музыкант
Киңәш («Чикмә гамь...»)
Киңәш («Ялангач калдыйсәң...»)
Китап .
Кичке теләк
Кичә һәм бүген
Кошларга
Кошчык
Көзге җилләр
Көлке түгел
Көтмәгәндә
*** («Кушмый ишан хилкасендә...»)
Кушмый ишәк җырлый
Күгәрчен
Күңел
Күңел йолдызы
Күңелле сәхифәләр
Күрсәтә
Кызыклы Шәкерт
Кыйтга («Көчләремне мин...»)
Кыйтга («Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов...»)
Кышка бер сүз
Кышкы кич
Кярханәдә

**М**
Мәҗлес

Мәҗрух указ
Мәктәп
Мәктәптә
Мәхәббәт шәрхе
Мигъраҗ
Милли моңнар
Минһаҗ
Мияубикә
Могъҗиза
Монафикъка
Мөбарәк тәсбих өзелде
Мөкаддимә
Мөнтәкыйд
Мөхәрриргә
Муллалар

**Н**

Нәсыйхәт
Ни кирәк тагы?
Ник? Нигә?
*** («Ничек тормак тиеш, дустым? дисеңме...»)
Нумирга төшкән искеләр

**О**

Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре

**Ө**

Өзелгән өмид
Өйләнү – түгел сөйләнү
Өмидсезлек
Өч хәкыйкать

**П**

Пәйгамбәр
Поезд барган көйгә
*** («Приемныйның ишекләре...»)
Пушкин вә мин

**Р**

Рамазан гаетендә Иблиснең шәйтаннарына хитабы

**С**

Сабитнең укырга өйрәнүе
Сабыйга
Сабыйлар җыруы
Сагыныр вакытлар
Сайфия
«Сакмар суы» көенә
*** («Сәгатьләр келт-келт итәдер...»)
Сәрләүхәсез
Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә
Сибгатуллин
Сөбханалла, сөбханалла
Суык

**Т**

Табышмаклар
Танса
Татар мөхәрриренә
Татар яшьләре
Таян Аллага
Тәләһһеф
Тәмсил («Әһле Балкан кечкенә...»)
Тәмсил (Италия-Төркия сугышы мөнәсәбәтилә)
Тәрәддөд вә шөбһә
Тәүбә вә истигъфар
Тәфсирме? Тәрҗемәме?
*** («Теләрсәң кемне сүк...»)
Теләү бетте
Толстой сүзе («Зур бәхет инсанга...»)
Толстой сүзе («Кирәк анчак...»)
Толстой сүзләре
Толстой фикере
Толугышшәмси мин мәгърибиһа

Төрекчәдән («Сөйгәнеңне мин кочам, дип...»)
Төрекчәдән («Эзләдем, филлаһ...»)
*** («Төркия янгын эчендә...»)
Төш
Туган авыл
Туган тел

**У**

*** («Уңга да мин әйләнәм...»)
Уянмас йокы

**Ү**

Үкенеч
Үтенеч

**Ф**

Фатыйма белән Сандугач

**Х**

*** («Хайлыйм, хайлыйм хайларга...»)
Хале хазир
Хасият
Хатыннар хөррияте
Хәзерге өйләнүчеләр
Хәстә хәле
Хөрмәтле Хөсәен ядкяре

**Һ**

*** («Һәзад-дөнья әкалле...»)
Һәзиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа
Һәркемнең ашыйсы килә
Һәр ялтыраган алтын түгел

**Ч**

Читен хәл
*** («Читтәге бик күп өяздә...»)
Чыршы

**Ш**

Шаян Песи
Шекспирдән («Күрәм кайчакта...»)
Шигърият һәм нәсер
Шиһаб хәзрәт
«Шура» шигырьләреннән
Шөһрәт
Шыер

**Э**

Эш
Эш беткәч уйнарга ярый
Эшкә өндәү
Эштән чыгарылган татар кызына

**Я**

Яз галәмәтләре
Яз хәбәре
Ялгызлыкта
Ялкау Маэмай
Янә бер хатирәм
Яңа чыкты
Яңгыр
Яңгыр илә Кояш
Япун хикәясе
Яратырга ярый
Яшен яшьнәгәндә
Яшьләр

**ЭЧТӘЛЕК**

**1909**

Күңел
Васыятем
Тәрәддөд вә шөбһә
Хатыннар хөррияте
Авыл җырлары (Өченче көлтә)
Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә
Пәйгамбәр
Исемдә
Нумирга төшкән искеләр
Дәүре галәм
Ишан
Хәзерге өйләнүчеләр
Булмый
Минһаҗ
Гласный
*** («Хайлыйм, хайлыйм хайларга...»)
*** («Бунларның берсе – үз анасы...»)
Күрсәтә
Габделхәмид
Муллалар
Вөҗдан зарары
Ике юл
*** («Ничек тормак тиеш, дустым? дисеңме...»)
Гаилә тынычлыгы
Киңәш («Ялангач калдыйсәң...»)
Ике кояш
Эштән чыгарылган татар кызына
Бәгъзе зыялыларымыз
Гомер хакында
Ачы хәкыйкать
Төрекчәдән («Сөйгәнеңне мин кочам, дип...»)
Гашыйк
Вакъты гаҗезем.
Шекспирдән («Күрәм кайчакта...»)
Китап
Мөкаддимә
Сөбханалла, сөбханалла
Эш
Әнә-менә
Могъҗиза
Туган авыл
Чыршы
Яңгыр илә Кояш
Милли моңнар
Яратырга ярый
Япун хикәясе
Күңел йолдызы
Киңәш («Чикмә гамь...»)
Сәрләүхәсез
Теләү бетте
Туган тел
Ана догасы
Таян Аллага
Бабай
Уянмас йокы
Ай һәм Кояш
Җир йокысы
Кышка бер сүз
Кошларга
Сабыйга
Карлыгач
Кышкы кич
Кошчык
Бишек җыруы
Бәхетле бала
Бала белән Күбәләк
Мәктәптә
Эш беткәч уйнарга ярый
Арба, Чана, Ат
Кярханәдә
Кәҗә белән Сарык хикәясе

**1910**

Татар мөхәрриренә
Нәсыйхәт
Мәҗрух указ
Кәҗә тугърысында
Зур бәшарәт!
Җәйге таң хатирәсе
Авыл җырлары (Дүртенче көлтә)
Күңелле сәхифәләр
Имтияз алган бала
Һәр ялтыраган алтын түгел
Безнең гаилә
Гали белән Кәҗә
Фатыйма белән Сандугач
Һәркемнең ашыйсы килә
Ялкау Маэмай
Шаян Песи
Кызыклы Шәкерт
Бичара Куян
Ак Бабай
Кичә һәм бүген
Мигъраҗ
Ике иптәш арасында
Ник? Нигә?
Катиле нәфескә
Газаптан соң
Ачы тәҗрибә авазы
Җәй көнендә
Мәҗлес
Яз хәбәре
*** (Ике хатын берлә тормыш)
Кайчакта
Гомер юлына керүчеләргә
Өмидсезлек
Хале хазир
Үкенеч
Хасият
Яшьләр
Танса
Иссез чәчәк
Сибгатуллин
Күгәрчен
Баскыч
Бер мән
Мөбарәк тәсбих өзелде
Актык тамчы яшь
Граммофонда татар җырлары
Ит базарында тәрәкъкый
*** («Сәгатьләр келт-келт итәдер...»)
Елның дүрт фасылы
Төш
Өзелгән өмид
Кайда? Кем?
Тәләһһеф
Өйләнү – түгел сөйләнү
...га («Бул кеше...»)
*** («Кушмый ишан хилкасендә...»)

**1911**

Борын
Кушмый ишәк җырлый
*** («Төркия янгын эчендә...»)
...га («Шома тормыш юлында...»)
Мияубикә
Ана илә Бала
Карга
«Сакмар суы» көенә
Җил
Эшкә өндәү
Иртә
*** («И төрек, иң әүвәл үк...»)
Шигърият һәм нәсер
*** («Приемныйның ишекләре...»)
«Шура» шигырьләреннән

Иhтида
*** («Уңга да мин әйләнәм...»)
Яшен яшьнәгәндә
*** («Һәзад-дөнья әкалле...»)
Читен хәл
Гөнаh
Авыл җырлары (Бишенче көлтә)
Гакыллылар фәлсәфәсе
Кадер кич
Рамазан гаетендә Иблиснең шәйтаннарына хитабы
Сайфия
Поезд барган көйгә
Тәмсил (Италия-Төркия сугышы мөнәсәбәтилә)
Толстой фикере
Тәүбә вә истигъфар
Көзге җилләр
Золым
Кечкенә музыкант
Төрекчәдән («Эзләдем, филлаh...»)

**1912**

Сабитнең укырга өйрәнүе
Гыйбрәт вә нәсыйхәт
Авыл мәдрәсәсе
Бәет
*** («Читтәге бик күп өяздә...»)
*** («Җырласаң да, җегет...»)
*** («Теләрсәң кемне сүк...»)
Яз галәмәтләре
Хөрмәтле Хөсәен ядкяре
Янә бер хатирәм
Шыер
Һәзиhи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа
Балканда
Казан мулласы hәм булачак депутат
Валлаhи
Тәмсил («Әhле Балкан кечкенә...»)
Аң
Толугышшәмси мин мәгърибиhа
Үтенеч
Дошманнар
Кичке теләк
Җегетләр
Ваксынмыйм
Бала оҗмахта
Сагыныр вакытлар
Картлар
Авылда авырып яту
Бәрәңге вә гыйлем
«Йолдыз»дан да курка
Буран
Көтмәгәндә
Көлке түгел
Әхлаксызлык
Монафикъка
Сабыйлар җыруы
Ни кирәк тагы?
Пушкин вә мин
Мөнтәкыйд
Интикадка мөтәгалликъ
Мәхәббәт шәрхе
Казан вә Кабан арты
Казан вә Казан арты
Татар яшьләре
Дин вә гавам
Яңгыр
Җил тавышы
Авыл халкына ни җитми
Өч хәкыйкать
Балкан көйләре

**1913**

Шиhаб хәзрәт

Йокы алдыннан

Суык
Хәстә хәле
Әнвәр бәк
Даһигә
Толстой сүзе («Зур бәхет инсанга...»)
Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре
Кыйтга («Көчләремне мин...»)
Шөһрәт
Толстой сүзе («Кирәк анчак...»)
Тәфсирме? Тәрҗемәме?
Мөхәрриргә
Толстой сүзләре
Кыйтга («Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов...»)
Буш вакыт
Мәктәп
Казан
**Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр**
Яңа чыкты
Җабир хәзрәт мактана...
Табышмаклар
Бәндәләр
*** («Амур» – фәхеш ресторанны...»)
Ялгызлыкта
**Искәрмә һәм аңлатмалар**

Литературно-художественное издание

**Тукай** Габдулла
(**Тукаев** Габдулла Мухамметгарифович)

СОЧИНЕНИЯ

Академическое издание

В шести томах

Том 2

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Тукай** Габдулла
(**Тукаев** Габдулла Мөхәммәтгариф улы)

ӘСӘРЛӘР

Академик басма

Алты томда

2 том

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Галимуллина, Г.Г.Зиннәтуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.04.2011. Форматы 60Х90 $^{1}/_{16}$.
Басма табагы 24,0. Тиражы 3000 д. Заказ Р-491.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.